Татарстан Республикасының Мәдәният Министрлыгы

Татар фольклоры дәүләт үзәге

# *Татар халык иҗаты*

## *Фәнни эзләнүләр һәм фольклор үрнәкләре*

***(Фәнни конференцияләр материаллары җыентыгы)***

Беренче китап

Казан 2004

Татар фольклоры дәүләт үзәгенең Гыйльми Советы карары белән басыла

Төзүче: Сотникова Л.П.

Редколлегия: Завгарова Ф.Х. (җаваплы редактор), Мухамедова Р.Г., Исхакова-Вамба Р.А.

Татар халык иҗаты. Фәнни эзләнүләр һәм фольклор үрнәкләре. (Фәнни конференцияләр материаллары җыентыгы). Беренче китап. – Казан: РИЦ “Школа”. – 2004. – с.

Җыентыкта фольклор мирасын өйрәнү һәм аның тарихка, мәдәнияткә мөнәсәбәтле мәсьәләләренә багышланган мәкаләләр, фольклор үрнәкләре тупланган. Халкыбызның мәдәни мирасы, фольклоры белән кызыксынучыларга тәкъдим ителә.

# Төзүчедән

Татар фольклоры дәүләт үзәге үзенең еллык фәнни эшләрен йомгаклап, ел саен конференцияләр үткәрә. Конференциядә укылган докладлар фольклор мирасын өйрәнү, фәнни эшкәртү, фольклорның профессиональ мәдәниятскә тәэсире, еллык фольклор экспедицияләре нәтиҗәләре, яңа табылган үзенчәлекле үрнәкләр белән уртаклашуга багышлана.

Үзәкнең гыйльми Советы 2004 елдан башлап, конференция материалларын аерым җыентыклар итеп бастырып чыгара башлауны максат итеп куйды. Бу җыентык шул максатны тормышка ашыруның беренче карлыгачы.

Җыентыкка башлыча 2003-2004 елларда үткәрелгән конференция материаллары урнаштырылды. Материалларның эчтәлегенә карап мәкаләләр тупланмасын шартлы рәвештә өч өлешкә бүлдек. Беренче өлеш фәнни-тикшеренү характерындагы мәкаләләрдән оешты. Бу бүлектә төп урынны фольклор үрнәкләренең тарихи чыганак буларак бәяләнү мөмкинлекләре мәсьәләсе, мифларның хәзерге әдәби әсәрләрдә поэтик чагылышы аспектлары, халык экиятләренең мифик күзаллауга мөнәсәбәтләре, хәзерге керәшен туй йолаларында персонажлар бирелеше үзенчәлекләрен күтәрүгә багышланган мәкаләләр алды, шунда ук әдәбият дөньясында билгеле шәхес Фазыл Туйкинның фольклор өлкәсендәге эшчәнлеге яктыртылды.

Икенче бүлектә Кукмара районына оештырылган экспедиция материаллары тәкъдим ителде. Әлеге мәкаләләрендә авторлар экспедиция барышында тапкан нәтиҗәләре белән уртаклашалар.

Өченче бүлек Татар фольклоры дәүләт үзәгенең төрле музей, архив фондларында сакланган, әмма фәнни әйләнешкә кермәгән фольклор үрнәкләрен махсус эзләү планы нәтиҗәләренә багышланган. Бу бүлектә Иван Николаевич Юркин тарафыннан XIX йөз ахырында җыелган, моңа кадәр җыентыкларда урын бирмәгән татар халкының сюжетлы җырлары тәкъдим ителә. Җырларны архивтан табып, күчереп басмага әзерләгән Р.Г.Мухамедова әлеге халык җырларын И.Н.Юркин фондында ничек сакланса, шул килеш тәкъдим итә. Бүлекнең икенче мәкаләсе милли мәдәниятебезнең күренекле шәхесе Зәйнәп Максудова архивында сакланган мәкаль һәм әйтемнәрне әйләнешкә кертә.

# *I бүлек*

*М.Х.Бакиров,*
филология фәннәре докторы, профессор,
ТФДҮнең әйдәп баручы фәнни хезмәткәре

## *Легенда-риваятьләргә төренгән тарихыбыз*[1]

Төрле гыйлемнәрнең табышларын, шулай ук борынгы культура мирасы материалларын файдалануга нигезләнгән комплекслылык методы хәзерге фәннең бик мөһим бер казанышы булып исәпләнә. Теге яки бу халыкның этногенезы (килеп чыгышына) һәм этник тарихына бәйләнешле проблемалар да, табигый ки, төрле фәннәр һәм милли культура ядкәрләре үзара очраша торган уртак җирлектә генә аеруча уңышлы булып хәл ителә ала. Безнең темага мөнәсәбәтле тарихи фольклор да, һичшиксез, халкыбызның этник тарихына бәйләнешле культура мирасына керә.

Фольклорның аерым жанрлары, бигрәк тә риваять һәм легендалар, аеруча кыйммәтле чыганак булып исәпләнәләр, чөнки алар гасырлар тирәнлегеннән килә торган бай мәгълүматлар белән сугарылган. Һәм бу табигый да. Риваятьләр алар – халыкның буыннан-буынга тапшырыла килгән тел-авыз иҗаты елъязмасы. Аларның төп вазыйфасы – борынгы мөһим вакыйгалар һәм шәхесләр турында халыкның хәтерен-истәлекләрен саклау һәм җиткерү, аларга тарихи-эстетик бәя бирү[2]. Легендалар да, риваятьләр кебек үк, дөреслеккә дәгъва итә торган, заманында сөйләүче тарафыннан да, тыңлаучы ягыннан да булган хәл итеп кабул ителгән һәм кайчакта хәзер дә шулай булып кала торган эпик хикәятләр. Ләкин риваятьтән аермалы буларак, легендаларда гадәттән тышлык, хыял-фантастика, уйдырма һәм кайчакларда хәтта мифологик башлангыч та катнаша. Тик шулай да, легендалар вакыт-вакыт аерым тарихи мәгълүматлар белән үрелеп-керешеп китәләр. Димәк, алардагы шул тарихи орлыкны яки нигезне күрә һәм таба белергә, иң мөһиме – чынны уйдырма катламнан аерып ала белергә кирәк[3].

Алабуга белән бәйләнешле тарихи фольклорны фәнни кулланышка керткәндә һәм бәяләгәндә, без әнә шундый таләпләрдән һәм методологик принциплардан чыгып эш итәргә тиешбез. Бүгенге көндә безгә Алабуга турында һәм, руслар биргән атама белән әйткәндә, “Шайтан каласы” (“Чертово городище”) хакында берничә риваять һәм легенда билгеле. Аларның иң борынгыларында сүз Кама (Чулман) елгасы буендагы әлеге “кала”да заманында канатлы зур елан-сазаган яшәгәнлеге турында бара һәм җирле халыкның шуңа бәйләнешле ышанулары китерелә. Бу мәҗүси-мифологик легендалар безнең көннәргә Казан ханлыгында әсирлектә булган исеме билгесез кеше язып калдырган “Казанская история” (XVI йөз) һәм Шәрәфетдин Болгари-Мөслими язган “Тәварих-и Болгария” (XVIII йөз) кебек чыганаклар аша килеп җиткәннәр[4]. Шул ук легендаларның аерым вариантлары

---

[1] Мәкалә Алабуганың 1000 еллыгын ачыклауга багышланган фәнни конференциядә сөйләгән доклад нигезендә язылды һәм татар халкының килеп чыгышына бәйләнешле өстәмә мәгълүматлар белән тулыландырылды.
[2] Соколова В.К. Русские исторические предания/ В.К. Соколова. – М.: Наука, 1971. – С.27.
[3] Толстова Л.С. Исторические предания Южного Приуралья/ Л.С. Толстова. – М.: Наука, 1984. – С.19.
[4] Казанская история. Историческая повесть XV в. – М.-Л.: Изд. АН СССР, 1954. – С.194; Усманов М.А. Татарские исторические источники XVII-XVIII вв./ М.А. Усманов. – Казань: Изд. КГУ, 1972. – С.113, 165.

шулай ук XIX йөз галимнәре П.Рычков, Н.Рычков һәм Ф.Эрдман хезмәтләре аша да мәгълүм[1].

XIX йөзнең ахырында тарихи мәгълүматларга таянып, Платон Заринский ачыклавынча һәм, безнең көннәрдә профессор А.Халиков раславынча, канатлы елан-сазаган образы Болгар дәүләте чорында һәм, өлешчә хәтта Казан ханлыгы дәверендә дә әле, җирле халык тарафыннан изгеләштерелгән һәм саклаучы-яклаучы мәҗүси-мифик зат итеп күз алдына китерелгән[2]. Ата-бабадан килгән бу традициянең, ягъни илаһилаштырылган сазаган культының башы болгарлар һәм татарлар составына субстрат (субстрат – иң борынгы катлам мәгънәсендә) һәм этник компонентлар булып кергән һун-гуннарга, сувар-хазарларга, угыз-кыпчакларга барып тоташа. Ачыклап әйткәндә, кытай язмаларында Үзәк Азия һуннарының Лун-сы (“Елан-ләү храмы”) дигән гыйбадәтханәдә күккә (Тәңрегә) багышлап корбан бирүләре, патша-шаньюйлары мәетен ак елан-сазаган сурәте төшерелгән кара ефәккә чорнап күмүләре теркәлеп калган[3]. Себердәге төрки каганат идарәчеләре Билге-каганның һәм Күл-тегинның каберләре өстенә исә ләү-сазаган ясалган ташлар куелган булган[4]. Ә менә болгарларның бер кабиләсен тәшкил итүче савир/ суварлар Төньяк Кавказда яшәгән вакытта муеннарына алтыннан һәм көмештән елан-сазаган сурәте ясалган бөти-амулет тагып йөргәннәр[5]. Янә килеп, көньяк далаларда яшәгән кыпчаклар канатлы елан-сазаган сурәтен кылыч-хәнҗәр сапларына, садакаларына – ук савытларына һәм ат дөрбия-сбруйларына ясый торган булганнар. Мурад Аджи тикшереп ачыклавынча, әлеге яклаучы-саклаучы образ кыпчакларның этник символы булып әверелгән (сүз бара торган мифик образ исеменең кыпчак-куман телендәге һәм Идел буе болгарларындагы вариантлары: сазаган/саруган/шарукан). Боларга өстәп тагын шуны әйтергә кирәк: Дон буе кыпчакларының башында 150 ел буена “елан-сазаган халкы”ннан чыккан Шаруканнар династиясе-нәселе торган һәм аларның Шарукан исемле шәһәре дә булган[6].

Яңа тикшеренүләр күрсәткәнчә, сазаган образы хәтта борынгы болгарларның һәм кыпчак-кимакларның күмү йолаларында да яклаучы-саклаучы мифик зат буларак катнашкан. Бу очракта мин, барыннан да элек, Дунай буе Болгар дәүләтенең беренче башкаласы Плиска янында Аспарух (VII йөз) каберлегендә табылган сазаган сүрәтен күздә тотам[7]. Кубрат хан династиясенең тамга-мөһере булып исәпләнүче җиз тәңкәгә ясалган әлеге мифологик образ, безнең уебызча, хан каберенә йола таләп иткән өчен генә түгел, ә теге дөньяда хуҗасын яклау һәм саклау өчен дә күмелгән булырга тиеш.

Икенче мисал IX йөздә Көнбатыш Себердә барлыкка килгән кимаклар дәүләте территориясендә - Иртыш буенда ачылган Зевакин каберлеге белән бәйле. Безнең

---

[1] Рычков П.П. Опыт Казанской истории древнейших и средних времен/ П.П. Рычков. – Спб., 1767. – С.45-46; Рычков Н.П. Журнал и дневные записки путешествия по разным провинциям Российского государства 1769 и 1770 годов/ Н.П. Рычков. – Спб., 1870. – Ч. I. – С.60-67.

[2] Платон Заринский. Сборник исторических и археологических исследований о Казанском крае/ П. Заринский. – Казань, 1880. – С.76, 83; Халиков А.Х. О времени, месте возникновения и названии города Казани/ А.Х. Халиков// Из истории культуры и быта татарского народа и его предков. – Казань: Тат.гос.изд., 1976. – С. 3-19.

[3] Мелиоранский С.П. Об орхонских и енисейских надгробных памятниках с надписями/ С.П. Мелиоранский// Журнал министерства народного просвещения. – Спб., 1898. – Ч. 317. – С.269.

[4] Руденко С.И. Культура хуннов и Ноинулинские курганы/ С.И. Руденко. – М. Изд. АН СССР, 1962. – С.205.

[5] Гадло А.В. Этническая история Северного Кавказа IV-X вв./ А.В. Гадло. – Л.: изд. ЛГУ, 1979. – С.145; Мовсэс Каланкатуци. История страны Алуанк/ М. Каланкатуци. – Ереван. Полынь половецкого поля. – М.: ТОД “Пик-контакт”, 1994. – С.87, 335-336.

[6] Ахинжанов С.М. Кипчаки в истории средневекового Казахстана/ С.М. Ахинжанов. – Алма-Ата: “Наука” Казах. ССР, ССР, 1989. – С.133-135.

[7] Салихова Ф. Родословная дракона// Идель. – Казань, 1990. - №9. – С.32-33

темага кагыла торганы – байбикә хатын күмелгән каберлектә табылган рун язмалы бронза көзгедәге рун – төрки бабаларыбызның борынгы шрифт-язу төре. Утыз хәрефтән торган бу ике юллык төркичә язманы археолог Ф.Арсланова белән тюрколог С.Кляшторный, текстта күрсәтелмәгән сузык авазларны үзләре фараз иткәнчә ачыклап, болай укыганнар: isi k$^{\text{ü}}$n$^{\text{i}}$s$^{\text{i}}$n s$^{\text{ä}}$s$^{\text{ä}}$r quty b$^{\text{a}}$s$^{\text{a}}$r (беренче юл); j$^{\text{ä}}$bči j$^{\text{ä}}$gr$^{\text{ä}}$n sŋlü (икенче юл). Аларча тәрҗемәсе: “Знатная женщина освобождается от своего [чувства] зависти (гнева). Ее счастливый удел (ее благость) наступает”. “Ябчи – рыжий (вар. огненно (ярко)-красный) ... дракон”[1].

Мин бу укылыш һәм әлеге тәрҗемә белән килешмәдем, текстны тартмый-сузмыйча, башка сузыклар белән үземчә укыдым. Түбәндәге гыйбарә һәм мондый кызыклы мәгънә килеп чыкты. Беренче юл: iši k$^{\text{ü}}$n$^{\text{ä}}$šn s$^{\text{e}}$š$^{\text{ä}}$r quty b$^{\text{o}}$š$^{\text{a}}$r; икенче юл: j$^{\text{a}}$bči j$^{\text{a}}$g$^{\text{i}}$n s$^{\text{e}}$ŋ lü. Тәрҗемәсе: “Байбикә кояшыннан аерыла, рухы (җаны) ташлап китә”; икенче юл: “Якла (каплачы) дошманнан, изге лү (сазаган)”, яки варианты: “... җирән (кызгылт-сары) лү”. Аңлатма рәвешендә өстик: борынгы төркиләргә “кояшыннан аерылу”, “кояшы сүнү”, “кояшы бату” кебек гыйбарәләр үлү, вафат булу мәгънәсен белдергән. Мәсәлән, Мәхмүд Кашгарида: ölük bilä qošuldy, togmyš kÿni uš batar – ’үлек(ләр) (мәетләр) белән кушылды, туган (чыккан) кояшы инде бата’ (МК, II, 146); якутларда: кунім сан буолла – “кояшым сүнде” (үлгәндә бәхилләшү формуласы). Бронза көзгедә без “jap-/jaв-” дип укыган сүзнең, “ябу”дан тыш, каплау, саклау дигән мәгънәләре дә булган: er qalqan japïndï - ’ир калкан белән капланды’ (-сакланды) (МК, III, 82). Борынгы төрки телдә һәм текстта кулланылган лү (вар. Ләү) сүзе исә кытайларның изгеләштерелгән елан-аждаһаны белдерүче “луң” сүзеннән үзгәртеп алынган.

Димәк, мисаллардан аңлашылганча, сазаган образы һуннардагы кебек ук, кыпчак-кимакларда да яклаучы-саклаучы буларак, хәтта теге дөньяга озата баручы булып чыга. Безнең бу нәтиҗәбез Себердә атаклы Аржан курганын казыганда, бер төрки кабереннән рун хәрефләре белән “lü” дип язылган бронза аел табылуы белән дә раслана[2]. Каеш аелындагы бу сүзнең лү-сазаганның яклавына һәм саклавына исәп итеп язылганлыгы, безнеңчә, шиксез.

Борынгы төркиләрдә изгеләштерелгән ләү-сазаган образлары мифологик ышанулар, легендалар даирәсендә генә торып калмаган, ә борынгы төркиләрнең төрле сәнгать төрләренә, шаман догаларына һәм героик эпос-дастаннарына да үтеп кергән. Мәсәлән, кыргызларның атаклы “Манас” дастаны баштан алып ахырга кадәр елан-“айдагар” культы белән сугарылган (төрки телләрдәге айдагар, ажыдар, аждарһа, аждаһа – ираннарның өч башлы елан-баскак патша Ажи-Дахака исеме нигезендә ясалган сүзләр). “Бер башлы җитмеш колачлы айдагар” анда төрки-кыргызларны яклаучы буларак хәтта яуда катнаша[3]. Шулай ук кыргызлар, казакълар казакълар һәм Себер татарлары арасында билгеле булган “Йиртөшлек” дастанында да геройга теләктәшлек итүче елан-аждаһалар патшасы - Ак елан тасвирлана. (Каюм Насыйри сүзләрен исегезгә төшерегез: “Барлык еланнар кара төстә булып, еланнар патшасы ак була. Ак елан татарны яклый, ярата, алдан хәбәр биреп, төрле файдалар китерә”)[4]. Себер-Алтай шаманнарының чакыру догаларында да “алтмыш колачлы

---

[1] Арсланова Ф.Х., Кляшторный С.Г. Руническая надпись на зеркале из верхнего Прииртышья/ Ф.Х. Арсланова, С.Г. Кляшторный// Тюркологический сборник. 1972. – М.: Наука, 1973. – С.306-315.

[2] Кляшторный С.Г. Рунические надписи из Кургана Аржан II/ С.Г. Кляшторный// Первобытная археология Сибири. – М.: Наука, 1975. – С.184.

[3] Манас. – Фрунзе: Гилем, 1958. – 368 б.; Манас. Киргизский героический эпос. Великий поход. – М.: М.: Гос.изд.художест.литр-ры, 1946. – С.372.

[4] Насыйри К. Сайланма әсәрләр/ К. Насыйри. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1975. – Т.2. – Б. 46.

ажыдар” шаманның ярдәмчесе-булышчысы итеп сурәтләнә. Янә килеп, борынгы “Угыз-наме” дастанының хәзергә күпләргә билгесез Стамбулда Топкану китапханәсендә саклanучы версиясендә дә үзенең сихри-магик куәте белән яхшы һәм гаепсез кешеләрне бәла-казалардан һәм гарип-горабалыктан коткаручы-савыктыручы (явыз һәм гөнаһлы-гаепле кешеләрне ашаучы) изге елан-сазаганнар тасвирлана[1]. Әгәр боларга янә Идел буе Болгар дәүләте биләмәләрендә табылган канатлы елан-сазаган сурәте төшкән мөһерләрне, бакыр акчаларны, алтын йөзекләрне[2] һәм бил каешына тегелә торган шундый ук сурәтле тәңкәләрне дә китереп кушсаң, әлеге мифик образ культының элек никадәр нык таралган булуы тагын да тулырак төс ала. Һәм шушы ук гамәли сәнгать ядкәрләреннән болгарларның бу образны ни өчен изгеләштергәнлекләрен, нинди максатта кулланганлыкларын да чамаларга була.

Инде Алабугадагы “Шайтан каласы”на бәйләнешле елан-сазаган образына әйләнеп кайтыйк. Сүз барган легендаларда әлеге илаһи-мифик көч тә үзенә табынучыларга карата ярдәмчел-булышучы зат итеп тасвирлана. Тирә-яктан аңа төрле үтенеч-сораулар белән туктаусыз кеше агылып тора, хәтта әсирләр исәбеннән аңа корбаннар да китерәләр. Канатлы елан-сазаган аларга сихри-илаһи көче белән ярдәм итә: чир-авырулардан котылдыра, Кама елгасы кискен борылыш ясаган куркыныч-бусагалы урыннан көймә-корабларын исән-имин үткәреп җибәрә, күрәзәлек итеп, киләчәк язмышларының нинди булачагы турында җаваплар бирә. Үзе белән исәпләшмәүчеләрне һәм ризалатмыйча үтеп китәргә теләүчеләрне исә һәлак итә, көймәләрен капландыра[3]. Иң мөһиме – болгар мифологиясендә һәм аңа барып тоташучы татар хикәятләрендә елан-сазаган Болгар дәүләтенең һәм соңрак Казан ханлыгының чикләрен саклаучы һәм яклаучы көч булып күз алдына баса[4].

Менә монда инде без сазаган образының тагын бер функциясенә - дәүләт иминлеген, чик буйларын саклау вазыйфасына барып чыгабыз. Заманында канатлы елан образының чик буйларын саклау функциясенә күренекле фольклорчы В.Я.Пропп игътибар иткән булган[5]. Археолог А.Х.Халиков үзенең хезмәтендә “Шайтан каласы”ндагы сазаганга менә шул сыйфатның да хас булуына басым ясый. Һәм шунысы характерлы: ил чиген саклаучы әлеге мифологик образ традицион ышану, дәвамлылык рәвешендә Болгар чорыннан Казан ханлыгы дәверенә дә күчә. Аерым алганда, “Казанская история”дә теркәлгән һәм Н.П.Рычков, Ф.Эрдман язып алган легендаларда Болгар дәүләтенең “мәлиге”/”илтәбәр”е дә, шулай ук Казан ханлыгының ханы да (бер легендада әлеге идарәче Сөембикә итеп бирелә) монголлар яки руслар яу белән килер алдыннан “Кем җиңәчәк – монголлармы (соңрак варианты: руслармы), әллә безме?” дип сорарга Алабугадагы елан-сазаган янына үзләренең вәзирләрен җибәрәләр. Һәр ике очракта да әлеге елан “Минем инде сезне сакларга көчем бетте, бу җирләр басып алучылар кулына калачак” дип җавап бирә һәм, һавага күтәрелеп, юкка чыга.

“Казанская история”дәге легендада янә бер мәгълүмат игътибарны җәлеп итә. Ачыклап әйткәндә, анда “Шайтан каласы”нда яшәүче елан-сазаган руслар килер алдыннан мәҗүси таш гыйбадәтханәдән түгел, ә мәчеттән очып чыгып киткән итеп

---

[1] Рашид ад-дин Фазлаллах. Огуз-наме/ Р. Фазлаллах. – Баку: Элм, 1987. – С.19, 83-84.
[2] Шпилевский С.М. Древние города и другие булгарско-татарские памятники в Казанской губерне/ С.М. Шпилевский. – К., 1877. – С.281.
[3] Казанская история. Историческая повесть XV в. – М.-Л.: Изд. АН СССР, 1954. – С.91-92.
[4] Заринский П. Күрсәтелгән хезмәт/ П. Заринский. - Б. 73-74; Халиков А.Х. Күрсәтелгән хезмәт/ А.Х. Халиков. - Б. 13-14.
[5] Пропп В.Я. Исторические корни волшебной сказки/ В.Я. Пропп. – Л.: Изд. ЛГУ, 1986. – С.219.

тасвирлана. Безгә шулай ук исеме билгесез урта гасыр рәссамының әлеге фактны Казан яулап алынуга бәйләп ясаган рәсеме дә билгеле. Белүебезчә, анда да мәчеттән очып чыгып китүче канатлы елан сурәте төшерелгән. Бу мисалларны кайбер галимнәр гадәттә бабаларыбыз тоткан ислам динен мыскыллау өчен руслар уйлап чыгарган ялган итеп карыйлар. Минемчә, бу дөрес үк караш түгел. Әгәр елан-сазаганны мәчет белән бәйләп күрсәтү, чыннан да, мыскыллау һәм ялган икән, ул чагында Төрекмәнстанның башкаласы Ашхабад янындагы атаклы Анау мәчете (1456 елда төзелгән) порталының як-ягына канатлы ике сары елан-сазаган сүрәте ясалган булуын ничек аңлатырга?![1] Я булмаса Кытайдагы мәчетләрнең стеналарына төшерелгән канатлы елан сүрәтләрен ничек аңларга?![2] Үзеннән-үзе соралып торган җавап бер: мәҗүси ышанулар калдыгы булган һәм безнең көннәргә килеп җиткән әлеге образлар элек-электән үк аерым объектларны, шул исәптән дини храмны-мәчетне саклаучы мифологик зат итеп тә күзалланганнар. Моннан тыш, этнографларның һәм архитекторларның ачыклавынча, Татарстан территориясендә тәрәзә өслекләренә агачтан кырып өй саклаучы елан-сазаган сүрәтләре эшләү традициясенең яшәп килгәнлеге дә билгеле[3]. Бу, әлбәттә, Болгар чорыннан ук башлангыч ала торган традициянең дәвамы.

“Шайтан каласы”ндагы елан-сазаганның заманында нәкъ менә мәчетне һәм үзе яшәгән тирәлекне саклаучы итеп күз алдына китерелгәнлеге турындагы караш А.Халиковның археологик тикшеренүләре белән дә раслана. Ул “Шайтан каласы” нигезенең кыйбла ягына яраштырып төзелгән булуын һәм шунда ук михраб эзе дә саклануын ачыклап, әлеге корылма элек, чыннан да, мәчет булган, шул ук вакытта ул Болгар дәүләте чиген саклаучы кальга-ныгытма вазыйфасын да үтәгән дигән нәтиҗәгә килде[4]. Бу нәтиҗә көньяк гарәп илләрендә элек берьюлы мәчет тә, кальга да булып хезмәт иткән корылмалар салыну традициясе булганлыгы белән дә туры килә һәм раслана.

Борынгы Урта Идел–Кама буе легендаларында елан-сазаган образының әнә шулай дәүләт һәм дин иминлегенә бәйләп сурәтләнүе уңае белән бу урында урынлы нәтиҗә соралып тора: безнең бабаларыбыз болгарлар һәм кыпчаклар, димәк, үзләренең яклаучысы һәм саклаучысы итеп гади җанварны түгел, ә борынгы ышануларыннан килә торган иң куәтле һәм дәһшәтле итеп күз алдына китерелүче мифологик затны сайлаганнар. Илаһи һәм һәлакәтле куәткә ия булган әлеге образ аларның дошманнарында, сугышып яшәгән күршеләрендә һәм, гомумән, явыз ниятле рухларда яки каршы көчләрдә курку-өркү тойгысы тудырырга тиеш булган. Елан-сазаганның ачуыннан һәм зыян китерүеннән хәтта бабаларыбыз үзләре дә курка, шикләнә торган булганнар һәм табыну, корбан бирү исәбенә аның күңелен табарга, ризалатырга һәм үзләренә хезмәт иттерергә тырышканнар. Болгар-кыпчак һәм соңрак өлешчә татар мифологиясендә канатлы елан-сазаганның аерым объектларны, кеше аягы басмаган җирләрне һәм чик буйларын саклаучы илаһи көч булып чыгыш ясавы һәм дә Болгар дәүләте илә Казан ханлыгының этник тамга һәм герб рәвешендәге билгеләре булып китүе[5] менә шуның белән аңлатыла да.

---

[1] Анау// БСЭ. – Т.1. – С.578; Пугаченкова Г.А. Мечет Анау/ Г.А. Пугаченкова. – Ашхабад, 1959. – С.58.
[2] Решетов А.М. Дракон в культурной традиции китайцев/ А.М. Решетов// Материальная культура и мифология. – Л.: Наука, 1981. – С.87.
[3] Бусыгин Е.П., Зорин Н.В., Токсубаева Л.С. Декоративное оформление сельского жилища в казанском Поволжье/ Е.П. Бусыгин, Н.В. Зорин, Л.С. Токсубаева – Казань: Тат.кн.изд., 1986. – С.82-83.
[4] Халиков А.Х., Шарифуллин Р.Ф. Исследование комплекса мечети/ А.Х. Халиков, Р.Ф. Шарифуллин// Новое в археологии Поволжья. – Казань, 1979. – С.27-28.
[5] Валеев Ф.Х. Древнее и средневековое искусство Среднего Поволжья/ Ф.Г. Валеев. – Йошкар-Ола: Мар.кн.изд., 1975. 1975. – С. 101.

Янә килеп, заманында елан-сазаган сурәтләре төшерелгән һәм шамаил кебек гарәп хәрефләре белән чигеп-нәкышләп язылган ефәк-тукыма байраклар, шулай ук уртасына канатлы елан уелган бакыр һәм тимер штандарт-флаглар булганлыгы да, һичшиксез, әлеге образның дәһшәтле һәм куркытучы-саклаучы табигате белән бәйләнгән. Мондый байраклар, флаглар турындагы мәгълүматларга без Мәскәү Кремлендәге кораллар палатасының һәм Россия кораллар музееның элекке архив материаллары исемлеге белән танышканда юлыктык[1]. Күңелдә табигый рәвештә “Болар Казан ханлыгының А.Курбский язмасында телгә алынган трофей-ганимәт “патша байраклары” түгел микән?” дигән сорау туды. Үзенең истәлек-мемуарларында Курбский Казан байлыгын талаулары турында менә ничек язып калдырган бит: “И приказал (Государь) воеводам во граде огни гасити, и многие сокровища казанские велел всему воинству имети. На себя же Государь велел имети ... царя Едигерь Магмета и знамена царские, да пушки”[2]. Аерым чыганакларга караганда, сазаган сурәте төшерелгән байраклар үз заманында хазарларда һәм Анатолияны яулап алган сәлҗүкләрдә дә булган. Кем белә, архив материаллары исемлегендә күрсәтелгән һәм бабаларыбыздан калуы ихтимал булган андый байраклар бәлки бүген дә Мәскәүдәге алда телгә алынган музейларның саклагыч подвалларында беркемне дә кызыксындырмыйча ята торганнардыр...

Бу урында төрки халыкларның, хәтта ислам диненә күчкәннән соң да, традицион мәҗүси ышануларыннан тәмам баш тарту юлына басмауларын, ә кушма-синкретик төстә дәвам итүләрен угызлар мисалында да анализлап китү кызыклы. Билгеле булуынча, Сырдәрья буйларында һәм Каспий диңгезеннән төньяк-көнчыгышта яшәгән угызларның бер өлеше VIII йөздә үк ислам динен кабул итә. 1040нчы елда Сырдәрья угызлары мөселман ыруы-династиясе сәлҗүкләр җитәкчелегендә Төрекмәнстан (элекке Төрекманстан ССР) җирләрен яулап ала, һәм сәлҗүкләр гаскәрендә хәрби җитәкчеләр булып хезмәт итүче Артуклар йортының кабилә тотемы һәм нәсел гербы сазаган була[3]. 1071нче елда сәлҗүкләр Кече Азиягә үтеп керәләр һәм Византия императоры Роман IVнең армиясен тар-мар итәләр. Безнең өчен иң игътибарга лаеклысы – алар үзләре белән бергә Византия территориясенә сазаган культын да алып киләләр[4]. XII йөздә инде Диярбакер каласының Алеп капкасы түбәсендә сазаган сурәте пәйда була, дөресрәге, 1183нче елда язмага андый сын-сүрәт булганлыгы теркәлә[5]. (Бер уңайдан Ашхабад янындагы янындагы Анау мәчетенең порталына - алгы өлешенә угыз-төрекмәннәр тарафыннан ясалган канатлы сазаган сүрәтләрен дә кабат искә төшерик). Госманлы төрекләре арасында сакланган Ахи Эврен (эврен – зур елан) турындагы борынгы легендада да геройның исеменнән һәм әсәрнең эчтәлегеннән елан-сазаган культы беленеп тора һәм хәтта (кызыкның да кызыгы!) сазаганга тиңләштерелүче каһарман Эврен Мөхәммәд пәйгамбәрнең көрәшчесе итеп бирелә. Аерым алганда, легендада герой болай тасвирлана: “В одной руке держал он знамя, даренное пророком Мухамедом, а в другой меч и поражал врагов, как дракон”[6]. (Сүз уңаенда татар дастаны “Идегәй”дән дә бер тәңгәл мисал китерик: “Шаңшаң иткән шам кылыч – Идегәйнең

---

[1] Опись Московской оружейной палаты. Знамени, прапоры, значки, флаги и штандарты. – Спб., 1884. – Ч. III. (Кн. I). – С. 130.
[2] Курбский А.М. Сказание о покорении Казани/ А.М. Курбский – М., 1902. – С.104.
[3] Пугаченкова Г.А. Күрсәтелгән хезмәт. - Б. 46.
[4] Гордлевский В.А. Что такое “босый волк”?// Известия АН СССР. Отд.лит-ры и языка. – М., 1947. – Вып.4. – С.326-337
[5] Гордлевский В.А. Избранные сочинения/ В.А. Гордлевский. - М.: Изд. вост. лит-ры, 1960. – Т.1. – С.164.
[6] Шунда ук. – Б. 203

кылычы ... Аждаһадай сулаган ул кылычның сулышы"[1]). Моннан тыш, сәлҗүкләрнең аерым байракларында сазаган сурәте булуы һәм төрекләрнең элек басу-кырларны саклаучы елан ("тарла-бекчиси") образын изгеләштергәнлекләре дә[2] угызларда елан-сазаган культының болгарларда һәм кыпчаклардагы кебек үк заманында шактый нык таралганлыгы турында сөйли.

Һинд-европа халыкларына, шул исәптән руслар-славяннарга килгәндә исә, алар, киресенчә, тарихта билгеле була башлаган чорларыннан ук елан-сазаганга һәм үзләре җирлегендә туган аждаһага дошман мөнәсәбәттә булганнар[3] ("аждаһа" – ираннарның өч башлы еланны белдерүче "ажи" сүзеннән һәм Иранны яулап алган елан кыяфәтле баскак патша Ажи-Дахака исеменнән). Алай гына да түгел, моннан берничә мең ел элек үк инде аларда елан-аждаһага каршы көрәшүче алла образы (соңрак алмашчысы – изге патша һәм мифоэпик герой) барлыкка килгән. Ул һинд-европалыларга бәйләнешле барлык этник культураларда да түбәндә, җир-суда яшәүче елан-аждаһаны утлы уклары яки утлы ташлар белән әзерлекләүче, аңа каршы көрәшүче яшен алласы итеп күзалланган[4]. Күпчелек Европа халыклары тота торган христиан динендәге "Сатана"/ "Дьявол" да, Библиядә тасвирланганча, коточкыч елан-аждаһа итеп күз алдына китерелгән[5].

Һинд-европалылар һәм славяннар-руслар антихрист-дәһриләрне, мифик кара көчләрне генә түгел, ә үзләренең реаль дошманнарын, шул исәптән күчмә яки утрак тормыш белән яшәүче борынгы төрки кабиләләрне һәм татарларны да елан-аждаһа белән тиңләштергәннәр[6]. Моңа, билгеле, аталган халыкларның елан-сазаганны изгеләштерүләре дә сәбәп булгандыр. Мәсәлән, Владимир Мономах XII йөз башында кат-кат яу белән килеп, Дон буе кыпчакларын кыйраткач, "бог избавил нас от врагов наших и сокрушил им головы змеиные" дип белдергән[7]. Русларның "Казан "Казан елъязмасы"нда исә татар ханлыгының, бабаларыбызның мәркәзе булган Казан "гнездо змиево" дип исемләнә[8] һәм, Казанга килгәч, шушы ук атаманы татарларга карата Петр Беренче дә куллана. Хәтта үзләренең союздашы булган Касыйм ханы Ибраһимны да руслар үзләренең бер риваятендә "Змий Горыныч" дигән кушамат белән атыйлар[9].

Белүебезчә, татар легенда-риваятьләре арасында Казанның еланлы урынга һәм Елан-тауга салынуы, моның өчен ул җирләрнең башта яндырылуы, еланнардан чистартылуы турындагылары да бар. Шуларның берсе 1774 елда сәяхәтче Георги Иоган Готлиб соравы буенча борынгы татар кулъязмасыннан тәрҗемә иттерелеп, немец телендә теркәлгән, икенче шуңа охшаган риваять исә, Сәид Вахитов тарафыннан Татарстанның Спасс кантонында язып алынган[10]. Платон Заринский әлеге еланнарның патшасы ике башлы "аждаһа" да үзе яшәгән төбәкне (бу очракта "кеше аягы басмаган искиткеч гүзәл" Кабан буйларын) саклаучы мифик зат булган

[1] Идегәй. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1988. – Б. 153.
[2] Мифы народов мира. Энциклопедия. – М.: Советская энциклопедия, 1987. – Т. I. – С.449.
[3] История Европы. – М.: Наука, 1999. – Т.1. – С. 109; Миллер Вс.Ф. Очерки в связи с древнейшей культурой/ Вс.Ф. Миллер. – М., 1876. – Т.1. – С.161.
[4] Мифы народов мира. Энциклопедия. – Т.1. – С.529-530.
[5] Толковая Библия. – Пб., 1904-1907. – С.24-27; Мифы народов мира. Энциклопедия. – Т.2. – С.159.
[6] Рыбаков Б.А. Язычество древней Руси/ Б.А. Рыбаков. – М.: Наука, 1987. - С.544-545.
[7] Полное собрание русских летописей. – Спб., 1841. Т.1. – С.279.
[8] Адрианова-Перетц В.П. Очерки поэтического стиля древней Руси/ В.П. Адрианова-Перетц. – М.-Л., Изд. АН СССР, 1947. – С.94.
[9] Адоньева С.Б. Особенности структуры и семантики змееборческого сюжета в фольклоре и письменной традиции/ С.Б. Адоньева// Русский фольклор. – Л.: Наука, 1989. – С.104.
[10] Татар халык иҗаты. Риваятьләр һәм легендалар/ С. Гыйләҗетдинов. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1987. – Б. 50-53, 302-303.

дип карый һәм, янгында исән калгач, шәһәр коручылардан үз оясын туздырганнары, рәнҗеткәннәре өчен үч ала башлаган дип исәпли[1]. Әмма миңа калса, әлеге легендаларны реаль чынбарлык белән бәйләргә дә нигез бар. Аерым фактлардан аңлашылуынча, яңа җирләрне үзләштергәндә элек кешегә күп еланлы урыннарга да килеп төпләнергә, еланнарны төрле юллар белән юк итәргә туры килгән. Һәм, һичшиксез, бабаларыбыз килеп утырган Елан-тау һәм Кабан буйлары да шундый урыннарның берсе булган булса кирәк.

П.С.Паллас та үзенең юлъязмаларында Иртыш белән Обь елгалары арасында "Елан-тау" дип атала торган тау булуы турында яза һәм аның ни өчен шулай аталуының сәбәбен болай аңлата: "Сия гора получила название свое от множества змеев, которые здесь находили как прежде, так и в первые годы построения заводов"[2]. Казан корыла башлаган җирнең дә еланнар кайнашып торган таулы һәм урман-суга бай урын булуы халык фантазиясендә аның нәкъ менә аждаһа саклаган серле төбәк итеп күзаллануына китергән булса кирәк. Ләкин легендаларда Казан халкының котын алып торучы әлеге җыелма образ борынгы болгарлар һәм кыпчаклар изгеләштергән сазаган кебек бер башлы итеп түгел, ә тискәре, явыз елан-аждаһа сыман ике башлы итеп тасвирлана. Ричард Фрейның һәм А.Х.Халиковның бик дөрес ачыклавынча, мондый төр аждаһа һәм аңа каршы көрәш сюжеты төрки халыкларга һәм татарларга иран телле халыклардан кергән[3]. Шулай ук безнең әкиятләрдә каһарманның корбан таләп итүче күп башлы явыз аждаһаны үтереп патша кызын коткаруы турындагы сюжет та (сюжетлар типологиясе буенча АТ 301 мотивы) асылда һинд-европа халыкларының, бигрәк тә ираннарның йогынтысы нәтиҗәсе булып тора.

Күп башлы аждаһа турында сүз чыккач, монда елан-сазаган образына бәйләнешле янә бер мөһим аерманы күрсәтергә кирәк. Тарихи мәгълүматларга караганда, һуннар, борынгы төркиләр һәм болгар-кыпчаклар изгеләштергән бер башлы елан-сазаган/ләү образы һинд-европалылар, ираннар аша кергән күп башлы аждаһадан тышкы кыяфәте белән шактый аерылган. Безнең бабаларыбыз мифологиясендә һәм гамәли-кулланма сәнгатендә әлеге илаһи образ кош яки бүрегә охшаган бер башлы һәм кош кебек канатлы, божра рәвешендә бөгәрләнеп-уралып торган гәүдәле һәм балыкныкы кебек икегә аерылып яки чукланып тора торган койрыклы гибрид зат итеп күз алдына китерелгән, димәк, өч тирәлектә: күктә, җирдә һәм суда яши ала торган тереклек иясе итеп күзалланган. Шул ук вакытта сазаганның канатлы зур ак елан (варианты – сары елан) рәвешендә фараз ителгәне дә булган. Монда, билгеле, рус һәм сарай геральдистлары татарны һәм аның ата-бабалардан килгән тарихи символикасын мыскыл итеп ясаган әтәч, каз һәм личинка-суалчан кыяфәтле мәхлүк "аждахалар" керми. Әтәч кыяфәтле һәм елан койрыклы "аждаһа" образында, мәсәлән, әтәч салган йомыркадан яралган дип фараз ителүче һәм үзенең ачуы, хәтта карашы, сулышы белән бар нәрсәгә һәлакәт, үлем китерүче Василиск дигән коточкыч явыз елан күздә тотылган[4].

Ахыр килеп, тагын бер мөһим искәрмә: изгеләштерелгән бер башлы елан-сазаганнан аермалы буларак, күп башлы явыз елан затын, бабаларыбыз "сазаган", "ак каен" яки кытайлардан кергән алынма сүз белән "ләү" дип түгел, ә ираннардан

---

[1] Платон Заринский. Күрсәтелгән хезмәт/ П. Заринский. – Б. 83-84.

[2] Паллас П.С. Путешествие по разным местам Российского государства/ П.С. Паллас. – Спб., 1786. – Ч. II. (Кн.II). – С.330.

[3] Халиков А.Х. О времени, месте возникновения и названии города Казани/А.Х. Халиков. – С.17-18.

[4] Большой энциклопедический словарь. Мифология. – М.: Большая Российская энциклопедия, 1998. – С.116.

кергән һәм күбесенчә кире мәгънә белдергән атама белән “аждаһа” дип йөрткәннәр. Һәм кайбер очракларда (мәсәлән, кыргызларда һәм казакъларда) хәтта уңай образ булган канатлы һәм бер башлы елан-сазаганны “айдагар”, “аджидаар” дип атаган тәкъдирдә дә, бабаларыбыз аны һинд-европалылар, иранлар йогынтысы аша килгән күп башлы дошман аждаһа белән бутамаганнар. Бу инде канатлы елан образлары, бигрәк тә аларның аталышы иран тәэсирендә күпмедер дәрәҗәдә каршылыклы төс алуына карамастан, төркиләр, шул исәптән кыпчак тел семьялыгына керүче халыклар һәм татарлар хәтерендә яклаучы һәм саклаучы елан-сазаган образы барыбер сакланып калган дигән сүз.

Ләкин йогынтысы, һичшиксез, ике яклы булган. Аерым алганда, русларга болгарлар һәм кыпчаклар йогынтысы аша, шулай ук Казан ханлыгы юк ителгәндә кулларына төшкән трофей-ганимәтләр сыйфатында елан-сазаганга бәйләнешле сәнгать ядкәрләре, төрле мифологик образлар һәм мотивлар үтеп кергән. Тарихчы В.Н.Татищев борынгы елъязмаларга таянып, 1219 - 1230 елларда Владимир-Суздаль кенәзлегендә ак ташлардан салынган Георгий храмының авторы-архитекторы турында мондый мәгълүмат китерә: “Князь Святослав церковь построил новую, вельми дивную резаным камнем; мастер был болгарский”[1]. Б.А.Рыбаковның тикшереп ачыклавынча, бу оста храмның таштан кырып эшләнгән рәсем-бизәкләренә Идел болгарларының мәҗүси ышануларын һәм мифологик образларын да кертеп җибәргән икән. Томшыгына “шарик”, дөресрәге бер чеметем җир капкан үрдәк образын галим шуларның бер үрнәге итеп карый[2]. Утызынчы елларда храм диварлары архитектурасын өйрәнү белән шөгыльләнгән Австрия галиме Ф.Халле Идел-Кама болгарларының мифология элементларын 1194-1197 елларда Владимирда төзелгән Дмитрий соборы бизәкләрендә һәм кабарынкы-рельефлы итеп эшләнгән аерым хайван сүрәтләрендә дә күрә[3]. Ләкин сүз бара торган Георгий һәм Дмитрий соборлары фасадындагы һәм диварларындагы барс, бүре һәм башка образларны эченә алучы сурәтләр-бизәкләр арасында әлеге галимнәрнең игътибарыннан читтә калган сазаган образлары да бар. Без рус-славяннар өчен чит, дошман булган әлеге образларны да болгардан килгән дип исәплибез. Бу инде, димәк, болгарлар ата-бабаларыннан ук дәвам итүче елан-сазаган сынын, башка образлары белән бергә, үзләренең кул тамгалары һәм этник мөһерләре рәвешендә рус храмнары диварларына да уеп калдырганнар дигән сүз.

Яки хәзергә киң җәмәгатьчелеккә билгеле булмаган икенче бер кызыклы мисал. Англия сәяхәтчесе Антоний Дженкинсонның язуына караганда, Иван Грозный оештырган тантаналы кабул итү мәҗлесендә ул алтын кубоклар һәм кечкенә көмеш мичкәләр арасына кыйммәтле экспонат рәвешендә куелган “берничә манаралы, өске өлешендә сазаган башлары ясалган алтын әйбер”гә игътибар итә[4]. Палата уртасындагы махсус өстәл-күперчек өстенә урнаштырылган әлеге антиквар әйбер дә, безнең уебызча, Казанны алганда руслар кулына төшкән трофей байлыгы. Ник дигәндә, әлеге кабул итү мәҗлесендә Казан ягыннан Сөембикәнең әсирлектәге улы Үтәмешгәрәй дә катнаша һәм ул да асылда Мәскәүнең Казанны җиңүен күрсәтү-демонстрацияләү өчен җанлы экспонат итеп Иван Грозный янына утыртылган була. Явыз Иван үзе исә күргәзмә экспонатлар фонында башына кигән “татар стилендәге

---

[1] Татищев В.Н. История Российская/ В.Н. Татищев. –Спб., 1877. – Т.3. – С.226.
[2] Рыбаков Б.А. Күрсәтелгән хезмәт/ Б.А. Рыбаков. – Б. 629.
[3] Вагнер Г.К. Скульптура Древней Руси/ Г.К. Вагнер. – С.27-28.
[4] Английские путешественники в Московском государстве в XVI веке. – Л.,1938. – С.87-88.

таҗ”да күрсәтелә[1]. Хәзерге вакытта Кораллар палатасында саклаучы һәм “Казан бүреге” дип аталучы әлеге таҗның да трофей экспонат булуы шиксез. Татар галимнәренең фикеренчә, асыл ташлар белән бизәлгән һәм саф алтыннан эшләнгән әлеге таҗ-бүрек Казан ханнарыныкы булган.

Әгәр без татар фольклорында, дөресрәге – “Дәфтәре Чынгызнамә” җыентыгында (XVIII йөз) борынгы чыганакка нигезләнеп теркәлгән тагын бер үзенчәлекле елан булуына тукталмасак, елан-сазаган турындагы җирле архаик мәгълүматларыбыз тулы булмас иде. Бу хакта җыентыкның икенче бүлегендә болай диелә: “Бараҗ халкының әүвәл замандагы борынгы төп йорты ошбу Зәй тамагында булыр иде (Зәй – Каманың сул кушылдыгы. – М.Б.). Алыплар заманы иде. Бер Бараҗ дигән аждаһа елан килде. Ул шәһәрнең халкына көч-зыян кыла башлады. Чыгып аждаһа белән сугыштылар, җиңә алмадылар. Ахыры үзләре шәһәрен салып качтылар. Болгар шәһәре якынына барып Бүләр суының өстенә йорт салдылар. Ул шәһәрләрен Бүләр дип атадылар. Ул сәбәптән халыкны Бараҗ халкы диер иделәр. Ораннары Бараҗ иде”[2].

Аерым галимнәр (мәсәлән, Әмир Нәҗип) тарафыннан әкият, чеп-чи фантастика итеп кенә карала торган әлеге риваятьнең дә, безнеңчә, югарыда саналган легендар фактларныкы кебек үк, реаль җирлеге булырга тиеш. Кемнәр соң алар Зәй буенда пәйда булган елан исемен алган бараҗ халкы? XII-XV йөзләргә караучы фарсы чыганакларында Бараҗ Нух углы Яфәснең төрле төрки кабиләләргә нигез салучы унбер улының берсе итеп бирелә, ягъни эпоним сыйфатында телгә алына[3].

Әмма, безнең карашыбызча, бараҗлыларның башта яшәгән җирлеген Зәй буе белән генә бәйләп калдыру җитми. “Дәфтәре Чыңгыз-намә” җыентыгындагы Зәйдә пәйда булган Бараҗ еланы турындагы легенданы Мәхмүд Кашгари, әл-Мәрзәви, Гардизи мәгълүматлары белән бәйләгәндә, бараҗ халкын кимак-кыпчаклар берләшмәсендәге елан кабиләсе белән мөнәсәбәттә карарга да нигез бар. Кашгари сүзлегендә мондый кызыклы мәгълүмат теркәлеп калган: “Бука – большая змея. В пословице говорится: “У змеи семь голов”. Иногда этим словом называют героев, подобно тому, так называли одного из видных людей, ябагу Бука Будраҗ – с ним сражался Арслан-тегин – завоеватель с 40 тыс. мусульман, а неверных было 700 тыс.”[4]. Тарихчы С.Ахинжанов Бука Будраҗ җитәкчелек иткән әлеге халык җиде кабиләдән торучы кимаклар һәм кыпчаклар берләшмәсе булган дип исәпли һәм “у змеи семь голов” дигән әйтем еланга табынучы шул кабиләләр союзына карата кулланылган, ди[5]. Кашгари, күрәсең, үзенең язмасында ышбу берләшмә халкының Җидесу төбәгендәге караханилар династиясе идарәчесе Арслан-хан Сөләйман ибн Йосыф гаскәрләре белән бәрелешүе турында сүз алып бара булса кирәк. Һәрхәлдә, еланга табынучы каи-кимакларның һәм сазаганны изгеләштерүче кыпчакларның X йөз уртасыннан ук ислам кабул иткән караханилар белән оппозициядә булулары һәм җәйләрен аерым кыпчак-кимак ыруларының көтүлекләре белән Каманың/ Ак иделнең түбән агымына кадәр барып җитүләре тарихчыларга билгеле[6].

---

[1] Шунда ук. – Б. 88.
[2] Татар халык иҗаты. Риваятьләр һәм легендалар. – Б. 31-32, 297; Усманов М.А. Татарские исторические источники XVII-XVIII вв./ М.А. Усманов.– Казань: Изд.КГУ, 1972. – С.113.
[3] Шунда ук. – Б. 293-294.
[4] Мәхмүд Кошгари. Дивану лүготит түрк/ М. Кошгари. – Тошкент: Үзбек. ССР ФА нашр., 1963. – Т.3. – 247 б.
[5] Ахинжанов С.М. Из истории движения кочевых племен евразийских степей в первой половине XI в./ С.М. Ахинжанов// Археологические исследования древнего и средневекового Казахстана. – Алма-Ата: Изд. “Наука” Каз. ССР, 1980. – С.50-51; его же: Кыпчаки в истории средневекового Казахстана. – Алма-Ата: Изд. “Наука” Каз. ССР, 1989. –С.184-185.
[6] Шунда ук. – С. 184-185; Бартольд В.В. Сочинения/ ВВ. Бартольд. – М.: Наука, 1970. – Т. II. – С.46.

Без килгән нәтиҗәгә караганда, XI йөзнең башында һәм урталдарында, мөгаен, нәкъ менә Кашгари язган һәм шулай ук башка чыганакларда чагылган бәрелешләр аркасындадыр инде, кимак-кыпчакларның бер өлеше “Дәште кыпчак” биләмәләреннән Каманың сул (көньяк) кушылдыгы булган Зәй буйларында да басып кергән булырга тиеш. “Дәфтәре Чыңгыз-намә” әсәрендә легендар формада тасвирланган Бараҗ еланы, минем фикеремчә, менә шул читтән кергән елан халкын гәүдәләндерә. Соңыннан инде “бараҗ” атамасы җиңүчеләрнең исеме-эпонимы буларак җирле халыкның да исеменә һәм оранына әверелә[1]. (Оран/уран – сугышчан кычкыру-чакыру авазы, кабиләнең пароле).

Моның чыннан да шулай булуына, ягъни Бараҗның Болгар җиренә үтеп кергән елан халкын (reconstr. кимак-кыпчакларны) белдергәнлегенә ышану өчен, тарихи чыганаклардан төрле дәлилләр китерергә мөмкин. Шундыйлардан Риза Фәхретдинов архивында сакланган һәм тарихчы Миркасыйм Госманов тарафыннан тикшерелгән бараҗ ыруының (кабиләсенең) шәҗәрәсе аеруча игътибарга лаек[2]. Анда бараҗлыларның (белүебезчә, Бараҗ еланы турындагы риватьтә алар “алыплар заманында”, ягъни Болгар чорында Биләр шәһәренә нигез салучылар итеп күрсәтелә) Инсан-бәк шәхесе белән бәйле шәҗәрәсендә - Җадашбәктән башланган 20 буын конкрет кеше исемнәрендә (антропонимнарда) санап күрсәтелә. Егерме буын ул һәр буынга уртача 25-әр ел куеп исәпләгәндә 500 ел дигән сүз, һәм әлеге санны “Дәфтәре Чыңгыз-намә”нең якынча язылу чорыннан – 1650(±25) елдан чигергәндә 1150 еллар тирәсенә туры килгән ел исәбе килеп чыга. Бу дата гаҗәеп дәрәҗәдә караханилар идарәчесе Арслан-хан Сөләйман ибн Йосыф гаскәрләренең Мәхмүд Кашгарида күрсәтелгән Бука Будраҗ белән сугышуы һәм, минем фикеремчә, елан яугиләренең, җиңелгәч, өлешчә булса да, Зәй буена үтеп кергән вакытына туры килә. Менә Кашгари сүзлегендәге ул урын: “Всевышний обратил их в бегство в тот день, когда с ним сразился Арслан-тегин”[3].

Ике арадагы әлеге сугыш-бәрелешнең датасын исә шактый дөрес итеп казакъ тарихчысы С.М.Ахинжанов исәпләп чыгарган: “Согласно Кашгарскому, народ змей двинулся в поход при Арслан-тегине, т.е. где-то в промежутке между 1032-1057/58 гг., временем правления Арслан-хана”. “Точная дата выплывает при сопоставлении информации Махмуда Кашгарского с данными Абу-л Фараджа. В послании несторианского митрополита Самарнада католиксу, отправленном в 1046 г., говорится о появлении возле Кашгара (Кашгар – караханилар дәүләте шәһәре – М.Б.) неведомого до этого многочисленного кочевого народа, вышедшего из местности между Хотаном и Тибетом. Всадников было якобы 700000 под командованием семи царей”[4].

Димәк, Җидесу төбәгенә үтеп кергән елан кабиләләре (кимак-кыпчаклар) белән караханилар арасындагы сугыш үз чиратында Болгар җиренә бараҗлыларның (елан кабиләсенең) чынлап та бәреп керүенә китергән булып чыга түгелме?! Бараҗның Болгарга керү вакыты белән бараҗ шәҗәрәсе яшенең үзара ярашуы да, шулай ук әлеге уртак датаның Җидесу җирендә елан кабиләләренең караханилар белән орышу вакыты белән тәңгәл килүе дә әнә шундый зарури нәтиҗәгә китереп чыгара. Менә шуңа күрә дә 20 буынлы (!) шәҗәрәлере сакланган бараҗлыларны без, шәҗәрәгә

---

[1] Татар халык иҗаты. Риваятьләр һәм легендалар. – Б. 32.
[2] Усманов М.А. Татарские исторические источники XVII-XVIII вв./ М.А. Усманов. – Казань: Изд.КГУ, 1972. – С. 174-178.
[3] Мәхмүд Кошгари. Күрсәтелгән хезмәт/ М. Кошгари. - Б. 247.
[4] Ахинжанов С.М. Кипчаки в истории средневекового Казахстана/ С.М. Ахинжанов. – С.184-185; его же. Из истории движения кочевых племен евразийских степей в первой половине XI века. – С.53.

бәйле легендада Аксак Тимернең дә телгә алынуына карап кына (безнеңчә, бу кычкырып торсак анахронизм – даталар, вакыйгалар буталышы!) Алтын Урда дәверенә чигермичә, Болгар дәүләте чоры белән бәйләп карау дөреслеккә ныграк туры килә дип исәплибез.

Безнең нәтиҗәне куәтли торган охшаш, хәтта турыдан-туры тәңгәл килүче, башка төрле дәлилләр дә юк түгел. Мәсәлән, “Випасанк” дигән әрмән эпосында да Мидиянең еланга табынучы җирле халкы алмаш этноним белән “мар” дип исемләнә (мар – халык этимологиясе буенча һәм фарсыча “елан”), патшалары исә Аңдахак дип атала һәм иң характерлысы – әлеге эпос Тигран II-нең мидиялеләргә каршы сугышына мөнәсәбәтле тарихи вакыйгаларны гәүдәләндерә[1]. Яки менә турыдан-туры кыпчаклар һәм кыпчаклашкан кимаклар белән бәйләнешле саллы мисал. Сырдәрьяның түбән агымы буенда яшәүче җирле халыктан язып алынган риваятьтә XI йөздә Урта Азиядәге угызлар дәүләтен тар-мар иткән кыпчаклар һәм каи-кимаклар шулай ук еланга тиңләнә һәм Сырдәрья тамагындагы Джанкент (Янкент/Янгикент=Яңакент) шәһәре еланнар явыннан һәлак булды дип күрсәтелә[2]. “Каи” сүзенең мәгънәсе дә монголча елан дигәнгә туры килә һәм бу исем белән аталучы халыкның этник тамгасы да елан була. Шулай ук “Дәште кыпчак”та яшәгән “уран” кабиләсенең төркичә мәгънәсе дә - елан (>“ора”).

Италия сәяхәтчесе Марко Полоның юлъязмаларында теркәлгән мәгълүмат буенча (XIII йөз), безгә кыпчакларның Натигай исемле мәҗүси алласы булганлыгы да билгеле[3]. Себер татарларында әлеге исем “нацагай” рәвешендә сакланган, күктән елан шикелле бөгәрләнеп яки чатлы-ботлы булып төшкән яшенне белдерә[4]. Казан татарлары телендәге “нажагай” (варианты – “аҗаган”) сүзе дә шул ук тамырдан, игеннәр өлгергән вакытта төннәрен офыкта уйный торган яшенне шулай диләр. Бу сүзләрнең һәм шуларга бәйләнешле ышануларның нигезе дә елан-сазаганга барып тоташа. Чөнки әлеге канатлы һәм чуклы яки балык койрыклы илаһи зат күк һәм яшенне, явым-төшем һәм сулыкларны бергә бәйли торган образ итеп тә күз алдына китерелгән. Борынгыдан калган сынамышларны искә төшерик: а) Мәхмүд Кашгарида: “Ләү елы килсә, явым-төшем һәм уңыш күп буладыр, чөнки ул суда яши”[5]; б) халыкта: “Салават күперенең (resp. күк еланының) ике башы да суга төшсә, яңгыр булыр”.

Ләкин кыпчак-кимакларның Болгар җиренә монголлар явына кадәр үк үтеп керүен исбатларга ярдәм итә торган иң ышанычлы күрсәткеч, әлбәттә, тел. Менә монда инде безгә Болгар чорына бәйләнешле тел катламын нечкәләп һәм чагыштырып тикшергән Р.Г.Әхмәтҗанов, Ф.С.Хәкимҗанов һәм Д.Г.Мөхәммәтшин кебек күренекле телчеләрнең хезмәтләре җитди таяныч була ала. Үзләренең тикшеренүләрендә алар барысы да Болгар дәүләтенең үзәк шәһәрләре һәм көньяк, көньяк-көнбатыш биләмәләре монголлар килгәнче үк инде кыпчаклашкан булганнар дигән уртак нәтиҗәгә киләләр. Менә әлеге галимнәрнең хезмәтләреннән аерым өзекләр:

а) Р.Г.Әхмәтҗанов: “Племена, говорящие на языках кыпчакского (небулгарского) типа, были уже в составе булгарских племен, пришедших в Среднее Поволжье из Приазовья”. “Вышеприведенный комплекс западнокыпчакских,

---

[1] Мифы народов мира.Энциклопедия. – Т. I. – С. 50.
[2] Ахинжанов С.М. Кипчаки в истории Казахстана/ С.М. Ахинжанов. – С.188-189.
[3] Алексеев М.П. Сибирь в известиях западно-европейских путешественников и писателей. – Иркутск: ОГИЗ, 1941. – С.35
[4] Валеев Ф.Г. Западно-Сибирские татары/ Ф.Г. Валеев. – Казань: Тат.кн.изд., 1980. – С.199.
[5] Мәхмүд Кошгари. Күрсәтелгән хезмәт/ М. Кошгари. – Т. I. – Б. 330.

куманских слов, распространенных в Среднем Поволжье уже мусульманской Булгарии, говорит о том, что кыпчакоязычные предки татар жили в древней Булгарии и оказали огромное влияние на культуру местного населения". "Возможно даже, что центры Булгарского государства – города Булгар, Сувар и Биляр – к XII в. уже оказались кыпчакизированными". "В основной, заволжско-закамской части Булгарии к началу XIII в. кыпчакское население доминировало... Монгольское завоевание привело к еще большему усилению кипчакского элемента в Среднем Поволжье"[1].

б) Ф.С.Хәкимҗанов, Д.Г.Мөхәммәтшин: "Проникновение западных кипчаков в Волжскую Булгарию [происходило] с начала XI века (отдельные небольшие группы, видимо, были еще раньше в составе булгарского союза племен), которые занимались ремеслами, торговлей, земледелием и нанимались в армию. В летописях, например, имеется такой факт: во время похода русских князей на Великий город (то есть на Биляр) в 1183 году уже на булгарских землях к ним присоединились "емяковы половцы" во главе с булгарским князем. Это были йемеки. Одно из тюркских племен, входившее ранее в кимако-кипчакскую федерацию". "Считается, что к XII веку сформировался обобщенный тип речи более высокого порядка – булгарское наддиалектное койне общетюркского характера ... Его устная форма сложилась при подавляющем преимуществе кипчакских элементов, и она была созвучна с деловым языком Золотой Орды"[2].

Димәк, телчеләрнең мондый нәтиҗәләре легенда-риваятьтәге Бараҗ еланының кимак-кыпчакларны гәүдәләндерүе турындагы безнең карашны тагын да нигезлерәк, ышанычлырак итә. Безнең караш исә, үз чиратында, телчеләрнең нәтиҗәләрен куәтли. Дөрес, әлеге галимнәрнең концепциясендә без килешми торган эклектизм элементлары, нигезсез фаразлар да юк түгел. Мәсәлән, Р.Г.Әхмәтҗановның "татар этносының нигезе" Болгар дәүләте чорында ук барлыкка килгән дип раславы һәм Алтын Урда чорына бәйләнешле "монгол-татар нигезе"н санга сукмавы, татар халкының барлыкка килүендә әлеге ике катламның да бердәй роль уйнавын танымавы. Ләкин әлеге галимнәрнең карашлары болгар теле белән кыпчак-татар теле арасында тигезлек билгесе куймаулары, иске татар телен болгар теленең ("r – телнең") турыдан-туры дәвамы итеп карамаулары белән көчле. Ә бит "болгарчы" галимнәр һәм, гомумән, "болгарчылар" моның нәкъ киресен исбатларга һәм татар телен дә, татарларны да турыдан-туры болгарлардан чыгарырга тырышалар. Һәм өстәп әйтергә кирәк: аларның Болгар дәүләтендә, болгар этнос-кавеменнән тыш, кимак-кыпчаклар һәм өлешчә угызлар да булганлыгын танулары һәм иске татар теленең чишмә башын шул телләргә үк илтеп тоташтырулары, һичшиксез, халкыбыз һәм телебез тарихына иң дөрес якын килү булып тора. Менә шушы принципиаль аерманы аңламыйча, яңа буын галимнәрне Болгар дәүләте чорын халкыбызның тернәкләнү-этногенез этабыннан чыгарып ташларга маташулары бер чиктән икенче чиккә ташланудан башка нәрсә түгел. Минемчә, бу көнбатыштан кергән бер мәкальдә әйтелгәнчә, бала юындырган суны түгәм дип, тагарактагы баланы да су белән бергә түгү-ыргытып ташлау белән бер.

Тагын бер җитди өстәмә. Телчеләрдән академик Н.А.Басков белән Г.М.Гарипов татарларның килеп чыгышында кимак-кыпчаклар берләшмәсенә керүче йемәкләр

---

[1] Ахметзянов Р.Г. Сравнительное исследование татарского и чувашского языков/ Р.Г. Ахметзянов. – М.: Наука, 1978. – С.220, 239-240.

[2] Мухаметшин Д.Г., Хакимзянов Ф.С. Эпиграфические памятники города Булгара/ Д.Г. Мухаметшин, Ф.С. Хакимзянов. – Казань: Тат.гос.издат., 1987. – С.91-93.

аеруча зур роль уйнаган дип исәплиләр[1]. Р.Г.Әхмәтҗановның ачыклавынча, фарсы телле чыганакларда “йемәк” һәм “татар” вакыт-вакыт бер-берсен алмаштырып килгәннәр һәм, уртак нигездән чыккан кардәш телләр буларак, көнбатыш кыпчак теленә бик якын торганнар[2]. Күренекле телче Әмир Нәҗипнең бер үзенчәлекле тикшеренүе дә шушы ук рәткә килеп ялгана. Ул 1312 елда Әсир әд-Дин Әбү-Хайан исемле гарәп кешесе тарафыннан Мисырда төзелгән сүзлектә, “кыпчак”ныкы һәм “угыз”ныкы дигән язулардан тыш, бериш сүзләр янында “болгар”, “татар”, “токсуба”, “уйгыр” дигән билгемәләр булуына игътибар итә. Шунда ук “токсуба – кыпчак татарларының кабиләләре” (“племена из кыпчакских татар”) дигән үзенчәлекле гыйбарә булуын да күрсәтә. Галимнең чыгарган нәтиҗәсе кызыклы: “Это объяснение в свою очередь позволяет предполагать, что издавна в Дешти-кыпчак жили какие-то племена, которые называли себя татарами. Если так, то прибывшие в Египет во время правления султана Бейбарса (1259-1277) татарские эмиры (имена которых явно татарские – Кучкар Муган, Тангри-берди, Алабай) являлись коренными жителями кыпчакских степей. Следовательно, племена, носившие название татар, жили в Дешти-кыпчаке и до прихода монголов на эту территорию”[3]. Бу инде, димәк, югарыдагы мәгълүматлар монгол-“татарлар”га кадәр үк Болгар җиренә кыпчак-кимак (кимак йемәк) кабиләләре составында татар исемен йөртүче кавем-этносның да үтеп керү ихтималына юл калдыра дигән сүз. Ләкин “татар” этнонимының кыпчаклашкан болгарларга, шулай ук Идел-Кама буена кат-кат килеп төпләнгән кыпчак-кимакларларга карата кулланыла башлавы, һичшиксез, монгол-“татарлар”дан соңгы чорга туры килгән һәм гомумхалык исеме буларак акрынлап урнашкан. Һәм әйтергә кирәк: ерак бабаларында болгар каны да катнашканлыгын таныган аерым шәхесләр вакыт-вакыт архаик атама буларак “болгар” этнонимын да тәңгәл рәвештә кулланып килгәннәр.

Без сүзебезне, дөресрәге Болгар чорына бәйләнешле дәлилләребезне Алабугадан башлаган идек. Ахырда тагын бер кат шул төбәккә мөрәҗәгать итик һәм бу юлы Алабуга шәһәренең атамасына тукталыйк. Минем карашымча, әлеге атама да борынгы ышанулар һәм мифологик легендалар дөньясына алып бара. “Алабуга” сүзен гадәттә русча “окунь” дигән мәгънә белдерүче балык исеме белән бәйләп карыйлар, йә булмаса, җитдирәк фикер йөрткәндә, бу сүзне үгез мәгънәсен белдерүче сүзгә кайтарып калдыралар: димәк, Алабуга атамасы “ала үгез” дигәнне белдерә булып чыга. Ләкин, минем карашымча, тәкъдим ителә торган әлеге мәгънәләрнең берсе дә ышандырырлык түгел, чөнки алар тарихи географик реалийлар белән ярашмыйлар. Хәтта сүз барган балыкның башы үгез башына охшаган һәм шуңа “алабуга” (ала үгез) дип аталган тәкъдирдә дә ни өчен әлеге атаманың шәһәр исеме булып китүе аңлашылмый.

Минем фикеремчә, Алабуга – борынгы ике төрки сүздән ясалган катлаулы-кушма исем. Аның “ала” дигән беренче өлеше элек Үзәк һәм Урта Азия, Кавказда яшәгән һун-болгар бабаларыбызның телендә булган һәм соңрак чордагы төрки халыкларда сакланган. Ачыклап әйткәндә, Ашина ыруының беренче башлап чыккан төбәгенең исеме – Алашань[4]: әлеге атаманы төзүдә катнашкан һун-төрки сүзе “ала”

---

[1] Гарипов Т.М. Махмуд Кошгари и кыпчаксике языки Урало-Поволжья/ Т.М. Гарипов// Советская Тюркология. – Баку, 1972. - №1. – С.48-49.
[2] Ахметьянов Р.Г. Сравнительное исследование татарского и чувашского языков/ Р.Г. Ахметьянов. – С.21, 239.
[3] Наджип Э.Н. Тюркоязычный памятник XIV в. “Гулистан” Сейфа Сараи и его язык/ Э.Н. Наджип. – Алма-Ата: Изд. “Наука” Каз. ССР, 1975. – Ч. I. – С. 45-46.
[4] Гумилев Н.Г. Этническая история Тибета в I тыс. н.э. в связи с историей сопределенных стран / Н.Г. Гумилев// Центральная Азия и Тибет. – Новосибирск: Наука, 1972. – С.75.

да, кытай сүзе “шань” да тау мәгънәсен белдерә. Кыпчак семьялыгына керүче үзбәкләрдә, казакъларда һәм кыргызларда “ала” лексемасының борынгы мәгънәсе шулай ук “тау”. Кытай оронимы Тяньшаньның төрки атамалары Ала+таг, Ала+тоо, Ала+тау шушы ук сүз катнашында ясалган; димәк, әлеге исемнәрнең һәр ике яртысы да тау төшенчәсенә туры килә булып чыга. Аерым сүзләрнең баштагы эчтәлеге тоныклангач яисә онытылгач, аларга шул ук мәгънәле башка сүзләрнең катлы-катлы булып ялгануы борынгы топономик атамалар өчен, гомумән, гадәти күренеш ул. Алтай тавы, Памир системасына керүче Алай сырты, Төркия җирендәге Алаҗадаг, Алаҗаһөйүк исемле тау тезмәләре, Әрмәнстан территориясендәге әрмәнчә Араган, төрекчә Алагеоз дип йөртелә торган тау-калкулык исемнәре дә шул ук тамырдаш атамалар исемлеген дәвам итә. Моннан тыш, төрекмәннәрдә өсте тигез калкулыкны белдерүче “ала+н”, тауны белдерүче “ала+нг” сүзләре бар. Һәм, әлбәттә, Алтай телләренә керүче тунгус-манчжурларда калкулыкның – “ала”, монголларда тауның “ола” дип йөртелүе дә, һичшиксез, шушы ук рәткә, уртак тамырга килеп ялгана. Ләкин бу очракта иң әһәмиятлесе шунда: безне кызыксындырган Алабуга атамасы составында да, ягъни аның “ала” өлешендә, минем ышануымча, гасырлар тирәнлегеннән килүче шул ук сүз-тамыр һәм “тау” мәгънәсе ята.

Билгеле, “ала” сүзенең “пегий” дигән борынгы мәгънәсе дә юк түгел. “Алабуга” сүзенең “окунь” балыгын белдерүче вариантында ук нәкъ шул мәгънәдә килгән дә. Һәм әйтергә кирәк: Пермь һәм Чиләбе өлкәләрендәге Алабуга дип йөртелүче күлләр дә үз атамаларын, һичшиксез, суларында шул исемдәге балык булуына карап алганнар. Ә менә сулыкның түгел, ә Кама буендагы шәһәрнең балык исеме белән аталуы аек акылга сыймый. Шуңа күрә дә без “Алабуга”ны кушма исем итеп карыйбыз да һәм географик атамаларның мотлак рәвештә тарихи чынбарлык белән ярашырга тиешлегеннән чыгып, әлеге сүзнең икенче яртысын да җирле фактлар белән бәйләү – иң дөрес юл дип исәплибез.

Ачыклап әйткәндә, Алабуга сүзенең икенче яртысы – буга/ бука өлеше, алда XI йөз галиме Мәхмүд Кашгаридан китерелгән өзектә күрсәтелгәнчә, “зур елан” дигән мәгънәгә туры килә. Бука сүзе заманында Арал диңгезе буенда, Дон елгасының түбәнге өлешендә һәм Төньяк Кавказда яшәгән болгар кыпчак кабиләләре аша Көнбатыш Дагыстандагы аерым халыкларга да бераз үзгәргән формада үтеп кергән. Мәсәлән, аварларга якын торучы тиндаль/тиндин телендә “бека” – елан, ахвак телендә бека – елан, бежтин телендә “бекела” – елан, чеченнарда “бохалла” – шулай ук елан. Монда без борынгы чор өчен гадәти күренеш булган к һәм г (к=г) авазлары чиратлашуы белән очрашабыз. Чагыштырыгыз: баку/багу, арку/аргу – тау үзәне, йатак/йатаг, бу көн/бүген. Әлеге күренеш болгар чорындагы кабер ташы язмалары өчен дә хас: йекет/егет, токуз/тугыз, битик/битиг – язма, бәлүк/белегъ – билге. Болардан инде без тикшерә торган “буга” сүзенең “бука” белән аваздаш булуы, аның фонетик вариантын тәшкил итүе турында нәтиҗә чыгару кыен түгел.

Шулай итеп, без Алабуга атамасы ике өлештән, ягъни борынгы ике төрки сүздән тора дигән нәтиҗәгә киләбез. Аларның беренчесе, ала сүзе – “тау”, икенчесе, буга сүзе исә “елан” (“зур елан”) дигән мәгънәләргә туры килә, димәк, икесе бергә “Тау-елан” яки “Елан-тау” дигән мәгънәне белдерә булып чыга. Сүз тәртибе үзгәрә-алмашына торган гыйбарәләгә мөрәҗәгать итегез: Тимер-хан – Хан-тимер, Таң сылу - - сылу – сылу таң, көн озын – озын көн, язамын – мин язамын. Бу, әлбәттә, бик борынгы, архаик гыйбарә, мәгънәсе буенча ул соңгы дәверләрдә кулланыла торган “Елан-тау” (Елан тавы) атамасына туры килә. Димәк, “Алабуга” сүзенең без тәкъдим итә торган мәгънәсе-этимологиясе тулысынча тарихи һәм географик реалийлар

белән үзара ярашып тора, ягъни ул “Шайтан каласы”нда яшәүче елан-сазаган турындагы легендага да, шулай ук әлеге каланың шактый текә тау өстенә урнашкан булуына да һәм, әлбәттә, еланны изгеләштерүче болгар һәм кимак-кыпчакларның уртак мифологик карашларына да тәнгәл килә.

Инде төп нәтиҗәне ясыйк. Шулай итеп, тарихи фольклорыбыз һәм тел фактлары безне турыдан-туры яки урау юллар белән Болгар җирлегенә илтеп чыгара. Бу, һичшиксез, халык хәтеренең, тарихи аңның Болгар дәүләте тарихына һәм культурасына тоташуы белән бәйле. Алай гына да түгел, безнең этногенетик тамырларыбыз һәм этник аңыбыз да шунда тоташкан, кендегебез өлешчә булса да, шунда береккән. Чөнки Болгарның көньяк һәм көнчыгыш биләмәләренә үтеп кергән кимак-кыпчаклар һәм алар кыпчаклаштырган болгарлар татар этносының һәм иске татар теленең тернәкләнә башлавы өчен иң борынгы җирлек булганнар. Бу инде, димәк, бабаларыбызның иң тәүге буыннары тарихы һәм дәүләтчелегебезнең беренче этабы Болгар дәүләте чорына туры килгән дигән сүз.

*М.И.Ибрагимов,*
филология фәннәре кандидаты,
КДУның доценты

## *Поэтика мифа в современной татарской прозе*

В современной татарской литературе ведется поиск новых форм художественности, что в настоящий момент позволяет говорить о наметившихся тенденциях переходности в татарской литературе. Перед учеными, занимающимися изучением современной татарской литературы, стоит сложная задача - определение качественного своеобразия “переходности” в татарской литературе (а шире - культуре).

Авторитетный современный российский культуролог Н.А. Хренов в статье “Опыт культурологической интерпретации переходных процессов” выделяет ряд наиболее универсальных черт исторической переходности: изменения в отношениях человека к пространству и времени, активизацию мифа и архетипа, культ творчества, открытие логики “вечного возвращения”, эсхатологическое переживание истории, активизацию личности маргинального типа, кризис коллективной идентичности, автономизацию видов искусства и “ренессанс” эстетических теорий синтеза[1]. Принимая во внимание то обстоятельство, что данные универсалии были выделены ученым применительно к европейской культуре, но при этом, допуская возможность функционирования некоторых из них в культурах восточного типа, рассмотрим явление активизации мифа в современной татарской литературе.

Активизация мифа в современной татарской литературе наиболее ярко проявляется в произведениях исторической тематики, авторы которых обращаются к историческим мифам, преданиям, легендам (произведения М. Хабибуллина, Р. Батуллы, Р. Хамида, Н. Фаттаха, Ф. Латыйфи и др.). Обращение к историческим мифологемам в литературе конца XX века, очевидно, связано с социально-политическими процессами в нашей республике в 1990-ые годы, которые способствовали возрастанию интереса к периодам Волжской Булгарии и Казанского ханства.

С другой стороны, в современной литературе достаточно широко представлены мифоцентрические тексты (произведения А. Халима, Н. Гыйматдиновой, Г. Гильманова, Ф. Байрамовой), авторы которых в той или иной степени обращаются к мифологической архаике. В такого рода произведениях происходит сочетание реалистического и фантастико-мифологического пластов, что, как нам представляется, отражают суть переходных процессов в татарской литературе: с одной стороны, это стремление сохранить реалистичность, осветить наиболее злободневные проблемы современной действительности, с другой - поиск художественной новизны.

Появившееся в печати в 2001 году (журнал “Казан утлары” № 1-2) произведение Г. Гильманова “Албастылар” сразу привлекло к себе внимание

[1] Хренов Н.А. Опыт культурологической интерпретации переходных процессов// Искусство в ситуации смены циклов. Междисциплинарные аспекты исследования художественной культуры в переходных процессах/ Н.А. Хренов - М.: Наука, 2002. - С. 11 – 56.

исследователей. Несмотря на полярность существующих высказываний, исследователи сходятся во мнении, что “Албастылар” - наиболее яркий пример проявления мифоцентрических тенденций в современной литературе. Применительно к “Албастылар” можно говорить об авторской игре мифами и восходящими к мифологии мотивами, цель которой - придание своему произведению налета мистицизма, занимательности. Но в то же время за всеми неправдоподобными, фантастическими коллизиями скрывается авторская модель действительности, конструкция “новой реальности” происходит под влиянием авторских эстетических установок. Такая особенность находит проявление в многочисленных отступлениях лирического (а чаще - лирико-дидактического) характера, в которых предметом авторской рефлексии становятся и универсальные философские понятия (дорога, добро и зло, любовь, истина, надежда, душа), и некоторые значимые в татарском национальном сознании категории (например, “моң” или “**рух”)**. Помимо размышлений нравственно-философского характера, отступления содержат в себе восходящие к домусульманской мифологии метафизические представления, основу которых составляет пантеистическая идея всеединства: каждый феномен бытия (в первую очередь - природа и человек) оказывается связан с высшей божественной силой – Тэнгре (Тәңре).

В прозе Н. Гыйматдиновой мифоцентризм сводится к построению сюжета на коллизиях, в которых принимают участие некие мистические силы. Одним из наиболее распространенных мотивов в прозе писательницы становится мотив чудесного превращения героев в животных (“Болан”, “Каракош”, “Ак торна каргышы”), восходящий к архаическому тотемизму.

В повести “Ак торна каргышы” мифопоэтическая реконструкция позволяет выявить мотив «вторичного рождения», восходящий к древнейшим мифологическим представлениям об умирающем и воскресающем божестве. Любовь Арслана выступает как сила, возвращающая Сару к жизни, что находит отражение на пространственном (дихотомия закрытого (изба) и открытого (луг) пространств) и образном (образ-символ крыльев и связанная с ним идея возрождения становятся сквозным структурно-семантическим комплексом) уровнях. Противопоставлен мотиву «вторичного рождения» восходящий к эсхатологическим мифам мотив гибели, конца, который обыгрывается писательницей в мистическом ракурсе (после убийства одного из лебедей Сара исчезает).

Аналогичное столкновение мифопоэтических мотивов обнаруживается и в повести “Болан” (“Олень”), в которой счастье героев (Акчач и Рыскола) оказывается невозможным (как и в «Ак торна каргышы» финал в «Болан» по своей сути эсхатологичен). Эта повесть представляет интерес и с точки зрения «столкновения мифов». С одной стороны, это тэнгринианство, которое понимается воспитывающей Акчач бабушкой Сузгын как “правая” вера, противопоставленная извращенному современными людьми исламу. С другой - «миф» современного человека, верящего в свои неограниченные возможности, в свое право распоряжаться природой. Основная коллизия в повести заключается в стремлении Акчач примирить в своей душе “правду” бабушки и любовь к Рысколу. Вопреки всем запретам покойной Сузгын, Акчач решается совершить вместе с Рысколом ритуальное восхождение на священную для нее и бабушки гору (“Хуҗалар”), результатом которого становится физическое и духовное преображение героя. Однако повесть заканчивается трагически: Рыскол нарушает свою клятву не убивать животных и во время

последней охоты стреляет в олениху, в которую превратилась Акчач. Трагедия Рыскола, таким образом, предстает как следствие нарушения табу, основу которого составляет восходящее к мифологии представление о единстве человека и природы.

Если в творчестве Г. Гильманова и Н. Гыйматдиновой обнаруживается сознательная ориентация на миф, а их произведения по своей сути мифоцентричны, то в некоторых произведениях современной татарской прозы сказочно-мифологическая фантастика отсутствует, но при этом существует возможность мифопоэтической реконструкции. В этой связи хотелось бы заметить, что в отечественном литературоведении еще недостаточно распространен мифопоэтический анализ текста, предполагающий возможность обнаружения скрытых мифологических мотивов. Таким скрытым мифопоэтическим потенциалом обладает, в частности, повесть А. Халима “Өч аяклы ат”.

Важное место в повести с точки зрения раскрытия мифопоэтического контекста приобретает введенная в текст легенда. Согласно этой легенде, в давние-давние времена, когда в мире шла борьба между темными и светлыми силами, Мать-Земля родила сына, которому не нашлось места на кровавой земле и который, превратившись в звезду, вознесся на небо. Мальчик-звезда был вскормлен крылатой Кобылицей, за доброту которой Мать-Земля, якобы, наполнила ее утробу золотом. Узнавший об этом злой Див собирается проглотить Золотую Кобылицу, но оказывается обманутым юношей, который заводит его в ад, а Мать-Земля снова возносит своего крылатого сына на небо. Обманутый же Див с тех пор, якобы, строит всевозможные козни, желая разлучить мужчину и коня. Рассказанная Сами легенда становится идейно-эстетическим фокусом повести, заключающим в себя один из аспектов национальной картины мира: представление о нерасторжимом единстве человека и коня. В итоге, коллизии, происходящие в повести, вписываются не только в социально-исторический контекст, но и в мифопоэтический: все, что происходит с Кабиром во время пути становится своего рода иллюстрацией к данной легенде. Данная легенда сочетает в себе космогонический (объяснение происхождения звезд на небе), философский (представление об извечной борьбе сил добра с силами зла), ценностный аспекты Такого рода сочетание позволяет интерпретировать события, произошедшие с Кабиром, с точки зрения универсальных бытийных основ, не ограничиваясь конкретно-исторической проблематикой (изображение тоталитарной эпохи).

В то же время в сюжете повести обнаруживаются мифопоэтические мотивы, среди которых основное место занимает мотив пути. По существу, этот мотив может быть соотнесен с обрядом инициации, на что указывает акцентируемый автором мотив мужания героя. С другой стороны, в сюжете повести обнаруживаются и другие мотивы, восходящие к мифопоэтической традиции. В генетически связанных с мифологией волшебных сказках герою помогают в пути волшебные силы, зачастую представленные образами животных. В произведении А. Халима возникает обратная ситуация: Кабир сам помогает Бамбуку (делит с ним хлеб, перевязывает поврежденную ногу), стремясь довести лошадь до родной деревни. Такое переворачивание мифологического мотива, очевидно, объясняется стремлением автора усилить героический аспект в характере Кабира: через все испытания, выпадающие на его долю во время пути, герой проходит сам без вмешательства волшебных сил, что в итоге приводит к мифологизации Кабира (конюх Сами называет Кабира “Кан-Күрәзә”: так зовут мифологическую птицу, которая, якобы, возвращает хозяевам похищенных у них конокрадами лошадей).

Наконец, обратим внимание на финал повести, в котором присутствует мотив ритуального захоронения: Кабир вместе со своим другом Харисом хоронят сердце Бамбука. Этот мотив, с одной стороны, оказывается соотнесен с рассказанной Сами легендой, объясняющей происхождение звезд. С другой - восходит к мифопоэтической традиции: к календарным мифам об умирающих и воскресающих богах, отражающии древнейшие представления о цикличности природных процессов. В этой связи, несмотря на драматический финал повести, можно говорить о надежде автора на возрождение, на торжество сил света, добра над силами тьмы, зла (не случайно повесть заканчивается возвращением матери Кабира), что отличает данную повесть от произведений Н. Гыйматдиновой («Ак торна каргышы», «Болан»), развязка в которых эсхатологична.

И в “Ак торна каргышы”, и в повести “Болан”, и в «Албастылар» Г. Гильманова, да и в произведении А.Халима мифопоэтика выступает как художественный прием, позволяющий авторам выразить свое отношение к современной действительности, и дать образец правильной жизни. Иначе говоря, применительно к этим произведениям можно говорить о сохранении традиционной для татарской литературы нравственно-дидактической направленности, которая облекается в новую мифопоэтическую оболочку.

*Ф.Х.Завгарова,*
филология фәннәре кандидаты,
ТФДҮнең директоры

## *Татар халык әкиятләрендә җан мотивы*

Әкият - халык аваз иҗатының борынгы, шул ук вакыта киң таралган һәм мавыктыргыч жанрларының берсе.

Әкиятләрдә халыкның күп гасырлык тормыш тәҗрибәсеннән туган зирәклеге, тапкырлыгы, яхшылык һәм явызлык турындагы төшенчәләре тупланган, киләчәккә өмет һәм хыяллары чагылган.

Халык арасында кеше ышанмастай нәрсә сөйләнсә, гадәттә "әкият бу" диләр һәм еш кына сөйләм телендә "әкият" һәм "ялган" сүзләре синоним буларак кулланылалар. Бу, әлбәттә, әкиятләргә хас үзенчәлек – уйдырма булудан килеп чыга. Әкиятләрдәге уйдырмалылык каян килеп чыга соң? Аның тамырлары кайда? Бу сорауга җавап бирү өчен әкиятләрнең килеп чыгу юлын күзәтеп үтми мөмкин түгел.

Белгәнебезчә, әкиятләр кешелек тарихының бик борынгы заманнарында, әле җәмгыять сыйныфларга бүленмәгән дәверләрдә үк барлыкка килгән һәм борынгы кешенең практик максатлары – дөньяны танып белү, дөньяга караш чикләрендә чынбарлыкның төрле күренешләрен аңлату; көн итү эшчәнлегендә нәтиҗәлелеккә ирешу, табигый, рухи кыенлыкларны җиңәргә теләүгә хезмәт иткәннәр, ягъни гамәли вазыйфа башкарганнар.

Борынгы кеше дөньяның, кешенең һәм гомумән җанлы һәм җансыз табигатьнең барлыкка килүен, алар арасындагы мөнәсәбәтләрне, кешеләр тормышындагы төрле хәлләрне – барысын да – мифологик карашлар нигезендә аңлаган, һәм аларның аңлатмалары миф – мифик риваять формасында йөргән. Ул гына да түгел, аларның берсе изге итеп саналган. Алар теләсә кайчан, теләсә кемгә сөйләнмәгән. Мондый хикәяләрне сөйләү изге йоланы үтәү белән бергә алып барылган һәм бары тик балигъ булган кешеләргә генә җиткерелгән, ягъни мифлар ритуал белән тыгыз бәйләнештә булган. Гамәли вазыйфа үтәгән бу мифик риватьләрне галимнәр әкиятнең иң борынгы формасы буларак бәялиләр[1].

Иҗтимагый яшәешнең, матди җитештерүнең үсүе нәтиҗәсендә, кешенең рухи дөньясы киңәя һәм, шуның белән бәйле рәвештә, эстетик ихтыяҗ туа. Бу ихтыяҗны кәнәгатьләндерү өчен рухи азык, әлбәттә инде, шул чордагы бердәнбер чыганактан – идеологик синкретизмнан алынырга тиеш була. Ихтыяҗ үсүе төрлелеккә китерә һәм нәтиҗәдә идеологик синкретизм составындагы фольклористик яралгылардан төрле жанрлар үсеп чыга. Шуларның берсе - әкият[2].

Күренекле фольклорчы галим В.А.Пропп әйтүенчә, "әкиятнең туу вакыты – ул нәкъ менә шул хикәянең" (әкият "баба"сының) нәфис хикәягә әверелгән чагы[3], ягъни изге хикәянең мифик ритуалдан аерылуы. Чөнки йоланы барлыкка китергән шартлар вакытлар узу белән бетә, көнитеш яшәү чыганаклары үзгәреш кичерә, нәтиҗәдә, изге мәгънәдәге йоланың гамәли кыйммәте бетә. Йоладан аерылган хикәя

---

[1] Мелетинский Е.М. О генезисе и путях дифференциации эпических жанров. – Русский фольклор. Материалы исследования/ Е.М. Мелетинский. – М.-Л., 1960. - С. 86-87.
[2] Ярми Х. Татар халык иҗаты. Әкиятләр (беренче китап)/ Х. Ярми. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1977. – Б. 9.
[3] Пропп В.А. Собрание трудов/ Фолҗклор. Литература. История. – М.: "Лабиринт", 2002. – С. 178.

“изгелеген” җуеп, гомум мәнфәгатьтлегә әйләнә һәм барлык кешеләргә дә сөйләнә башлый. Әкиятнең шушы рәвешчә мөстәкыйль жанр булып формалашып җитүе борынгы ыруглык җәмгыятенең таркалу чорына туры килә[1]. Менә шул чордан башлап, әкият гамәлилектән арына һәм беренче чиратта эстетик вазыйфа үти башлый. Әлбәттә, аның әхлакый, социаль вазифалары да мөһим урын тота.

Шулай итеп, әкият идеологик синкретизм белән арасын өзә һәм, берничә гасыр дәвамында камилләшә барып, тулаем сәнгать өлкәсенә карый торган бүгенге матур әдәбият кебек үк, чын мәгънәсендәге, сәнгати эчтәлекле жанр булып җитешә.

Алда әйтеп үткәнебезчә, әкият сюжетында уйдырма мөһим урын били, ләкин уйдырманы фантазия җимеше дип кенә карау дөрес булмас, чөнки теләсә кайсы фантазия тормыш чынбарлыгы нигезендә генә барлыкка китерелә ала, икенче төрле әйтсәк, тормыш материалыннан башка уйдырма туа алмый. Ә кешелек үсешендә моңа җирлек искиткеч күп булган. Ырым-ышанулары ярдәме белән табигатькә, яшәешкә, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләргә тәэсир итү теләге адәм баласына әле дә чит түгел. Ә инде борынгы кеше үзенең яшәеш-көнкүрешен төрле ышануларга бай булган гаҗәеп күп йолалардан башка һичничек оештыра алмаган. Ул йолаларның иң киң таралганнарының берсе – үсмерләрне балигълык чорыннан олылар рәтенә күчерү (инициация) йоласы.

Үзенең кырыслыгы белән аерылып торган бу йоланың нигезендә яткан үсмерләрне урман эчендә урнашкан махсус йортка алып килеп, шунда беркадәр яшәү барышында төрле катлаулы сынаулар аркылы үткәрү һәм ыруның төрле закон-селәрен, изге мифларын сөйләү йолалары күп кенә тылсымлы әкиятләрнең мотивларына һәм сюжетларына кергән[2].

Борынгы кеше тотем хайван “йотып чыгаргач”, үзенә тотемның җаны керә дип исәпләгән, ягъни үлеп яңадан терелгәндә, кешенең җаны тотемга, ә тотемныкы кешегә күчә, ягъни кеше белән хайван арасында “җан алмашу” процессы башкарыла дип уйлаган[3]. Ул гына да түгел табигатьтәге һәрнәрсәне җанлы итеп күзаллау (анимизм) тәэсирендә җан гомумән мөстәкыйль субстанция буларак аңланган, ягъни кешенең һәм әйберләрнең җаны чыгып-кереп йөри дип исәпләнгән. Мәсәлән, җан вакытлыча чыкса – кеше йоклый, ә бөтенләй чыкса – үлә дип уйланган.

Абстракт фикер йөртү сәләте түбән булган борынгы кеше аңында җан матди әйбер буларак күзалланган. Аны күрергә, тотып карарга һәм кая да булса салып, теләсә кемнең кулы җитмәслек урында сакларга мөмкин дип уйлаган. Шуңа мөнәсәбәтле җанны кеше тәнендә генә түгел, аңардан тыш та яшәргә хокуклы, хәтта шулай булган очракта исән калырга, төрле куркынычлардан сакланырга мөмкин дип фаразлаганнар. Борынгы кеше фикеренчә, кеше үзенең җанын тәненнән тыш, аерым бер ышанычлы җирдә, мәсәлән, берәр хайван, үсемлек, предмет-әйбер эчендә саклый ала[4]. Әлеге борынгыларның ышанулары татар халкының тылсымлы экяитләрендә шактый кызыклы чыгылыш тапкан. Без аларны үзебезнең чыгышыбызда беркадәр барларбыз.

Халык әкиятләрендә җан мотивы чагылышын билгеләгәнче, татар телендә җан сүзенең нинди мәгънәләрдә яшәвен аңлап китү кирәктер. Моның өчен татар теленең аңлатмалы сүзлегенә мөрәҗәгать итик. Анда Җан:

---

[1] Мелетинский Е.М. Күрс.хезмәт/ Е.М. Мелетинский. – Б. 87.
[2] Пропп В.Я. Күрсәтелгән хезмәт/ В.Я. Пропп. – Б. 135.
[3] Дж.Фрезер. Золотая ветвь/ Дж. Фрэзер. Вып.IV. – М., 1928. – С. 216-227.
[4] Дж.Фрезер. Золотая ветвь. Вып.1/ Дж. Фрэзер. – С.193-194.

1. Тәнгә тереклек бирә һәм тәннән башка да яши ала дип каралган, тереклек иясенең психик процессларын чагылдырган мәңгелек башлангыч.
2. Кешенең эчке дөньясы: аның табигате, кичерешләре, хисләре, уй-фикере, омтылышлары.
3. Тереклек иясе.
4. Кеше.
5. Иң якын, кадерле кеше мәгънәләрендә кулланылуы санала[1]. Бу очракта без күчерелмә мәгънәдә куллану очраклары аңлатмаларына тукталмадык.

Күргәнебезчә, беренче аңлатмада җан төшенчәсе халыкның борынгы мифологик күзаллавына шактый якын. Бу якынлык халыкның мәкаль әйтемнәрендә дә искиткеч нык сизелә. Мәсәлән:

Бер тиен өчен җанын сатыр,
Бер тиене онытылып калса,
Йөз чакрым кире кайтыр.[2]

Ә җан мотивынна корылган әкиятләр һәм мәкальләр татар халкы авыз иҗатының шактый зур урынын биләп торалар.

Мотив латин теленнән аңлаганда, moveo – хәрәкәтләндерәм, motus – хәрәкәт мәгънәләрен белдерә, фәндә текст структурасының тотрыклы формаль компоненты буларак кабул ителә һәм фольклористикада XIX-XX гасырның күренекле белгечләре Н.Н.Веселовский, В.Я.Пропп хезмәтләреннән башлап, сюжетның иң кечкенә берәмлеге буларак аңлана. Бигрәк тә әкият, дастан кебек фольклор жанрларында сюжет коручы мотивларның билгеле бер төркеме бар. Алар теге яисә бу әсәр сюжетын кору берәмлекләре буларак чыгыш ясыйлар (мәсәлән, тылсымлы әкиятләрдә төп геройның нинди дә булса тылсымлы предмет ярдәмендә явыз көчне җиңә алуы, дастаннарда идеал геройның башкалардан камиллеге белән аерылып торуы). Мотивларның бу үзенчәлекләрен өйрәнгән галим Б.В.Томашевский аларны сюжетка береккән, ягъни сөйләүче әсәрнең сюжет эзлеклеген саклау өчен аларны һич төшереп калдыра алмый торганнарга һәм ирекле (телдән телгә сөйләгәндә җиңел төшеп калырга мөмкин булганнарга) аера.

Татар халык әкиятләрендәге җан мотивын береккән һәм ирекләләргә бүленүгә мөнәсәбәтле тикшереп карасак, тылсымлы әкиятләр сюжетында башлыча береккән, ягъни һичничек төшереп калдырырга мөмкин булмаган мотивлар булуын ачыкларбыз. Мәсәлән, “Утыз ул” әкиятендә дию тарафыннан урланган Сәхипҗамал аның җанының кая икәнен белү өчен: - мин бик куркам, җаныңны калдырыр идең, - дип үтенә. Дию аңа: “җаным әнә теге идән себерә торган себеркедә”, - ди. Сәхимҗамалның себеркене кочаклап утырганын күргәч, дию:

- Әй, җүләр, нигә минем җаным идән себеркесендә булсын инде, ди.

Дию Сәхипҗамалның хәйләсен белгәннән соң, кызны кыйный һәм Сәхипҗамалның: “көчеңне Батыр белән көрәшеп сынап кара”, дигән тәкъдименә җанының бик еракта, агач өстендә утыручы өч башлы кара елан астындагы кара мәче эчендә булуын әйтә[3].

Шушы ук мотивка корылган икенче бер “Унберенче Әхмәт”[4] әкиятендә дию урынына карт сурәтләнә, һәм урланган кыз картның җаны кайда булуын белү өчен шулай ук себеркене киендереп, матурлап качып утыра. Аның бу гамәлен күреп, карт

---

[1] Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. 3 томда.- Т.3. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1981. – Б. 745-746.
[2] Исәнбәт Н. Татар халык мәкальләре/ Н. Исәнбәт 3 томда. - Т.3. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1963. – Б. 770.
[3] **Татар халык иҗаты. Әкиятләр (беренче китап). – Казан: Тат.кит.нәшр., 1977. – Б. 138.**
[4] **Шунда ук. – Б. 286.**

җанның 150 чакрымда, читтә урнашкан бер күл утравы уртасындагы ояда утыручы үрдәк астындагы дүрт йомыркада булуын әйтә. Бу очракта да җан мотивы әкиятне тылсымлы итү өчен кирәкле шартта һәм аның сюжетының тотрыклы өлеше буларак чыгыш ясый. Мондый төр мотивларны “Өч дус”, “Турай батыр” кебек әкиятләрдә күрергә мөмкин.

Ә инде татар халык әкиятләрендә ирекле урын алучы җан мотивларын без бик күпләп көнкүреш әкиятләрендә күрә алабыз. Аларның ирекле булулары көнкүреш әкиятләренең соңрак, кешелекнең иҗтимагый яшәешендә социаль катламнар барлыкка килгәч, тууы белән аңлатыладыр. Бу чорда кеше аңы үсеп, җәмгыятьтә кешеләрнең үзара мөнәсәбәтләрен яхшырту, әхлак нормаларын саклау мәсьәләләре калкуырак күтәрелә башлый. Нәтиҗәдә, әкият мифологик аңны гына түгел, ә иҗтимагый аңны да чагылдыру коралына әверелә. Тылсымлы әкиятләрдән аермалы буларак, җан мотивы бу төр халык әсәрләрендә җан тәнгә кереп чыгып йөрергә мөмкин мөстәкыйль субстант буларак аңлану белән бергә тәнгә тереклек, хәрәкәт бирә торган башлангыч мәгънәсендә кулланыла башлый. Мәсәлән, “Аучы сөйли”, “Шамак карак”, “Кулсыз кул”, “Чуен бабай” кебек әкиятләрдә җан мотивы нәкъ шул мәгънәне били (мисал “Аучы сөйли” әкиятендә аучы отып төшергән кош киекләре турында: “... Барып карадым, үрдәкләрнең икесе үлгән, берсе җансыз...” ди). Әлеге әкиятләрдә бу мотивларны рәхәтләнеп төшереп калдырырга да, үзгәртергә, икенчегә алыштырырга да мөмкин. Чөнки аларның төп мәгънәләре мифологик күзаллауга түгел, ә иҗтимагый яшәешкә бәйләнгән. Шунлыктан алар сюжет коруның мәҗбүри элементы буларак чыгыш ясый алмыйлар.

Көнкүреш әкиятләрен өйрәнү структурасында үзенчәлекле җан мотивы булган тагын бер төркем әкиятләр бар. Аларга “Әби белән бабай”, “Бием белән килен”, “Йорт тотмас” тибындагы әкиятләр керә. Бу әкиятләрдә җан алу мотивы үзәккә алына. Җанны тылсымлы әкиятләрдәге кебек, нинди дә булса төп герой түгел, ә Газраил, персонажга сабак бирү мәнфәгатьләреннән, кылган гамәлләренә бәя бирү максатларыннан хөкем чыгаручы алырга тиеш. Ләкин әкиятләр сюжетында Газраил җанны алмый, ә алу мөмкинлеге барлыгы белән персонажны кисәтә, әкиятнең моралеен чыгара.

Шулай итеп, татар халык әкиятләрендә җан мотивы кешелек аңы үсә баруга мөнәсәбәтле үзгәреш кичерсә дә, тылсымлы әкиятләрдә тотрыклы, ә көнкүреш әкиятләрдә ирекле, үзгәрергә, төшеп калырга мөмкиннәр.

*Л.Х.Дәүләтшина,*
КДУның аспиранты,
ТФДҮнең редакторы

## *Архетиплар һәм аларның татар халык әкиятләрендә чагылышы*

Дөнья һәм рус әдәбият белемендә архетиплар мәсьәләсе актуаль һәм заманча саналса да, татар әдәбият белеме бүгенге көнгә кадәр бу проблемага тиешенчә игътибар бирми килде. Чынлыкта әлеге проблема иң элек кеше психикасында урын алган һәм гасырлар буе тормышта, иҗади процесста үзен сиздереп килгән мәңгелек төшенчәләргә кагыла. Ауропа галимнәре белән беррәттән, рус теоретиклары да бу юнәлештә нәтиҗәле тикшеренүләр алып баралар һәм фольклор әсәрләрендә, язучыларның иҗатында архетипик образларның мөһим урын алып торуын ассызыклап үтәләр[1]. Архетиплар ярдәмендә халыкның миф, әкият, йола һәм ырымнары арасындагы уртаклыкларны аңлату мөмкинлеге татар әдәбият белемендә дә бу юнәлешкә керергә вакыт җиткәнлеген искәртә.

Кеше психикасында гасырлар дәвамында калыпланган архетиплар, иң беренче чиратта, спонтан рәвештә аң төпкелендә «борынгы чорда» туган мифология, йола, әкиятләр, төш юрауларда чагылыш таба. Шуңа күрә дә безне иң элек татар халык авыз иҗатына, аерым алганда әкиятләргә күзәтү ясау һәм архетипларның анда яшәү-яшәмәвен ачыклау кызыксындыра.

Архетип төшенчәсенең барлыкка килүе швейцар психологы — З.Фрейдның дәвамчысы К.Г. Юнг исеме белән бәйле[2]. Аның хезмәтләрендә архетип төшенчәсе психологиянең бер элементы буларак гамәлгә керә, соңрак исә әлеге теоретик төшенчәнең кулланылыш даирәсе киңәя һәм әдәбият белемен дә үз эченә ала.

К.Г.Юнг гыйльми эшчәнлегенең башында З.Фрейд идеяләренә нигезләнеп эш итә, әмма соңрак барлыкка килгән аналитик психология һәм, аерым алганда, архетиплар теориясе остазының фикерләренә каршылыкта туа. К.Г.Юнг эчке субъектив тәҗрибә күзаллауларына туры калган психоанализга һәм З.Фрейдның һәр күренешне «сексуаль энергиянең” чагылышы дип аңлатуына тәнкыйть күзлегеннән карый.

Галим-психолог кешеләрнең хыялларын, төшләрен, эш, тормыш, яшәү рәвеше белән бәйле йола–ритуалларны һәм миф, легенда, әкият кебек иҗат төрләрен анализлаганнан соң, һәрбер кеше өчен уртак мотивлар бар дигән нәтиҗәгә килә. Бу күренешне кешелек дөньясының үсеш законнары белән логик яктан аңлатырга тырышу кыенлыклар тудырганга күрә, психолог кеше психикасына мөрәҗәгать итеп, аңлы һәм аңсыз халәтләрне аерып чыгара. Аныңча, аңсыз халәт шәхси һәм күмәк аңсыз халәтләрне үз эченә ала.[3]

---

[1] Бахтин М.М. Проблемы творчества Достоевского/ М.М. Бахтин. — Киев, 1994; Лотман Ю.М. В школе поэтического слова. Пушкин. Лермонтов. Гоголь: Книга для учителя/ Ю.М. Лотман. — М., 1988; Мелетинский Е.М. О литературных архетипах/ Е.М. Мелетинский. — М., 1994; Топоров В.Н. Странный Тургенев (Четыре главы)/ В.Н. Топоров. — М., 1998.

[2] Аналитическая психология и психотерапия / Сост. и общ. ред. В.М. Лейбина. – СПб., 2001; Юнг К.Г. Душа и миф: шесть архетипов/ К.Г. Юнг / Пер. с англ. А.А. Юдина. – Киев, М., 1997; Юнг К.Г. Избранное/ К.Г. Юнг / Пер. с нем. Е.Б. Глушак, Г.А. Бутузов, М.А. Собуцкий, О.О. Чистяков. – Минск, 1998.

[3] Аналитическая психология и психотерапия/ Сост. и общ. ред. В.М. Лейбина — СПб., 1998. — С. 37.

Кешелекнең коллектив аңсыз халәте гасырлар буе тупланган психологик тәҗрибәне үзенә сеңдерә һәм архетиплар формасында кеше аңында чагылыш таба. Халыкларның югалган аңсыз хәтере гасырлар дәвамында тулылана, баетыла барып, һәрбер халыкның дөньяга карашын , ышануларын, шатлыгын-хәсрәтен үзенә туплый һәм аңсыз халәттә архетипик хәтер, сурәт рәвешендә гәүдәләнә.

Архетипик хәтерне сеңдергән һәм аңга бәйсез рәвештә туган чыганакларның берсе — төшләр. Төрле халыкларның төш юрауларында еллар дәвамында тупланган тәҗрибә белән бүгенге көндә бер-берсе белән бөтенләй таныш булмаган кешеләрнең төшләре, матур әдәбият һәм сәнгать әсәрләрендәге образлар арасында табылган уртаклыклар әдәби әсәрләрдә дә архетиплар турында фикер йөртергә мөмкинлек бирә. Кеше психикасының асылын оештыручы аңсыз халәт һәрвакыт тормыш-яшәештә үзен сиздереп тора, интуитив рәвештә эшләнгән эшләрне, аңга бәйсез сөенү-көенүләрне билгели һәм ахыр чиктә кешенең шәхси тормышын оештыруына тәэсир итә.

К.Г.Юнг кеше психикасын анализлау процессында «архетиплар – геннар дәрәҗесендә кеше психикасында урнашкан инстинктив формалар, схемалар ул», дигән нәтиҗәгә килә[1]. Әлеге формалар кеше аңына үтеп кереп, рухи тәҗрибә күзаллаулары белән кушылганнан, баетылганнан соң гына, образлар, картиналар, уйдырмалар рәвешендә реальләшәләр.

К.Г.Юнг фикеренчә, архетипларны дәлилләү шактый катлаулы эшләрнең берсе булса да, аналитик психологиядә архетипның берничә төре төсмерләнә. Бөек Ана, Күләгә, Маска, Бала, Трикстер, Персона, Анима/Анимус, Рух, Үлеп терелү (Трансформация), Үзлек кебек архетипларны типик тормыш ситуацияләреннән чыгып бәяләү гамәлгә кергән. Аналитик психологиядә архетиплар иерархиясе рухи бөтенлекне тәэмин итүче Үзлеккә таба урнаша. «Үзлек кешенең дөньяда үз-үзен билгеләү принцибына нигезләнә, аңлы һәм аңсыз халәтнең бөтенлеген чагылдыра, димәк, кеше шәхесенең рухи үсешендә Үзлек максат буларак билгеләнә ала.»[2] Үзлек рәвешендә күзалланган рухи бөтенлеккә ирешү аңсыз халәт күренешләрен аңлы тормышка буйсындыруга тиң, ягъни кеше индивидуация процессында тискәре сыйфатларын, психиканың караңгы якларын да үз файдасына борып камил шәхескә әверелә ала. Әлеге үсеш юлы трансформация архетибы буларак билгеләнә һәм дөнья әдәбиятында үлеп терелү мотивы белән тоташа.

Архетип эчтәлексез гомуми буш форма буларак, кеше аңында чагылыш тапканнан соң, билгеле бер эчтәлеккә ия була һәм архетипик образ рәвешендә күзаллана башлый. Архетип һәм архетипик образларны аерып карау процессында архетипларның берничә генә булып, бары тик кеше психикасында яшәүләре, рухи эшчәнлектә гәүдәләнгән архетипларның исә образга әйләнүе, ә образларның, үз чиратында, күптөрле булуы турында нәтиҗә ясала. Шулай итеп, төш, әкият, миф, әдәби әсәрләрдә табылган архетипларны архетипик образлар дип йөртү дөресрәк булыр.

Архетипларны нәзари нигезләү процессында К.Г.Юнг милли архетипларны аерып чыгармый, чөнки, аныңча, алар юк. Бу фикер белән бер яктан гына килешергә мөмкин, чөнки кешелекнең аңсыз халәте уртак булса да, һәрбер халыкта архетиплар үзенчәлекле рәвештә туа ала. Әйтик, Ана, Бала төшенчәләре барлык халыкларда яшәп килә, ә Трикстер архетибы аерым бер милләттә гәүдәләнеш тапмаска да

---

Литературный энциклопедический словарь. — М., 1987. — С. 38.

[2] Человек и его символы/ Юнг К.Г., фон Франц. – М. – Л., Хендерсон Дж.Л., Якоби И., Яффе А. – М.: Серебр. нити, 1997. – С. 93.

мөмкин. Димәк, архетиплар — гомүмкешелек өчен хас күренешләр, шулай да аларның аерым бер халык аңында яшәү мөмкинлеге һәрбер милләтнең дөньяны күзаллавына бәйле.

Кешелек тарихында күңелләрне тетрәндергән, тормыш-яшәешкә көч-дәрт биргән, яктылык сирпегән матур әдәбият әсәрләрен, җанга-бәгырьгә якын халык авыз иҗаты җәүһәрләрен берничә архетип җыелмасына гына кайтарып калдыру мөмкинлеге, әлбәттә, шик уята. Һәрбер халыкның гасырлар дәвамында тормыш шартларына, көнкүрешенә бәйле рәвештә милли аңнары формалашу бәхәссез. Психологиядә этник стереотип, ягъни бер халыкның, бер этносның дөньяны кабул итүен, мәдәни-психологик үзенчәлекләрен, рухи кыйммәтләр җыелмасын тәшкил иткән төшенчә кулланылышка кереп бара.[1] Һәрбер халык үзенә генә хас, кабатланмас сыйфатларга ия була һәм шул рәвешле бер халыкның милли характер үзенчәлекләре туа, ә ул үз чиратында милләтнең сәнгатен, дөньяга карашын, үз-үзен тотышын билгели. Архетипларның аңлы күзаллаулар белән кушылганнан соң гына эчтәлеккә ия булуы алардан һәрбер кешенең субъектив кичерешләре белән бергә милли карашларны да сеңдерүен һәм милли архетипик образлар булып реальләшүен таләп итә. Коллектив аңсыз халәтнең эчтәлексез буш элементы буларак туган архетипларның сәнгатьтә, иҗатта тормышка ашырылуы милли үзенчәлекләр белән үрелеп, бер халык менталитетына хас архетипик образларны барлыкка китерә. Шулай итеп, архетипларның кешелек тарихының архаик катламнарына барып тоташуы һәм бер халык әдәбиятының милли үзенчәлекләрен билгеләргә мөмкинлек бирүе ышандыра.

Югалган аңсыз хәтер рәвешендә күзалланган архетиплар рухи эшчәнлекнең төрле формаларында, аеруча ритуал һәм мифларда таралыш таба. Чынбарлыкка, әйләнә-тирә мөхиткә нигезләнгән, тәртипсез рәвештә алып барылган тормышны җайга салган йолалар арасында иң әһәмиятлеләре — инициация, календарь һәм туй йолалары.

Йола-ритуал белән тыгыз бәйләнештә яшәгән мифология борынгы кешенең тирә-якны һәм үзен аңларга омтылуы, исән калу һәм яшәү хакына кырыс тирәлеккә яраширга тырышуы нәтиҗәсендә барлыкка килә һәм дөньяга күп төрле карашын билгели, әмма мифларда чынбарлык аңлы рәвештә түгел, ә бәлки күмәк аңсыз халәтнең барлыгы аша үткәрелеп, кешелек дөньясының психологик тәҗрибәсе — архетиплары аша чагылыш таба.

Төрки-татар мифологиясендә архетипларның чыганагын космогоник, антропогоник, эсхатологик, генеалогик мифлар тәшкил итә. Төрки халыкларның мифлары нигезендә тәңгәллек принцибы ятуы архетипларның түбән рухлардан югары көчкә — Тәңрегә таба хәрәкәтен тәэмин итә. Кеше күңеленең бөтенлегенә җавап бирүче илаһи Тәңре һәм Умай образлары Үзлекнең чагылышы булып исәпләнсә, түбән дөнья аллалары күптөрле архетиплар иерархиясен билгели. Мифларга күзәтү ясаганда, Ай, Ут — Үзлек; Убыр, Албасты — Ана; Шәке, Урман Тәңресе — Рух кебек тәңгәллекләрне күрсәтергә мөмкин.

Гамәли вазыйфа үтәгән мифология — әкиятнең иң борынгы формасы. «Әкият ритуалдан аерылгач, изгелеген җуеп, барлык кешеләр өчен сөйләнелә башлый һәм художестволы жанр булып җитешә.»[2] Фольклор әсәрләренең бу төрендә сөйләүченең тормышка шәхси мөнәсәбәте чагылмый, шуңа күрә әкиятләр

[1] Нартова-Бочавер С. Психология отношений/ С. Нартова-Бочавер. — М.: Изд-во ЭКСМО-Пресс, 2001. — С. 416. (Серия «Психология – 20 век»).
[2] Мелетинский Е.М. Герой волшебной сказки/ Е.М. Мелетинский. — М.: Изд-во восточной литературы, 1958. – С.9.

архетипларны аерым бер кешенең тормыш тәҗрибәсенә буйсынмаган хәлдә, үзгәртүсез тасвирлаулары белән кызыклы.

Төрле халыкларның әкиятләрен күзәткәндә, алардагы сюжет һәм мотивларның бер-берсенә гаять охшашлыгы игътибарны җәлеп итә. Бу хәл үзе үк әкиятнең бер тамырдан булуы турында сөйли.Академик А.Н.Веселовский күрсәткәнчә, кешелек үсешенең беренче чорларында көнкүреш яки психологик шартларның охшашлыгы, бердәмлеге нәтиҗәсендә күп кенә охшаш мотив һәм сюжетлар мөстәкыйль рәвештә барлыкка килә алган[1]. Шуңа күрә дә әкиятләр гомумкешелек өчен хас архетипларның чыганагы буларак өйрәнүдә әһәмиятле.

Тылсымлы әкиятләр жанрның башка төрләре арасында сихри күәткә, мәңгелек кыймматләргә ия булуы белән аерылып торалар. Бу төрдәге әкиятләрдә герой бик күп кыенлыкларга очрый. Максатына ирешү юлында аңа күп вакыт ярдәмчеләр булыша. Ярдәмчеләр сыйфатында гади кешеләр (юлаучы карт, асрау кыз һ.б.), шулай үк гадәттән тыш сәләткә ия булган әкият батырлары (зур агачларны йолкып атучы, күп ашаучы һәм күп эчүче, гаять төз атучы) катнашкан кебек, хайван, кош затыннан булган төрле персонажлар да зур урын алып тора[2].

Татар халык әкиятләрендә герой авыр хәлдә калганда, күпчелек очракта аңа карт бабай ярдәмгә килә һәм киңәше белән котылу юлын күрсәтә. “Аучы егет” әкиятендә ак сакаллы карт, аучыга куркыныч җанварның тиресен тунарга ярдәм итә[3]. Татар  халык әкиятләренең тагын берсе — «Камыр батыр»да геройга юлында «эшләпәсен кырын салган ак сакаллы карт» очрый. Әлеге карт үлемгә дучар ителгән Камыр батырга инициация белән бәйле сынауны үтәргә булыша һәм аны бәладән коткара. Югарыдагы әкиятләрдә искә алынган ак сакаллы карт образы авыр хәлдән котылу юлын күрсәтүе, киңәш бирүе белән Рух архетибына якын тора дип әйтергә нигез бар. Юнг хезмәтләрендә әлеге сыйфатлар нәкъ менә Рух архетибына мөнәсәбәтле рәвештә ачыклана.

К.Г.Юнг фикеренчә, әкиятләрдә еш кына карт, геройны уйландырыр өчен сораулар бирә һәм аны уңышка алып килүче сихерле әйбер белән бүләкли. Татар халык әкиятләрендә геройның тылсымлы әйбердән файдалануын һәм аның, гадәттә, эпизодик персонаждан (бүләк бирүчедән) алынуын Л.Җамалетдинов искәртә.[4] Рух архетибының архетипик образы булган карт «Унберенче Әхмәт» әкиятендә Әхмәткә юл өйрәтеп җибәрә һәм егеткә кульяулык, тарак, көзге бирә.  Шулай итеп, әлеге образ акыллы киңәше белән генә ярдәм итеп  калмыйча, әкият героен авырлыклардан котылу тылсымнары белән дә тәэмин итә.

Әкиятләрдә карт, әкият каһарманнарының әхлагын да тикшерә. «Өч карт» әкиятендә үги анасы кызны урманга каен җиләгенә җибәрә. Кыз урманда өч карт белән очраша, һәм алар төрле сынаулар аша үткәргәннән соң,  аңа тормышында бәхет-шатлык теләп калалар, кызны яхшылыгы өчен бүләклиләр,ә начар кызны исә, киресенчә, каргыйлар. Кешеләрнең әхлак дәрәҗәләрен тикшерүче әлеге картларның һәрвакыт диярлек урманда очрауларын исәпкә алсак, тылсымлы әкиятләрнең күбесенә хас үзенчәлек күзгә ташлана: герой һәрвакыт диярлек урманга барып чыга. Ә урман — балигълык йоласы башкарыла торган урын булу белән бергә, борынгы

---

[1] Җамалетдинов Л.Ш. Тылсымлы әкиятләр// Татар халык иҗаты. Әкиятләр/ Л.Ш. Җамалетдинов. - Казан. — 2 китап. – 1978. – Б. 17.

[2] Җамалетдинов Л.Ш. Әкиятләр/ Л.Ш. Җамалетдинов. – Б. 19.

[3] Мисаллар һәм љземтәләр” Әкиятләр”нең беренче һәм икенче китабыннан (Казан,1977; 1978) алынды.

[4] Җамалетдинов Л.Ш.Әкиятләр/ Л.Ш. Җамалетдинов. – Б. 20.

кешеләр фикеренчә, үлеләр дөньясына керү юлы да[1]. Үлеләр дөньясы — караңгы көчләрнең туплану урыны — кешенең акылына буйсынмаган куркыныч яшәешенә тиң булганга күрә, аңсыз халәт кебек үк чынбарлыкны билгели. Картның урманда очравы үзе үк аның Рух архетибы булуын дәлилли. Димәк, татар халык экиятләрендә еш очраучы, экият геройларына һәрвакыт ярдәмгә килеп,үз уллары кебек кабул итүче, аларны тылсымлы әйберләр белән бүләкләүче,геройның әхлак дәрәҗәсен тикшерүче карт образы Рух архетибына якын торганга күрә, аның образлы-әдәби чагылышы буларак исәпләнергә хаклы.

Рух архетибы турында сүз алып барганда, картның һәрвакыт диярлек ак сакаллы һәм ак киемнән булуын, әмма йөз-кыяфәте тәфсилле сурәтләнмәвен дә искәртү урынлы. Рух архетибының әлеге сыйфаты күпчелек экиятләрдә урын алып, татар сүз сәнгатенә дә килеп керә,үстерелә.

Ф.И.Урманчеев фикеренчә, фольклорда ак төс элек яхшы тормыш, бәхет, бәйрәм белән бәйләнештә каралган[2]. Ак төс сакраль (изге) мәгънәгә ия булуы белән рухи бөтенлекне тәэмин итүче Үзлек архетибының билгесе буларак бәяләнә ала. Татар экиятләрендә, гадәттә, ак сакаллы һәм ак киемнән сурәтләнүче картның йөз-кыяфәте сурәтләнмәве аны Үзлек дәрәҗәсенә күтәрә, ягъни яхшылык моделе буларак билгели. Шулай итеп, экиятләрдә һәм соңрак татар әдәбиятында үстерелгән ак сакаллы карт образы кечкенәдән күңелебезгә кереп урнашкан татар милләтенә хас яхшылык, изгелек, күркәмлек моделе рәвешендә чагылуы белән кызыклы.

Татар халык экиятләрендә ярдәмчеләр сыйфатында хайваннар да катнаша. Ярдәмче буларак сурәтләнүче җан ияләренең архетип икәнлеген аңлау өчен тарихка мөрәҗәгать итик.

Борынгы халыкларда яшәү чыганагы нигездә, аучылык булган заманда, иң элек теге яки бу хайван турында ышанулар туган. Дж. Фрэзер фикеренчә, хайваннар белән туганлык мөнәсәбәтенә ышану борынгы община строе чорында һәр ыругның ниндидер бер хайванны үзенең нәсел башы (тотем) — яклаучы һәм саклаучы итеп санауга китергән.[3] Борынгы кешенең тормышында зур урын биләгән тотемга ышану бер нәселдән икенче нәселгә күчә һәм аның архетипик эчтәлеккә ия булуын нигезли. Хайваннарның яклау һәм саклау сыйфатларына ия булуы аларны Рух архетибына якынайта. Һәр халыкның урынчалыкка , йолаларына бәйле рәвештә үз тотемы һәм милли архетипик образы барлыкка килә.

Татар легендаларында ак бүренең халыкны котылгысыз үлемнән коткаруы билгеле. Ак бүре татар халык авыз иҗатында көчле, тиңдәшсез урман хуҗасы буларак реальләшә[4]. Халык көнкүрешендә бүре, тотем хайван буларак, еш кына сакчы вазыйфасын үтәгән, һәм бу традиция татар экиятләрендә дә чагылыш тапкан. «Ак бүре» экиятендә урман хуҗасы ак бүре иң элек үзен хөрмәт итмәгән, сүзләренә колак салмаган егетләрне таш сынга әверелдерә, ә аның сүзләренә хөрмәт белән караган кече туганга ярдәм итә. Ак бүренең ике юл чатында калган егеткә ярдәм кулы сузуы, авыр чакта киңәш бирүе, әхлаксыз кешеләрне иректәреннән мәхрүм итеп җәзага тартуы аны карт образына якынайта. Һәр ике очракта да без мәрхәмәтле, ак күңелле, юлаучыга карата изге теләктә булган образлар белән очрашабыз.

---

[1] Җамалетдинов Л.Ш. Әкиятләр// Фольклор жанрларын анализлау/ Л.Ш. Җамалетдинов. – Казан: КДУ нәшр-ты , 1986. – Б. 98.
[2] Урманчеев Ф.И. По следам белого волка: Ранние этнокультурные связи тюрко-татарских племен/ Ф.И. Урманчеев. – Казань,1994. – С. 128.
[3] Җамалетдинов Л.Ш. Әкиятләр/ Л.Ш. Җамалетдинов. — Б. 6.
[4] Урманчеев Ф.И. По следам белого волка/ Ф.И. Урманчеев. — С. 15.

Аларның характерын билгеләүче сыйфатлар бу образларны Рух архетибына тәңгәлләштерә һәм татар халкына гына хас архетипик образлар буларак билгели.

Борынгы кешенең яшәеш-көнкүреше төрле ышанулар җирлегендә формалашкан гаҗәеп күп йолалар белән тулы булган. Шуларның иң киң таралганы — «үсмерләрне балигълык яшенә җиткәч, олылыр рәтенә күчерү йоласы. Фәндә бу йола инициация дип атала. Йола вакытында егетләрне тотемны хәтерләткән корылма эченә керткәннәр», ягъни йоттырганнар[1]. Йотылып кире чыккан кешегә шул тотем иясенең җаны керә дигән ышану әлеге корылманы Ана архетибы белән янәшә куя.

Бердән, Ана архетибының нигезендә үзенә йотучы караңгы упкын ята. Йола вакытында исә, үсмерләрне шуңа охшаш караңгы куышны хәтерләткән корылмага кертеп чыгаралар. Икенчедән, караңгыга йотылган үсмерләр сау-сәламәт булып чыгалар, ягъни ана кебек әлеге куыш аларны таза, сәламәт итеп, караңгыдан якты дөньяга чыгара. Димәк, балигълык йоласы вакытында күчеш ноктасы буларак билгеле куышны Ана архетибының образлы чагылышы дияргә мөмкин. Тышкы охшашлык нигезендә мәгънәви күчеш ята.

В.Я.Пропп классик тылсымлы әкиятләрнең нигезендә инициация йоласы ятуын хезмәтләрендә дәлилләп үтә.[2]Тылсымлы әкиятләрнең күбесенә түбәндәге сюжет хас: булачак герой, үсеп җиткәч, ил гизәргә чыгып китә, төрле маҗараларга очрый, патша кызын диюдән коткара яисә өйләнеп үзе патша була. Әлеге сюжет нигезендә индивидуация процессы ятуын бер әкият мисалында карыйк.

«Серле сумка» әкиятендә каһарман мунчада җен кызына өйләнергә тиеш. Әкияттә өйләнү кызны үлеләр дөньясыннан алып кайтуга охшатыла. Йоланы үтәмичә, ягъни, мунчага барып кайтмыйча, егет гаилә кора алмый, шуннан чыгып мунчаның инициация белән бәйле урын булуын фараз кылыйк. Н.А.Криничная фикеренчә, рус мифологиясендә мунча — үлеләр дөньясының бер атрибуты — кабер яисә ана буларак күзаллана[3]. Рус фольклорында мунча хуҗасы яңа туган баланы урлап, аның урынына утын агачы, себерке, күп ашаучы баланы калдырып китә. «Серле сумка» әкиятендә дә кызны кечкенә чагында мунча пәриләре урлаган була. Шулай итеп, кыз баланың урлану мотивы татар һәм рус әкиятләрендә охшаш.

Рус әкиятләрендә урланган кыз егеткә тозак кора һәм үзенә өйләнергә кыстый, ягъни, бу очракта кыз җеннәр дөньясыннан кешеләр даирәсенә күчәргә тели.[4] Бу күренешне бер халәттән икенче халәткә күчү — социаль статусны үзгәртү, ягъни инициация дип билгеләп булыр иде. «Серле сумка» әкиятендә дә мунчада яшәүче кыз егетне үзенә өйләнергә мәҗбүр итеп, үлеләр дөньясыннан якты дөньяга чыгу бәхетенә ирешә. Шулай итеп, мунча әкиятләрдә «йотылып чыгу» процессының урыны буларак, Ана архетибы белән ассоциацияләнә. Үзенә йотучы караңгы куыш бер халәттән икенче халәткә күчүне аңлата һәм шул рәвешле Ана архетибының архетипик образы буларак каралырга лаеклы.

Әкиятнең тагын бер үзенчәлегенә игътибар итик. Мунчада кыз белән очрашып, вәгъдә алышканнан соң, егет бик каты чирли һәм өйләнгәч кенә савыгып, бәхетле тормышка ирешә. Шуннан чыгып, мунчада яшәүче җен кызын Анима, ягъни ир-ат психикасына хас хатын-кыз башлангычы дип билгеләү дөрес булыр. Беренчедән, кыз егетне алдалап, үзенә өйләнергә мәҗбүр итә; икенчедән, ул аңсыз халәт

---

[1] Пропп В.Я. Исторические корни волшебной сказки/ В.Я. Пропп. — Л., 1986, — С. 96.
[2] Там же. — С.27.
[3] Криничная Н.А. Русская народная мифологическая проза: Истоки и полисемантизм образов/ Н.А. Криничная. В 3 т. – Т.1: Былички, бывальщины, легенды-поверья о духах. — С. 87.
[4] Там же. — С. 93.

дөньясында яши; өченчедән, егет аңа өйләнгәннән соң гына бәхеткә юлыга. Шулай итеп, әлеге сыйфатлар җен кызын Анима дип билгеләргә мөмкинлек бирә.

Әкият герое өйләнеп, җанының икенче яртысы — Анима белән кушыла һәм гаилә бәхетен татый. Туй вакытында яшьләрнең кавышуы Анима белән Анимусның, ягъни ир-ат һәм хатын-кыз башлангычларының берләшүенә тиң. Бәхетле гаилә кеше күңеленең рухи бөтенлеген тәэмин итә, яшәешнең максатына әверелә. Психологиядә индивидуация буларак ачыкланган әлеге процесс инициациягә тиңләшә. Һәр ике очракта да кеше үтә дә авыр тормыш шартларын җиңеп, гармонияле тормышка ирешә һәм бер дөньядан икенче — бәхет дөньясына күчә. Шулай итеп, геройның рухи үсешен һәм камиллеккә ирешүен гәүдәләндергән индивидуация процессы (трансформация архетибы) геройларның рухи тормышын үзгәрткән инициация йоласы белән тәңгәлләшә.

Башлангычын мифлардан алган әкият герое иң элек кабилә тормышын тәртипкә сала, кешеләрне һөнәрле итә, ыруны явыз көчләрдән саклый. Нәкъ менә шушы герой соңрак әкиятләрдә үз дәвамчысын таба һәм реаль җирлекле образга әверелә. «Камыр батыр», «Турай батыр», “Серле сумка” әкиятләрендә инициация үтүче егетләр әнә шундыйлардан.

Әлеге тип геройлар арасында иң кызыклысы — Таз. Е.М.Мелетинский фикеренчә, тылсымлы әкиятләрдә ике герой катнаша: берсе — батырлыклары белән дан казанган баһадир, икенчесе — түбән, өметсез герой.[1] Турай, Камыр, Әхмәт, Әйгәли батырлар аксөяк нәселеннән булса, Таз — түбән герой. «Таз — патша кияве», «Убыр таз» кебек әкиятләрдә Тазның капма-каршы яклары ачыла. Ялкау, ямьсез, куркак геройның күңеле әкият каһарманыныкына тиң. Ул патшаның һәр җәзасын да үтәп, яраткан киявенә әйләнә, хәйләкәрлек белән мактанчык абыйларын төп башына утырта, һәм ниһаять чибәр егеткә әверелеп патша кызына өйләнә. Күзәтелгән ике образ бер үк әкият героеның якты һәм караңгы якларын гына сүрәтли булса кирәк. Асылда алар икесе дә бер үк архетип — Анимус булырга тиеш, чөнки әлеге образларда халык әкиятләрендә гәүдәләнеш тапкан ир-ат башлангычы ачыла.

Әкиятләрдә герой үлеләр дөньясына эләкми торып өйләнә алмый. Әсәрләрдә ул нәкъ шулай чагыла да: герой күп очракта Дию кулындагы кызны алып кайтырга тиеш була («Турай батыр», “Карунбай”, “Ак бүре” һ.б.).

Дию кешеләрдән читтә яши, аның дөньясына керү — үлем дигән сүз, әмма дию кайда гына булмасын әкият герое — баһадир егет аның биләмәсенә керә һәм үлеләр дөньясы хакимен тар-мар итә. Дию өске дөньяга яманлык кылуы һәм иран мифологиясендә түбән дөнья патшасы булуы белән мәгълүм. Әлеге сыйфатлары аны кеше күңеленең караңгы якларын гәүдәләндерүче Күләгә архетибына якынайта, чөнки җир асты патшалыгы һәм аның хуҗасы —шайтан (дьявол) аналитик психологиядә кешенең аңсыз халәте буларак күзаллана.

Архетипларга хас каршылыклы якларның Үзлектә берләшүе әкиятләрдә дә әлеге архетипның яшәвен таләп итә. Кабилә тормышында ут һәрвакыт үзенчәлекле урын тоткан. Ут төркиләрдә изге-илаһи көч буларак каралган, ди Г. Гыйльманов.[2] Йорт җылысы, гаилә символы — ут әкиятләрдә дә яхшылык, көч, тынычлыкны гәүдәләндерә. Ул начар гына колынны гайрәтле итә (“Әхмәт батыр” һәм “Касыйм батыр”), Ут патшасы рәвешенә кереп баһадирга ярдәм кыла («Җидегән батыр») һ.б.

---

[1] Мелетинский Е.М. Герой волшебной сказки/ Е.М. Мелетинский. — С.213.

[2] Татар халык мифлары: ияләр, фаллар, ышанулар, им-томнар/ Г. Гыйлҗманов. — 1 китап. – Казан: ТКН, 1996. – Б. 72.

Димәк, Ут кешенең игелекле тормышын тәэмин итәргә тиеш. Ут образы мифлардан башланган традиция буенча, әкиятләргә дә  килеп керә һәм татар әдәбиятында яшәвен дәвам итә.

Күзәтүләрдән чыгып шуны әйтергә мөмкин: татар халык әкиятләре коллектив аңсыз халәтнең эчтәлеген тәшкил иткән архетипларның чыганагы буларак өйрәнелергә лаеклы. Әкиятләрдә архетипларның гомум таралыш тапкан образлары белән беррәттән, татар халкына хас үзенчәлекләре белән ачылганнары да урын ала. Архетипик образлар башлангычлары белән кешенең аңсыз халәтенә барып тоташа һәм бер үк архетипларны чагылдырган хәлдә татар халкына хас милли образлар барлыкка китерә. Мәсәлән, Таз, Ут, Дию, Ак бүре, Ак сакаллы карт образлары татар халкының дөньяга карашы белән сугарылып милли архетипик образлар буларак билгеләнә алалар. Архетипларны татар халык әкиятләренә һәм гомумән халык авыз иҗатына мөнәсәбәтле рәвештә тикшерүне дәвам итү кызыклы нәтиҗәләргә китерү ихтималына ышандыра.

*З.М.Арикеева,*
ТӘҺСИнең аспиранты,
ТФДҮнең фәнни хезмәткәре

## *Керәшен туй йоласында төп персонажлар бирелеше*

Фольклор турында фәнни сүз кузгатканда, без еш кына теге яисә бу этник төркемнең мәдәни-эстетик, фәлсәфи карашлар системасын, этик аңын күз алдында тотабыз. Шул ук вакытта, заман сулышын тоеп, көндәлек яшәештә дә халыкның иҗатсыз яши алмавын аңлыйбыз һәм үз алдыбызга сорау куярга мәҗбүр булабыз. Заман фольклоры бармы? Бүгенге көн татар фольклоры нәрсәләрне үз эченә ала, ул нинди формаларда, ничек яши бирә? Нәрсәләрнең сакланышы тотрыклы, ә нәрсәләр үзгәреш кичереп, яңа структурада яши башлый, ә нәрсәләр төшеп кала һәм ни сәбәпле?

Бу сораулар хәзерге фольклористика фәненең иң актуаль мәсьәләләренең берсе.

Фольклористикага караган соңгы елларда дөнья күргән хезмәтләрне, халыкара симпозиум, конференцияләрдә күтәрелгән мәсьәләләрне күздән кичерсәк, әлеге сорауларның еш һәм киң планда куелуларын күрербез. Мисал өчен К.Богдановның «Повседневность и мифология»[1], кебек хезмәтен китерә алабыз. Әлеге сораулар яссалыгында фольклор төшенчәсе аңлатмасының да беркадәр үзгәреш кичерүен, заман таләпләренә яраклаштырылуын күрергә мөмкин. Мәсәлән, аңлатмалы сүзлектә фольклор 1. халык авыз иҗаты; 2. гомүмән кайсы да булса халыкның гореф-гадәтләре, җырлары, әкиятләре җыелмасы дигәнне аңлата. Фольклорны халык мәдәнияте структурасының бер өлеше буларак билгеләүче галим А.С.Каргин «фольклор – этноска хас традицион сәнгати-утилитар эшчәнлек һәм аның нәтиҗәсе, этносның меңъеллык күмәк аралашуы нәтиҗәсендә формалашкан эстетик, этик аңының бик күп шәхси-вариантлар формасындагы башлыча телдән сөйләнүче әсәрләр буларак чагылышы»[2], - дип билгели.

Әлбәттә, без А.С.Каргинның фикерләре белән килешеп, фольклорның халык мәдәнияте тарихының мөһим элементы икәнлеген ассызыклап, мәдәни тарихны тудыручы фактор буларак та аңлыйбыз. Шул ук вакытта фольклорны – рухи тәҗрибәнең социаль төркемләнү формасы икәнлеген дә кабул итәбез. Күргәнебезчә, фольклор төшенчәсен аңлауда шактый күп төрлелек бар.

Күренекле фольклорчы, фольклористика теориясен эшләгән галимнәрнең берсе, Б.Н.Путиловның да бу мәсьәләгә мөнәсәбәтле әйткән фикерләре дә игътибарга лаеклы. Ул фольклор төшенчәсенә мөнәсәбәтле әйтелгән күп төрле фикерләрне биш, бер-берсеннән аерылмалы төркемнәргә туплый. Беренче төркемгә ул фольклор дигәндә традицион мәдәниятнең барлык формаларын кертеп караучы билгеләмәләрне туплый. Икенче төркемгә традицион рухи мәдәният комплексларын аңлаучы аңлатмаларны кертә. Өченчедә сәнгатькә мөнәсәбәтле булган рухи күренешләр комплексы карала, дүртенчедә – авыз иҗаты даирәсен, бишенчедә - вербаль рухи мәдәниятнең барлык күренеш һәм фактларын аңлатучы билгеләмәләрне китерә[3].

---

[1] Богданов К. Повседневность и мифология/ К. Богданов. – СПб.: Нива, 1999. – 386 с.
[2] Каргин А.С. Народная художественная культура/ А.С. Каргин. – Москва, 1997. – 182 с.
[3] Путилов Б.Н. Фольклор и народная культура/ Б.Н. Путилов. - СПб.: 1994. – С. 23-24.

Югарыдагы төркемләүдән күренгәнчә, һәр төркем бер-берсеннән күренеш һәм фактларның күләме, текст яисә көнкүреш әйбере, сәнгать әсәре булу-булмавы белән бик нык аерылып тора. Әлбәттә, әлеге төрлелек, эзләнүләр оештырганда, шактый зур катлаулыклар да тудыра.

Без, үзебезнең хезмәтебезне язганда, фольклор төшенчәсен таррак мәгънәдә, ягъни фольклор – теге яисә бу этник төркемнең фәлсәфи-эстетик, этник күзаллавының, башлыча авыздан-авызга сөйләнүче, төрле вариантларда яшәүче иҗат җимеше, әсәрләр чагылышы дип карауны кулай күрәбез. Эзләнүебезнең төп максаты буларак, Казан арты керәшеннәре этник төркеменең хәзерге гаилә йоласы туй фольклор мирасын барлау һәм андагы персонажларның үзгәреш кичерүен ачыклауны куябыз. Хезмәтнең тикшерү предметын туй йоласы поэтикасында персонажларның булган үзгәреш-күчешләре, ә объектын Мамадыш районындагы керәшен авылларына оештырылган экспедиция материаллары тәшкил итә.

Эзләнүләребезне башлыча чагыштыру, анализ методларына нигезләнеп алып бардык.

Керәшен татарларының йола фольклорын өйрәнү мәсьәләсенә килгәндә, беркадәр фикер әйтелмәгән түгел. Бу нисбәттән, Ф.С.Баязитованың «Керәшеннәр. Тел үзенчәлекләре һәм йола фольклоры»[1] исемле хезмәтен китереп була. Керәшеннәрнең этнографиясе, теле һәм фольклоры үзара тыгыз бәйләнештә каралган әлеге китапта автор гаилә, көнкүреш, календарь йолаларга зур игътибар бирә. Игътибар үзәгенә туй йоласының элек ничек үткәрелүе, аның традицион гадәтләре алынган. Өйрәнү объекты төрле сөйләш урынчылыкка мөнәсәбәтле сайланган.

Туй йоласы димче, яучыларның кыз сорарга килүеннән алып, туй мәҗлесе һәм аннан соң үткәрелә торган йолаларны үз эченә алган. Флера Баязитова керәшен туй йоласына хас булган үзенчәлекле уникаль фольклор материалын шактый төгәл һәм тулы канлы итеп җыйный алган. Шул яктан хезмәт, һичшиксез, ихтирамга лаеклы. Ләкин авторның үз әйтүе буенча, әлеге йола үрнәкләре элек ничек булган, шулай язып алынган. Бүгенге көндәге туй йоласы йола поэтик иҗатының сакланыш дәрәҗәсенең тотрыклылыгын ачыклау хезмәтнең максаты булмау сәбәпле күз уңаена алынмаган. Әлбәттә, безнең чагыштыруларыбыз өчен Ф.С.Баязитованың хезмәте җитди чыганак булуын без әйтеп китәргә тиешбез.

Керәшен татарларының йола фольклорын өйрәнү мәсьәләсендә кызыклы гына тарихи этнографик чыганак булырдай, тагын берничә китапны атамый мөмкин түгел. Алар арасында С.М.Матвеевның 1896 елда дөнья күргән «Свадебные обычаи и обряды крещенных татар Уфимской губернии», Ю.Г.Мөхәммәтшинның «Татары-кряшены» хезмәтләре бар[2].

Әлеге хезмәтләрдән без гасырлар дәвамында керәшен татарларының туй йолаларында, гомумән көнкүрешләрендә тотрыклы мәдәни күренешләрне, үзгәреш, күчешләрне билгеләргә мөмкинлекләр күрә алабыз. Бу яктан алар, һичшиксез, фәнни кыйммәткә ия.

Татар фольклоры дәүләт үзәге 2003 елның октябрь аенда Мамадыш районына оештырган экспедициясе барышында Никифорово, Җөри, Кумырык, Ташлыяр, Юкәче авылларында яшәүче керәшен татарларыннан туй фольклорын язып алуга зур әһәмият бирелде. Безнең өчен XX гасыр башы туеның ничек үтүен, поэтик

---

[1]Баязитова Ф.С. Керәшеннәр. Тел үзенчәлекләре һәм йола фольклоры/ Ф.С. Баязитова. – Казан, 1997. – Б. 103.
[2] Матвеев С.М. Свадебные обычаи и обряды крещенных татар Уфимской губернии/ С.М. Матвеев. – Казань, 1896; Мухаметшин Ю.Г. Татары-кряшены/ Ю.Г. Мухаметшин. – М., 1997.

мирасның сакланышын ачыклау кызык иде. Шунлыктан без информантлар буларак әле күптән түгел кызын кияүгә биргән, улын өйләндергән апаларны (1949-1962 елларда туган), күптән түгел кияүгә чыккан, өйләнгән яшь хатын, ирләрне (1975-1985 елларда туган) сайларга тырыштык.

Алар тарафыннан язып алган материалларны чагыштыру максатыннан 1923-1940 елларда дөньяга килгән абый-апалардан да мәгълүматлар алдык. Алар сөйләгәннәр нигезендә хәзерге керәшен туен тулы күзаллардлык материал туплый алдык.

Дөньяда яшәү көннән-көн яхшыра, алга таба бара, замана үзгәрә, кешегә яшәү, дөнья көтү җиңеләйгәннән-җиңеләя бара. Күп кенә кеше кул көче белән башкарган эшләрне хәзер техника үти. Кешенең рухи дөньясын баетуда һәм рухи таләпләрен кәнагатьләндерүдә дә еш кына техника ярдәмгә килә. Әйтик, радио, телевидение, интернет кебек замана ачышлары һәр кешенең тормышында зур гына урын алып тора. Шулар ярдәмендә ул яңалыклар белән таныша, күңелен ача, төшенкелеккә бирелүен баса, гомумән алганда, алар аның яшәү рәвешенә әверелә.

Ләкин радио, телевизор, магнитофон, компьютер, аларны тыңлау, карау, аларның ярдәменә мөрәҗәгать итү генә күңелнең сусавын баса, рухи дөньяның фәкыйрьлеген киметә аламы соң? Кешенең күңел таләпләре шулар белән генә канәгатьләнә аламы?

Тулы канлы, бар яктан да килгән тормыш алып бару өчен болар гына, һичшиксез, җитеп бетми. Һәм һәрбер хәзерге заман кешесенең дә эчке дөньясын баетучы, кирәк чакта юатучы, тормышының асылын тәшкил итүче булып, ата-бабалардан калган гореф-гадәтләр, күңел ачу ысуллары тора.

Бүгенге көндә халыкның көнкүреше, гомер-гомергә онытылмыйча үткәрелеп килгән бәйрәмнәре, йолалары нинди халәттә һәм нинди үзгәрешләр кичерә соң? Мамадыш районы керәшеннәре фольклорын өйрәнү барышында бу авылларның шәһәрдән, цивилизациядән ерак булмауларына, күп кенә авыл яшьләренең авылда калмауларына карамастан, гореф-гадәтләрнең, йолаларның әле дә яшәп килүен, яшәешнең мөһим тармагы икәнен күзәтеп була.

«Татар халкының гаилә йолалары арасында иң зур хөрмәтле урынны туй алып торадыр, мөгаен. Туй йоласы татар халкында яхшы сакланган, һәм ул үзенчәлекле эчтәлеккә ия»[1], - ди күренекле фольклор белгече Ф.И.Урманчеев.

Чыннан да, яңа гаилә төзү, икенче сүз белән әйтсәк, егетне өйләндерү һәм кызны кияүгә бирү, кешеләрнең шәхси тормышында бик әһәмиятле, гаять җаваплы эш булып тора. Алай гына да түгел, килен алу, аны егет ягына төшерү, һәм шул рәвешле ике нәсел арасында туганлык мөнәсәбәтләре урнаштыру һәр ике як өчен дә зур вакыйга. Монда туй үзенең әһәмиятлелеге буенча иҗтимагый акт дәрәҗәсенә күтәрелә. Менә шуңа күрә дә туй уздыру бигрәк тә мөһим бер эш булып тора[2].

Халкыбызда туй уздырудагы гореф-гадәтләрне төгәл, җиренә җиткереп башкаруга аеруча зур игътибар бирелә. Туй йоласы искиткеч бай, катлаулы, күпкырлы музыкаль-драматик тамаша[3].

Мамадыш районы керәшен авылларында туйлар, кыз сорау, егет өйләндерү әле бүгенге көндә дә искиткеч күңелле, борынгыдан килгән гореф-гадәтләргә таянып үтә.

---

[1] Урманчеев Ф.И. Татар халык иҗаты/ Ф.И. Урманчеев – Казан: Мәгариф, 2002. – Б. 69.

[2] Баязитова Ф.С. Керәшеннәр. Тел үзенчәлекләре һәм йола иҗаты. – Казан: “Матбугат йорты” нәшрияты, 1997. – Б. 105.

[3] Урманчеев Ф.И. Татар халык иҗаты/ Ф.И. Урманчеев. – Казан: Мәгариф, 2002. – Б. 69.

Керәшен туе бер тәүлек дәвам итә, бер кичтән икенче кичкә кадәр. Туйны бер якта гына уздырып калмыйлар, ул башта кыз ягында, ә инде 15-20 көннән егет ягында гөрләп үтә. Туйга килгән туганнар, кода-кодагыйлар, кодачалар иң кадерле, көтеп алган кунаклар, әлбәттә. Туй узасы йортның ишегалдында аларны инде түземсезлек белән ипи, май, бал тотып, учаклар ягып көтеп торалар.

Туйның тәүлек буе дәвам итүе аның башыннан ахырына кадәр кара-каршы җырлауга корылганлыгында.

Суларда ла балыклар, ай, йөзәдер.
Коерыгын комнарга салмыйча.
Без дә кодаларны да шулай көттек,
Тәрәзәдән күзләрне алмыйча.

Елга буйлары, ай, сулык,
Минем атым шуларга ташлана.
Кодаларым, сезгә дә шуны әйтәем:
Кушылулар шуннан башлана[1], - дип җыр суза башлый бер як кодалар.
Ишегалдым саз гына,
Үрдәк белән каз гына.
Кодалар, гаепләмәгез,
Безнең сыйлар аз гына[2].
Аш белән килгән кодаларның җырлары шулай башлана.

Керәшен туеның асылы да аның савымлы туй булуында, ягъни егет ягындагы туйга егетнең туганнары, кыз ягындагы туйга кызның туганнары бөтенесен пардан куеп, күп итеп ризык алып баралар. Кодалар туйга бәлешен, катламасын, хәтта токмачлы ашын да пешереп алып киләләр. Шул арада ук бу сый-нигъмәтләрне мактап җырланган җыр ишетелә:
Биеккәй дә тауның, әй, башлары
Җалтыраптай ла ята ташлары.
Безнең кодаларның ашын-суын
Ничек тартып килгән атлары[3]?

Билләреңә дә япкан алъяпкычың
Нинди күчергечләрдән күчергән?
Карагыз ла безнең туганнарга
Нинди тәмле ашлар пешергән.
Икенче як кодалар да җавапсыз калырга тырышмый, әлбәттә.
Билеңдәге алъяпкычың
Минеке белән пар икән.
Килгәннән дә бирле карап торам,
Бик күп дәүләтләрегез бар икән[4].

---

[1] Татарстанның Мамадыш районы Кумырык авылында яшәүче Ефремова Мария Петр кызыннан (1931) язып алынды. Язып алучы – Арикеева З.М.

[2] Татарстанның Мамадыш районы Кумырык авылында яшәүче Фадеева Анастасия Алексей кызыннан (1934) язып алынды. Язып алучы – Арикеева З.М.

[3] Татарстанның Мамадыш районы Кумырык авылында яшәүче Павлова Анастасия Василий кызыннан (1935) язып алынды. Язып алучы – Арикеева З.М.

[4] Татарстанның Мамадыш районы Кумырык авылында яшәүче Иванова Валентина Иван кызыннан (1966) язып алынды. Язып алучы – Арикеева З.М.

Туй дәвам итә, ә кәләш белән кияүгә, кода-кодагыйга, туганнарга, якыннарга һәм хәтта һәрбер ризыкка атап җырланган җырлар бер-берсенә үрелеп бара.

Кыйгакый, да, кыйгакый каз кычкыра,
Болыннарга төшкән дә каз икән.
Ашагыз да, сез, кодалар, эчегез,
Сезнең өчен үскән дә кыз икән.

И, атларны ла җиктем дә,
Чыгыплар киттем.
И, барып кына җиттем дә Кирмәнгә.
Ай, сез дә, кодаларым, ай, килә дигәч,
Ай, пешереп тә йөрибез, ай пирмәнкә.

Атымны да җиктем дә,
Чыгып киттем.
Барып кына җиттем дә мин Муртка.
Сез дә кодаларым да килә дигәч,
Пешереп тә йөрим мин ботка.

Кара урманнарны да чыккан чакта
Очрады урысларның, әй, марҗасы.
Ашагыз да, кодаларым, сез эчегез
Бигрәк тәмле итләрнең дә калҗасы[1].

Мамадыш районы керәшеннәрендә кызны урлап алып кайту – гадәти күренеш. Кызны егетнең бер бик якын туганнарына алып кайталар, һәм ул анда төн куна. Егетнең туганнары, ягъни, өй хуҗалары кыз өчен иң якын кешеләрнең берсенә әверелә, ул аларга матур итеп әтки, әнки дип эндәшә. «Үзеңнең әниең белән әтиеңнән тары бөртеге кебек кенә ким ул әтки белән әнки»,- дип сөйли мамадышлылар үзләре. Кызны әтки белән әнки дә үз кызларыдай кабул итәләр.

Урамнардан гына казлар килә,
Алдан килә аның да анасы.
Сезнең кызларыгыз да безнең кулда
Мин булырмын аның да анасы.

Иртә торып та бит сөртергә
Чөйдә бистәрләрең дә ак булсын.
Кичке җокыларың да татлы булсын,
Иртән җокыларың да саф булсын[2].

Әнки кешенең җырыннан ук аның кызга булган ягымлы, җылы карашы сизелеп тора.

Һәр ата-ана да балаларын зур тормышка озатып башлы-күзле иткәндә, аларның бәхетле, тигез гомер итүләрен телидер, мөгаен. Аларның бу изге теләкләре җырда да яңгыраш таба:

---

[1] Татарстанның Мамадыш районы Кумырык авылында яшәүче Ефремова Мария Петр кызыннан (1931) язып алынды. Язып алучы – Арикеева З.М.

[2] Татарстанның Мамадыш районы Кумырык авылында яшәүче Куркина Татьяна Петровна кызыннан (1933) язып алынды. Язып алучы – Арикеева З.М.

Иделләргә дә басма салдым,
Калыкмаска да, батмаска.
Безнең теләкләребез дә шундый теләк
Кызларыбыз кире кайтмаска[1].

Берсеннән-берсе тәмле ризыклардан авыз итеп, матур-матур җырлар җырлашып, бер тәүлек вакыт узып, туй мәҗлесе ахырына якынлаша. Моны сизеп туйга килгән кунаклар моңлы тавышлары белән җыр сузалар:

Әй, бакылдый үрдәк, әй, бакылдый
Күлләрдәге суларда,
Күлләрдәге сулары да кипкәнгә.
Рәхмәт инде безне чакырып кунаккай,
Безне чакырып кунаккай ла иткәнгә.

Ә инде туйның иң азагында традицион ботка чыга. Аны керәшеннәр «пошел» боткасы дип атыйлар. Кунак итүчеләрнең җыры нәкъ менә шул боткага багышланган:

Китәбез дә дигәч тә, сез китәсез,
Чатларга да җиткәч тә туктасы.
Китәсез дә, кодалар, сез китәсез,
Пеште хәзер «пошел» да боткасы[2].

Туй турында сүз кузгатканда, һичшиксез, аның төп персонажларының кемнәр булуы, этник төркемнәрдә туганлык, кода-кодагыйлык мөнәсәбәтләре ничек булуына бәйләнгән. Ул кияү-кәләш тә, димче һәм кода-кодагыйлар да, дус-иш, туганнар да, дуслар, күршеләр дә булырга һәм шуның белән беррәттән ул персонажларның урыннары туй йоласы этапларына карап үзгәреш кичерергә мөмкин. Кайсы өлештә кем үзәккә куелуын без керәшен туе мисалында тикшереп карыйк.

Югарыда билгеләгәнебезгә мөнәсәбәтле хәзер туй этапларыннан төп персонажларны ачыклап карыйк.

Туй мәҗлесенә кадәр үткәрелүче йолаларның берсе *аклашуда* туй башлыгы образы сүрәтләнә. Ул:

«Агы килә, агы килә,
Ак артыннан тагы килә,
Алтмыш агасы, җитмеш җиңәсе,
Тулмаганны тутырыгыз,
Җитмәгәнне җиткерегез,
Шалтыратып салыгыз,

Җалтыратып алыгыз»[3] сүзләре белән яшь килен төшкән як җәмәгатьчелегенә, бу очракта кияү ягы туганнарына, мөрәҗәгать итә. Мөрәҗәгать нигезендә килен ягыннан килеп, туганлык мөнәсәбәтләренә керергә тиешле төркемгә тиешле дәрәҗәдә игътибар, ихтирам күрсәтүгә әзерлек ята. Нәтиҗәдә, туй башлыгы дипломант вазыйфасын үти һәм шактый җитди роль уйный. *Баш ору* йоласы да туй йоласының тулы канлы өлеше. Бу йола без экспедициядә булган һәр авылда да элеккегечә тулысынча сакланып калган дип әйтеп булмый. Шулай да кайбер

---

[1] Татарстанның Мамадыш районы Кумырык авылында яшәүче Ефремова Мария Петр кызыннан (1931) язып алынды. Язып алучы – Арикеева З.М.

[2] Татарстанның Мамадыш районы Кумырык авылында яшәүче Фадеева Анастасия Алексей кызыннан (1934) язып алынды. Язып алучы – Арикеева З.М.

[3] Баязитова Ф.С. Керәшеннәр. Тел үзенчәлекләре һәм йола фольклоры/ Ф.С. Баязитова. - Казан. 1997. – Б. 104.

авылларда (мәсәлән, Җөри авылы) әле беркадәр урын алып тора. Башлыча бу йола туй мәҗлесе башланганда, егет белән кыз янәшә басып, һәр килгән кешегә баш орып тору буларак сакланып калган. Ә элек ул кияү белән кәләшнең һәр йортка кереп баш оруына бәйле булган һәм түбәндәге сүзләр белән башкарылган. Шунысы кызык, сүзләрне йорт хуҗалары әйткән.

Бу ызбаларның нигезен
Җалан бакыр белән ук ай батырган.
Бу кодалар безне ник чакырган
Җырлап баш орырга чакырган[1].

Күргәнебезчә, монда төп персонаж вазыйфасында кода-кодагыйлык мөнәсәбәтләренә керергә тиешле кешеләр чыгыш ясый һәм үзәккә алар арасында дустанә мөгалләмә урнаштыру, хөрмәт күрсәтү куелган.

Димәк, персонажлар буларак, кода-кодагый буласы кешеләр сүрәтләнгән кара-каршы әйтеш нигезенә ихтирамлык күрсәтү, мөнәсәбәтләр урнаштыру алына.

Инде *кунак өе* йоласын күзәтеп китик. Бу йоланы да хәзергә беркадәр сакланган дип әйтергә җирлек бар. Безнең эзләнүләребездә әлеге йолага караган күп кенә мәгълүматлар тупланды. Йола нигезенә туй күлмәкләре киеп, килен булып бу авылга төшкән кызны турыдан-туры кияү йортына алып кайтмыйча, алдан әзерләнгән йортка, кияү егетенә туган тиешле хатын-кыз һәм аның ире торган йортка алып кайту алынган. Йорт хуҗалары да күптән түгел генә гаилә корган парлар булырга тиеш. Гадәттә, килен кунак өенә аяк басканда түбәндәге сүзләрне әйтә:

Сезнең атларыгыз җиккәнме?
Пар кыңгырауларны такканмы?
Быйыл гына килгән кодалар
Безгә кунак өе тапканмы[2]?

Сүзләрдән мөрәҗәгать итүченең яшь килен булуы күренеп тора, һәм аның бу ситуациядә гадәтләрне саклаучы, былтыр алар кебек парлашкан гаиләдән парлашу мөмкинлеген сораучы ролендә чыгуын күреп торабыз. Ә инде йорт хуҗабикәсенең яшь киленнең таянычы, киңәшчесе ролендә килүен **кыяматлык**[3] җырларында бик ачык күрергә мөмкин.

Кыяматлык кызым, үз кызым,
Чәчләреңне тарап үр, кызым.
Ата-анаң йорты калды инде,
Күзләреңне ачып күр, кызым[4].

Югарыда китерелгән юлларда кыяматлыкның яшь киленгә мөрәҗәгате сүрәтләнгән. Ләкин мөрәҗәгатьнең беренче строфасында туганлык, якынлык мөнәсәбәтләре урнаштыру да, ата-ана йортыннан киткән яшь киленнең хәленә керү дә сүрәтләнгән. Строфа эчтәлегеннән әлеге мөрәҗәгатьне кунак өендә кунганнан соң әйтелгән булуын тоемларга була. Кичә ата йортында уянган булса, бүген бөтенләй икенче җирдә, яшәвенең икенче стадиясенә күчү күренеше сүрәтләнә.

Бу күренешне мифологиядә билгеле булган геройның балигълыкка яки нинди дә булса икенче халәткә күчүе – инициация белән дә бәйләп аңлатып була

---

[1] Шунда ук. – Б. 107.
[2] Шунда ук. – Б. 108.
[3] “Кыяматлык кызым” дип яшь киленгә шаһит булып торырдай сайланган кияү ягындагы хатын-кызның яшь киленгә мљрәҗәгать сүзе атала.
[4] Баязитова Ф.С. Керәшеннәр. Тел үзенчәлекләре һәм йола фольклоры/ Ф.С. Баязитова. - Казан. 1997. – Б. 108.

торгандыр. Чөнки нәкъ менә кунак өендә кичәге яшь кызның хатынга, яшь егетнең иргә әйләнүе, бигрәк тә яшь киленнең икенче даирәгә керүе, башка йортта яши башларга күчүе бар. Бу күренештә әлеге туй йоласының бик борынгыдан килгән булуына ишарә бар. Безнең фикерләрне керәшеннәрдә яшь киленгә аерым костюм комплексы киертелүе дә куәтли[1].

Күргәнебезчә, бу йолада үзәккә яшь килен куела, һәм ул төп персонажларның берсенә әверелә.

Кыяматлыкның роле туй мәҗлесендә дә һич кимеми. Мәҗлес барышында ул ире белән икенче ата-ана буларак хөрмәткә лаеклы. Мәҗлестә катнашучылар белән кыяматлык арсында әйтешләр дә гаҗәп үзенчәлекле. Мәсәлән:

Карабодайлар ла чабар ыйым,
Карабодайлары ла атлыклы.
Җырлыйм әле мин җырларны,
Кыяматлыклар булу шатлыклы»[2], - дип Кыяматлык мәҗлестә җырлый. Җырдан таяныч булуны хуплау, зурлау күренә.

Туй мәҗлесенең үзенә килгәндә, анда персонажларның иң үзәктәгесе аргыш – туй башлыгы. Ул туй йолаларын яхшы белгән, абруйлы кеше. Туйга үз исеменнән зурлап, матурлап әзерләнгән чәк-чәк яки бавырсак алып килә. Ул мәҗлескә килгәннәрдән җилкәсенә бистәр бәйләнгән булуы белән аерылып тора[3].

Хәзерге туйларда **аргыш** – тамада мәгънәсендә чыгыш ясый. Ләкин традиция буенча тамадага (аргышка) багышланган җырлар әле дә башкарыла.

Биеккәй тауларның башларында
Өлгерә микән сабан ашлыгы?
Сиңа җырламыйча кемгә җырлыйм
Син бит бу туйларның башлыгы.
И ашык син, и ашык син,
Ашый гына торган кашык син,
Ашый гына торган кашык син,
Шушы туйларда ла башлык син[4].

Җырда мәҗлес кунаклары туй башлыгына булган мөнәсәбәт, аның статусын да ассызыклыйлар. Ул – мәҗлеснең хуҗасы.

Аргыш үзе дә китергән күчтәнәчен табынга чыгарганда түбәндәгечә җырлап мөрәҗәгать итә:

Кыр капкасын чыккан чакта,
Атым керде арышка.
Кода-кодачалар сезгә әйтәм,
Сүз бирегез инде аргышка.

Өстемдәге постау бишмәтемне
Чөйләрдән чөйләргә элмим дә.
Шушы күчтәнәчне тапшырмагач,
Аргыш булып туйга килмим дә[5].

---

[1] Мухамедова Р.Г. Татар халык киемнәре/ Р.Г. Мухамедова.– Казан:Татар.кит.нәшр., 1997. – Б. 170.
[2] Баязитова Ф.С. Керәшеннәр. Тел үзенчәлекләре һәм йола фольклоры/ Ф.С. Баязитова. – Казан, 1997. – Б. 109.
[3] Шунда ук. – Б. 110.
[4] Баязитова Ф.С. Керәшеннәр. Тел үзенчәлекләре һәм йола фольклоры/ Ф.С. Баязитова. - Казан. 1997. – Б. 110.
[5] Шунда ук. – Б. 110.

Мамадыш районы керәшеннәре туй мәҗлесендә иң үзәк персонажларның берсе – кода-кодагыйлар.

Аларның үзара кара-каршы әйтешләре хәзерге туйларда да зур урын алып тора. Әйтешләр нигезенә бер-берләрен хуплау да, беркадәр төрттерү дә, аз-маз хурлаулар да бар. Ләкин ничек кенә булса да, кәләшнең ата-анасы игътибар үзәгендә. Алар **олы кода** һәм **төп кодагый** исемнәре белән аталып, аерым игътибар үзәгендә, ихтирам күрсәтүдә. Мәсәлән, төп кодагый мәҗлескә китергән казын табынга чыгарганда:

Бүген лә пичләрем кызу булган,
Көеп лә бетте бөккәнем.
Иртәләрдә торып, пич булганчы,
Сез булдыгыз минем көткәнем»[1], - дип җыр башкара.

Җыр нигезенә кыз туганнан алып, буй җиткәнчегә кадәр ата-ана баласын кемгәдер килен итеп бирүен, әнә шул кемнәрнең нинди кешеләр, кайдан булулары, алдан ук билгеле булмавы, ләкин кем булуына карамастан көтелгән, кадерле, якын кешеләр икәнлегенә ишарә ясала.

Кода-кодачалар да мәҗлестә читтә калмый:

Сары майлар каптым әзерәк,
Ак майлар ла каптым күбрәк.
Кодачалый булып килгән ийем,
Урын бирмәссезме әзерәк.
Түрдә бистәрләрем, әй, чүпләмле,
Чөйдә бистәрләрем лә чигүле.
Урын бирмәсәгез, без китәбез,
Безнең атларыбыз җигүле[2].

Әлбәттә, мондый җырлар бераз уен-көлкеле, җорлык белән сугарылган булсалар да, алар асылында кыз-кәләш туганнарының статусын билгеләү мәсьәләсе ята. Чөнки мәҗлестә, гадәттә, әлеге җырга каршы хуҗалар тарафыннан «Урын бирәбез, түрдән узыгыз! Хуш киләсез, кодалар!» сүзләре әйтелә һәм:

«Ындырлардан кайтканда,
Борчагымны табаларга салып та куырдым.
Сез дә, кодаларыбыз килә дигәч,
Капкаларны ачык та кундырдым»[3] кебек җырлар җырлана. Кодаларга мөнәсәбәтне белдерү мәҗлеснең башыннан ахырына кадәр алып барыла. Беренче параграфта әйткәнебезчә, туйларның озынлыгын тәэмин итүче факторларның берсе - җырланасы, кара-каршы әйтеләсе сүзләрнең шактый күп булуында.

Туй мәҗлесе персонажларының күп өлеше - **кода-кодагыйлар**, **кодачалар**.

Туй бераз баргач, төп ризыклар, кодагыйлар күчтәнәче чыгарылгач, акрынлап кияү һәм кәләш үзәк персонажларга әйләнә. Анда да игътибар үзәгенә күбрәк килен алына. Монда килен-каенана мөнәсәбәтләре урнаштырыла башлый. Кодагый килененең ата-анасына кызларының ышанычлы кулда, җәбер-золымсыз яшәячәген белдерә. «Безнең кулда калган кызыгызның анасы булып үзем калам», - кебек сүзләр әйтелә.

---

[1] **Шунда ук**. – Б. 111.

[2] Шунда ук. – Б. 111.

[3] Татарстанның Мамадыш районы Кумырык авылында яшәүче Ефремова Мария Петр кызыннан (1931) язып алынды. Язып алучы – Арикеева З.М.

Димәк, Мамадыш районы авылларында яшәүче керәшен татарларында туй мәҗлесенең төп персонажлары туй этапларына мөнәсәбәтле үзгәрәләр икән, һәм иң үзәккә **аргыш**, **олы кода**, **кодагый**, **килен** персонажлары куела.

Мамадыш районында яшәүче керәшен татарларының туй йоласында төп персонажларның сүрәтләнешен ачыклау максатын күз алдында тоткан хезмәтебезне башкару барышында, без түбәндәге нәтиҗәләргә килдек:

1. Керәшеннәрнең йола фольклорын өйрәнүгә багышланган хезмәтләр бар, ләкин аларда башлыча традицион йоланы этнографик тулылык белән сүрәтләп бирү генә күздә тотыла.

2. Мамадыш районы авылларында яшәүче керәшеннәрнең туй йолалары хәзерге заманда да борынгы традицияләргә беркадәр тугърылыклы бара.

3. Туй мәҗлесе йоласы шактый тотрыклы. Аларда традицион кара-каршы әйтешкә корылган кода-кодагый җыры да, туй күчтәнәчләрен табынга чыгаруның махсус җырлары да сакланган. Туй мәҗлесендә кәләшнең ата-анасы, туган-тумачасы аеруча игътибар үзәгендә. Мәҗлес башланганчы, кода-кодагыйларның исәнләшү җырлары мөһим урын алып тора. Өйрәнелгән авыллардагы туй мәҗлесенең традицион этник башламы (кода-кодагый, кодачаларны каршылау, табынга утырту) һәм тәмамлану өлешләре («пошел» боткасы) хәзер дә сакланган. Бу традициянең тотрыклы саклану билгесе.

4. **Аргышлау** - (димләү)  йолаларын тулы канлы сакланган дип әйтеп булмый. Без, өйрәнелгән 5 авылдан Җөри авылында гына туй йоласы персонажы буларак, **аргыш** белән очраша алдык. Җөри авылында туй мәҗлесендә аргыш вазыйфасын традицион  туй башлыгы үти. Башлыкны күп очракта аргыш дип түгел, ә тамада дип атау гадәте ешрак очрый. Ләкин 60-70 елларда кияүгә чыккан апалар үзләренең туйлары турында аргыш сүзен кулланып сөйлиләр. Бу факт туй йоласының кайбер гадәтләрен заман таләпләренә буйсынып, этник билгеләүнең унификацияләнүенә китерүен күрсәтә. Невелировкаланган йолалар арасында **«өй керү»** гадәтен дә күрергә мөмкин. Кайчандыр килен һәм кияүнең яшәешнең икенче халәтенә күчү процессын – инициацияләүне белдергән йола акрынлап мәҗлес тамашасына әйләнгән булуын билгеләргә туры килде. Элек йола туй мәҗлесендә кунаклар каршылауның ритуалы буларак кына сакланган. Гәрчә 1980 еллар башында **«йорт керү» («өй керү»)** йоласы шактый киң үткәрелгән булса да.

5. **Кыяматлык** персонажына килсәк, ул таяныч вазыйфасында сакланып килә. Ләкин, «йорт керү» йоласы булмаганлыктан, кыяматлык сайлау өлеше төшеп калган, шуның белән аның авыл җәмәгатьчелеге алдында статусы да беркадәр кимегән.

6. Туй йоласының төп персонажларына һәм аларның сүрәтләнүләренә килгәндә, түбәндәге нәтиҗәгә килдек:

а) персонажларның статуслары йоланың этапларына мөнәсәбәтле үзгәрә. Мәсәлән, **аргыш** — туй башлыгы һәм мәҗлестә төп персонаж.

б) иң төп, игътибар үзәгендәге персонажлар – **олы кода** һәм **төп кодагый**. Бу персонажлар туй барышындагы поэтик иҗатта иң еш телгә алынган һәм мөнәсәбәтләрне белдерүгә карап, иң еш мөрәҗәгать ителгән образлар.

в) **яшь килен** образы да үзенчәлекле чагылыш таба. Ул әти-әнигә рәхмәт әйтүче, кыяматлыкны зурлаучы, яңа хуҗалыкка кыюсыз атлап керүче образ.

г) **аргыш** – туй башлыгы – мәҗлес хуҗасы буларак, сүз бирүче буларак чагыла.

д) к**ияү**гә туй мәҗлесе поэтика иҗатында зур урын бирелмәсә дә, аның образы сүрәтләнә. Ләкин аның статусы килен статусыннан аермалы булганга, ул үзе даирә, игътибар яулауда катнашмый.

*Эльмера Ханнанова-Галимҗанова,*
ТӘҺСИнең фәнни хезмәткәре

# *Фазыл Туйкинның фольклор өлкәсендәге эшчәнлеге*

XX йөз башында киң колачлы иҗат эшчәнлеге алып барган, татар мәдәниятен үстерүгә зур көч куйган Фазыл Туйкин (1887-1938) исеме күпләребезгә таныш. Ул безгә үзенчәлекле шагыйрь, драматург, прозаик һәм тарихчы буларак билгеле. Шулай ук вакытлы матбугат битләрендә аның тел, әдәбият, мәгариф һәм башка мәсьәләләргә караган мәкаләләре белән дә еш очрашабыз. Соңгы елларда “Кечек тәҗвид” һәм “Әхкям ислам” исемле дини китаплар язуы да мәгълүм булды. Әмма татар әдәбияты тарихына ул татар кульязма ядкәрләрен эзләп табучы, күбрәк фольклорчы галим буларак кереп калган. Чөнки аның бу өлкәдәге хезмәте зур да, мактаулы да. Беренчеләрдән булып ул халык авыз иҗаты әсәрләрен туплады, аларны системага салды, фәнни күзәтүләр ясады.

Халык әдәбиятын өйрәнүнең әһәмиятен Фазыл Туйкин болай дип аңлата: “Бер халыкны тирәннән тикшереп өйрәнү өчен, иң зур булышлык итә алучы нәрсә – шул халыкның әдәбияты санала. Чөнки, халык әдәбиятын күп гасырлар аша килгән тормыш тәҗрибәләре, тарих дулкыннары тудыра. Халыкның тойгысы, шигърияте аны җанландырып үстерә бара. Шунлыктан халык әдәбиятында халыкның теле, гадәт-йоласы, тормыш һәм табигатькә карашы, идеологиясе, мәдәнияте, аның үсеше, үзгәреше, күрше халыклар белән сәяси, иҗтимагый, икътисади һәм мәдәни багланышларның халык әдәбиятының эчтәлегенә, үсешенә нык тәэсир итүенә дә игътибар итә.

1912 елны Фазыл Туйкинның Казанда кыска-кыска дүртьюллы халык җырларыннан торган “Җырлар әхтәрисе” исемле җыентыгы дөнья күрә[1]. Бу китап 1912-1918 елларда гына да дүрт тапкыр басыла. Димәк, хезмәтне халык яратып укыган һәм үз иткән дигән сүз. 1100 җырны берләштергән, алфавит тәртибендә системага салынган бу җыентык, революциягә кадәр чыккан башка җыр китапларыннан аерылып торган һәм бүгенге көндә ул үзенең тарихи һәм гыйльми әһәмиятен югалтмаган.

Фазыл Туйкинның халык авыз иҗаты әсәрләрен җыю, барлау, системага салу, бастырырга әзерләү һәм бу хакта фәнни хезмәтләр язуы башлыча унынчы-егерменче елларга туры килә. Ләкин фольклорчы галимнең бу өлкәдәге эшчәнлеге шома гына бармаган, аңа күп кенә кыенлыклар кичерергә туры килгән. Бигрәк тә, егерменче елларда ул совет режимының, аның тәти егетләренең мәрхәмәтсезлеген, кешелексезлеген күрә. Бу заманның сәясәте, идеологиясе, хәерче тормышы, иҗат кешесенең хезмәтенә, шәхесенә төкереп карау аның хатларында бик тә ачык чагылган.

Галимнең 1926-28 елларда Гыйльми Үзәккә язган сигез хаты сакланып калган[2]. Шушы хатлар аша аның шәхес буларак шул чордагы язмышын күзалларга була. Аларда күпме сәяси һәм әдәби көрәш, күпме сагыш, аһ-зар!

Төрле китапханәләрдә сакланып калган сигез китабыннан тыш, Фазыл Туйкинның күп кенә хезмәтләре дөньяга чыга алмый кала, югала. Хатлары аша

---

[1] Туйкә Ф. Җырлар әхтәрисе/ Ф. Туйкә. – Казан: Сабах, 1912.– 160 б.
[2] Дәүләт университеты фәнни китапханәсенең кульязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге. №938Т.– Б. 24.

научный сотрудник
по музыкальному фольклору ГЦТФ

# *К проблеме нотной фиксации татарского музыкального фольклора*

Перевод устной фольклорной речи на язык письменной пятилинейной нотации имеет свою неповторимую специфику. Народный напев, будучи феноменом устной музыкальной культуры, и сам по себе ни в какой записи не нуждающийся, фиксации нотными знаками поддается с большим трудом и значительной мерой условности. Во-первых, средства европейского нотного письма, рассчитанные на запись музыки, темперированной по строю и ритмически организованной на основе принципа кратного соотношения длительностей, мало пригодны для записи народных напевов, часто не подчиняющихся академическим европейским нормам звуковысотности и временной организации. Во-вторых, при записи народных напевов не всегда просто решить взаимоисключающие друг друга задачи – с одной стороны, отражение подробностей единичного уникального исполнительского акта, а с другой, выявление внутренней организации напева, сущностных элементов фольклорный «модели». Проблем, возникающих при фиксации устного музыкально-поэтического текста, рожденного и исполняемого народными музыкантами, возникает немало. В татарской музыкальной фольклористике, а во многом и в современной фольклористике в целом – их разработка до сих пор не завершена.

На разных этапах развития музыкальной этнографии складывались различные подходы к фольклористической нотации.

Первые записи татарского музыкального фольклора, сделанные в XIX – нач. XX века (имеются в виду публикации И.Добровольского, А.Риттиха, С.Рыбакова и др.), осуществлялись на слух, безусловно, носили обобщенный характер. При этом ладо – интонационные и ритмические особенности напевов осмыслялись в формах, господствовавших в профессиональной музыке того времени. Так, ладо – интонационная сторона напевов подогнана под мажорно-минорные стереотипы, ритмика уложена в регулярные структуры, фиксируется лишь один куплет (пример, песня «Тәфтиләү» из сборника С.Рыбакова).

Современные фольклорные сборники татарских народных песен, безусловно, отличает несравнимо более высокий уровень полноты и подробности фиксации напевов. В нотациях используется большое число знаков, фиксирующих свободное изменение длительностей. Ритмическая сторона фиксируемых напевов, как правило, освобождается от тактово-стереотипной зависимости. Общеупотребительным становится использование переменных, нерегулярных размеров, а иногда – отказ от какого бы то ни было обозначения размера (Р.Исхакова-Вамба, ТНП, 1981, №95 «Тәфтиләү»).

Более детализированной становится и фиксация разного рода исполнительских моментов. Так, в нотациях М.Нигмедзянова обозначаются важные и частные в народном интонировании приемы глиссандо. Фиксируются также такие нюансы исполнения, как произнесение слов говорком, подчеркнутое произнесение отдельных слогов, отмечаемое акцентами. Нередкие в народном исполнении случаи

понижения или повышения звуковысотного уровня напевов также находят свое отражение в рассматриваемых нотациях. В записях некоторых фольклористов отражаются моменты взятия исполнителем дыхания.

Все чаще можно встретить случаи фиксации не только первых куплетов многострофных напевов, но и последующих, особенно это характерно для нотаций Р.Исхаковой-Вамба, М.Нигмедзянова, З.Сайдашевой. В одних случаях напев выписывается полностью от первого до последнего куплета, в других – вариантные изменения, возникающие во второй и последующих строфах, отмечаются сносками или каким-либо иным способом.

Современным подходом к нотациям народных мелодий в татарской фольклористике стало выявление внутренних структурных свойств напевов и их отражение в различных способах расположения нотного текста. Закономерным стало соотнесение музыкальных и поэтических структур, размещение на одной нотной строке одной или нескольких поэтических строк. Данный способ записи делает возможным наглядное сравнение строк в мелодико-ритмическом отношении, отдельные примеры можно встретить в сборниках М.Нигмедзянова, З.Сайдашевой. Но даже в последних публикациях можно заметить некий схематизм в записи, нивелирующий специфику материала – мелизмы при записи орнаментального рисунка напевов, «выравнивание» в соответствии с тактовым размером протяженности долгих длительностей. Это обусловлено, вероятно, стремлением выделить внутренние организующие черты напева, выявить «модель» фольклорного образца. Но жертвовать при этом деталями исполнительской интерпретации вряд ли возможно.

В современной фольклористике утвердился метод так называемой аналитической нотации материала, предложенный Е.Гиппиус, развитый Э.Алексеевым. Он заключается в фиксации «как частных, единичных, случайных моментов, так и сущностных, типовых свойств, определяющих принадлежность фольклорного образца тому или иному пласту народной музыкальной культуры». При этом предполагается дифференциация в записи внутренне организующих свойств от избыточных, внешне вариативных, лишь замутняющих смыслонесущую структуру целого элементов.

В татарской музыкальной фольклористике метод аналитической нотации применялся очень ограниченно. Осуществляемая в Центре татарского фольклора практическая работа по обработке музыкального материала представляет собой одну из первых попыток в этом направлении. Тем самым возникает проблема адаптации теории аналитической нотации к конкретному – в данном случае, татарскому – национальному фольклорному материалу.

Аналитическая запись фольклорных образцов требует определенной системы в использовании как традиционно существующих в современной фольклористике нотных обозначений, так и специальных приемов нотирования. В татарской фольклористике некоторые из них до сих пор были невостребованными. Так, в пении информантов напев нередко претерпевает звуковысотную эволюцию: его звуковысотный строй может плавно смещаться, повышаться или понижаться. В записи такого рода напевов обычно сохраняется исходный звуковысотный уровень, а высотная эволюция напева в существующих записях не отражается. В наших нотациях она показывается буквенной формулой, помещаемой над ключевыми знаками альтерации (cis - c). Эта формула содержит в себе указание крайних звуковысотных точек смещения. Информация о композиционно-структурном

пространстве, в пределах которого происходит эволюция строя, отмечается в соответствующей сноске.

Кроме того, в пении информантов нередко встречаются случайные звуки, связанные с непопаданием на отдельные ноты или со смещением целого интонационного оборота. Такого рода звуки обычно подвергаются исправлению и в нотациях не сохраняются. Мне кажется необходимым фиксировать эти случайные звуки в скобках рядом с соответствующими им «исправленными» звуками.

С целью наглядной дифференциации в записи женского и мужского исполнения напевы, исполняемые женщинами, записываются в скрипичном ключе, мужчинами, соответственно в басовом. Партии низких женских голосов, во избежание большого количества добавочных нотных линий, фиксируются октавой выше реального звучания с использованием знаков октавной транспозиции. Между тем, в существующих фольклорных сборниках такого разграничения при использовании ключей не делалось (М.Нигмедзянов, ТНП, 1984, №3).

При записи орнаментальных «изгибов» напева или инструментального наигрыша представляется некорректным использование стандартных фигур европейских мелизмов, мало приспособленных для выявления национальной мелодической специфики. В своих нотациях мы стремимся к максимально точному фиксированию орнаментального рисунка фольклорного образца с сохранением при этом мелодического остова.

Для фиксации тонких ритмических нюансов при нотации используется знак, отличающий незначительные отступления от величины обозначенной ритмической доли.

Используемый нами метод аналитического структурирования фольклорных образцов предполагает непосредственное отражение в конфигурации нотного текста его композиционных закономерностей. Средством выявления в записи композиционного устройства фольклорного образца является ранжир. Вертикальный ранжир дает возможность непосредственного визуального восприятия композиционного строения нотируемого фольклорного образца.

Вертикальное соотношение музыкально-поэтических строк друг с другом может осуществляться по разным принципам: слогоритмическому, попевочному и др. Каждый из них может стать доминирующим. Для нас определяющих фактором становится задача выявления мелодико-композиционного строения строфы. При этом повторяющиеся или вариантно-подобные в мелодико-ритмическом отношении строки размещаются друг под другом, на одном вертикальном уровне, различающие строки «лесенкой», то есть со сдвигом начала строк вправо на определенное расстояние. Избранный способ дает возможность не только выявить мелодико-композиционное строение нотируемого напева, но и наглядно показывает мелодическое сходство и вариантные различия соответствующих строк различных строф. Отметим, что в большинстве сборников татарских народных песен вертикальный ранжир до сих пор не использовался. Исключение составляют фольклорный сборник «Татарско-мишарские песни» З.Сайдашевой, Х.Ярми (1979), «Сборник татарских народных песен» М.Нигмедзянова (1984).

В осуществляемых нами нотациях делается попытка «редактирования» напевов с целью «снятия» исполнительских случайностей, вуалирующих типовую музыкальную структуру. Поскольку различные жанры татарского устного музыкально-поэтического творчества имеют различную степень структурной

типизации, «редакционная обработка» фольклорного текста осуществляется в них с разной степенью последовательности.

Редакционная обработка осуществляется с учетом следующих факторов:

1. Наличие или отсутствие устойчивых структурных закономерностей, характерных для данного жанра.
2. Особенности исполнения, связанные со степенью вариативности того или иного элемента фольклорного текста.

При всех вносимых редакционных изменений в нотации сохраняется подлинная «версия» исполнения напева на основе использования надстрочных знаков и указаний в скобках.

Таким образом, используемые нами в нотации музыкального материала различные приемы и способы фиксации, призваны максимально точно, подробно, наглядно отразить все особенности фольклорного образца и при этом дифференцировать в записи сущностные и единичные моменты. Как мне представляется, предлагаемый подход к нотации татарских традиционных напевов на сегодняшний день является наиболее оптимальным.

*Р.Г.Мөхәммәдова,*
тарих фәннәре кандидаты,
ТФДҮнең әйдәп баручы фәнни хезмәткәре

## *XIX йөз ахыры – XX йөздә татарлар арасындагы этник процесслар*

Милләтнең үсүе, аның структурасына (составына) кергән төркемнәр арасында уртак этник күрсәткечләр, икътисади һәм мәдәни бәйләнешләрнең булуына һәм ныгуына бәйле. Шуңа күрә, милләт яшисе килсә, ике юнәлештә үсәргә тиеш: беренчесе, үзенең этник күрсәткечләрен, ягъни аны башка этнослардан аерып торган телен, буынннан буынга бирелеп килгән традицияләрен (йола гадәтләрен, авыз һәм музыкаль иҗатын һ.б.) саклау һәм, чор таләпләреннән чыгып, яңарта алу; икенчесе - үзенең социаль-экономик нигезен, профессиональ мәдәниятен үстерү юнәлешендә эш итү.

Кайвакытларда фикер алышканда, милләтне авыл саклый дигән фикер ишетергә туры килә. Бу дөрес фикер. Ләкин бит милләт (этнос) һәм аның мәдәнияте үссен һәм дәвам итсен өчен традицияләрне саклау гына түгел, аларны, яңа чор таләпләреннән чыгып яңартырга, аларга яңа тормыш бирә белергә дә кирәк. Моны шәһәрләрдә яшәүче милләт вәкилләре (һөнәрчеләр, эшкуарлар, профессиональ иҗат кешеләре – язучылар, композиторлар, сәхнә осталары һ.б.) һәм милли телдә чыгарылган газет-журналлар, әдәби һәм фәнни китаплар, радио-телевидение тапшырулары башкара.

Югарыда әйтеп узылганча, милләт үссен өчен, этнотерриториаль төркемнәр арасында икътисади һәм мәдәни бәйләнешләрнең булуы һәм ныгуы кирәк. Милләтнең үз эчендә һәм төрле милләтләр белән аралашу нәтиҗәсендә барган этник процессларның торышын һәрдаим күзәтеп һәм өйрәнеп торучы дәүләт һәм дәүләт оешмаларының булуы да мәслихәт. Алар милләтләрнең үсү процессында уңай яки тискәре роль уйнаучы субъектив фактор саналалар.

Татарларның милли үсешендә Казан шәһәренең роле дә зур икәнен әйтеп китәргә кирәк. Хәер, XIX йөзнең ахыры – XX йөзнең башларында (бу татар милләтенең формалашкан еллары) татарларның иҗтимагый һәм мәдәни үзәкләрен, Казаннан кала, тагы татар төркемнәре яшәгән башка төбәкләрдәге шәһәрләр (Ырынбур, Уфа, Тубыл, Төмән, Пермь, Сембер, Әстерхан, Касим һ.б.) дә тәшкил итә. Аларның күбесендә XX йөз башларында татарлар күп яши, анда татар газета-журналлары чыга, театр труппалары үсә, икътисади бәйләнешләр активлаша. Татар буржуазиясенең татарлар яши торган төркемнәргә керткән капиталы да зур этәргеч ясый. Бу чорда этносның икътисади һәм мәдәни бәйләнешләренә, территориаль ераклык әллә ни комачауламый, чөнки ул Россиянең эчке базар мөнәсәбәтләренә кушылу формасында бара. Төрле районнардагы татар иҗтимагый һәм мәдәни үзәкләре арасында бәйләнеш ныгый. Бу процесс төрле төбәкләрдә яшәүче татарлар арасында милли үзаң ныгу белән бер юнәлештә бара. Һәрхәлдә, XX йөз башларында гомум этник консолидация процессларына тартылмаган төркемнәр татарлар арасында юк диярлек. Ләкин бу әле аларның традицион мәдәниятләрендәге урынчылык билгеләре бөтенләй юкка чыкты дигән сүз түгел. Ул билгеләр телдә, туй

һәм башка йолаларда, милли киемнең колоритында, халык иҗатында бүгенге көнгә кадәр чагыла һәм милли мәдәниятнең үсеше өчен өстәмә чыганак булып тора.

Этносның (милләтнең) үсеше аның үз эчендә камилләшә баруы белән генә түгел, башка халыклардан нәрсәдер алу исәбенә дә бара. Шуңа күрә төрле төркемнәрдә яшәүче татар халкының традицион мәдәниятендә, мәсәлән, киемендә, аның үзенә генә хас билгеләр белән беррәттән, гасырлар буена аралашып яшәгән башка халыклар белән уртак элементлар да шактый. Күп очракта менә шул элементлар аларның традицион мәдәниятендә урынчылык хасил итәләр дә инде. Шунысы игътибарга лаек: башка этностан кергән элементны халык механик рәвештә кабул итми. Ул аның үзенең традицияләре һәм эстетик зәвыгы тәэсирендә шактый үзгәртә. Мәсәлән, XIX йөз ахыры – XX йөз башында формалашкан татар милли киеменең, үз традицион төрләрен, декоратив алымнарын саклап, бу чорларда Аурупада формалашкан яңа стильдәге киемгә күчә алуы моңа үрнәк булып тора. Бу стильдәге хатын-кыз кием комплексына өскә ятып тора торган, «куштаннар» куеп эшләгән киң итәкле күлмәк, билне кысып торучы кыска җиңсез камзул, маңгай өстенә генә утыртып куела торган калфак, биек үкчәле «чәмчәле» читек-кәвеш һ.б. керә.

Яңа стильдәге кием комплексы татарлар яшәгән бөтен төркемдә дә (керәшеннәрдән кала) кабул ителә. Бу вакытта этник яки милләтара аралашу, кайбер социаль һәм милли тигезсезлекләргә дә карамастан, шактый тыныч бара, чөнки гасырлар дәвамында милли аралашу традициясе формалашкан була инде. Мәсәлән, Казан арты районнарында этник аралашу өч җирле халыкның: мари, удмурт, татарларның тарихи бәйләнеше җирлегендә туа. Уртак аралашу булып биредә татар теле хезмәт итә. Бу төбәк базарларында әле сугышка кадәр дә сату-алу шул телдә бара. Урал алды төбәкләрендә дә уртак аралашу теле булып татар теле кабул ителгән. Тау ягында исә этник аралашу, борынгырак чорларда, чуваш һәм татарлар арасында, ә XVI йөзнең икенче яртысыннан чуваш, татар һәм урысларның бергә яшәү җирлегендә була. Бу районнарда татарлар - чувашча, чувашлар татарча сөйләшә белә. Буа, Тәтеш, Сембер кебек шәһәрләрдә урыс теле дә шактый иртә тарлыш ала. Профессор Е.П.Бусыгин үз хезмәтләрендә бу районнарда яшәгән урысларның традицион мәдәниятенә җирле халыкларның (чуваш, татарларның) йогынтысын ассызыклап күрсәтә. Һичшиксез аралашу нәтиҗәсе берьяклы гына булмый. Җирле халыкларның традицион мәдәниятенә урысларның уңай йогынтысы да шактый була. Һәр халык бу мәдәни бәйләнешләрне үзенең эчке мөмкинлекләреннән һәм таләпләреннән чыгып үзләштерә.

Совет чорының беренче яртысында, халыклар арасындагы этник процесслар – милләтнең үсеше һәм аның башка милләт вәкилләре белән аралашуы каршылыксыз бара. Бу еллардагы кайбер социаль-икътисади һәм мәдәни үзгәрешләр татар милләтенең үсешенә шактый уңай нәтиҗәләр дә бирә. Халыкның белем дәрәҗәсе күтәрелә, үзенең фәнни һәм иҗат интеллигенциясе үсә. Башка төбәкләрдә яшәүче татарларның рухи ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен кайбер уңай шартлар: милли районнар, бистәләр һәм авыл Советлары, мәктәпләр, ә район үзәкләрендә татар педучилищелары ачыла, ана телендә гәзитәләр чыга башлый. Шуның белән бергә халыкның милли үзаңының формалашуында зур урын тоткан Ислам идеологиясе куллану сферасыннан кысрыкланып чыгарыла. Бу елларда ук инде милли сәясәт нигезендә социаль тигезләүләр һәм милләтләрнең якынаю процессын тизләтү, интеграция процессларын үстерү ята. Әлеге процесс бигрәк тә сугыштан соңгы елларда киң колач алды. Икътисади, сәяси һәм демографик фактлар йогынтысы

астында милләтара миграция көчәйде, татар теленең куллану сферасы тарайды һәм, киресенчә, урыс теле икенче ана теленә әверелде: яшьләр арасында үз халкының мәдәни кыйммәтләренә һәм традицияләренә игътибар кимеде, төрле милләт вәкилләре, бигрәк тә урыслар белән никах нормалашты һәм этносның төп билгеләмәсе булган әдәби тел һәм милли үзаң да әүвәлге ачыклыгын җуйды. Көнкүрештә гомумсовет мәдәни үрнәкләре: яңа йолалар, яңа бәйрәмнәрнең урын алуы да милли үзаңны какшатуга китерде. Шул ук вакытта, чиктән тыш үзәкләштерелгән административ система, милли мәсьәлә, янәсе, хәл ителде дип, милли үсеш ихтыяҗларын искә алмый башлады. Республиканың автоном суверенлыгы да милли һәм интернациональ кыйммәтләрнең органик бәйләнешен тәэмин итмәде. Гомумән, совет чорында, бигрәк тә сугыштан соңгы елларда, берләштерү (интеграция) белән бәйле этник процессларны гына алга сөрү сәясәте аерым милләтләрнең үсүенә зур тоткарлык ясады. Нәтиҗәдә, бу ике этник процессның (милләтнең үзенең эчке этник күрсәткече нигезендә һаман да үсә баруы һәм аның башка халыклар белән аралашуы, якынаюы) органик бәйләнеше, гармонияле үсеше бозылды. Мондый шартларда төрле җирләрдә таралып яшәгән татарларның башка халыклар, беренче чиратта руслар белән ассимиляцияләшүе дә бик мөмкин иде. Бу процесс кайбер төбәкләрдә (мәсәлән Себердә) шактый актив бара. Ләкин, гомумән алганда, татар милләте, хәтта аның ерак җирләрдә яшәгән вәкилләре дә үзләренең этник йөзен, динен, уңай сыйфатларын саклый алды.

Бүген дә, милләтнең үсүе зур авырлыкларга һәм каршылыкларга очрый. Бу, беренче чиратта, Татарстанның үзендәге табигый ресурсларыннан тулысынча файдалана алмавы, аннан килгән керемнең яртысыннан артыгы үзәккә китүе икътисади өлкәдәге мөмкинлекләренең кимүендә, Россиядә бүген милли мәсьәләләрнең чамадан тыш сәясәтләштерелүендә дә сизелә.

Үткән ел халык санын алу өчен эшләнгән анкетада татар милләтен, дини (конфессиональ) һәм территориаль аерымлыкларга карап, төрле төркемнәргә (керәшен, Себер һәм Әстерхан татарларына, мишәр, типтәрләргә) бүлеп бирү дә нормаль күренеш түгел иде. Бөтен дөнья халыклары арасында интеграция процессы колач җәйгәндә, оешкан милләтне яңадан сүтәргә, вакларга тырышу акылга сыймый. Моңа каршы миңа: «Ә бит төркем вакилләре үзләре шуны сорый», - диючеләр табылыр. Әйе, андый фактлар да бар. Мәсәлән, керәшеннәр үзләренең оешмаларын, гәзитәләрен булдырды. Демократиягә омтылыш елларында бу нормаль күренеш. Шуны да истән чыгарырга ярамый, милләт ни кадәр зур һәм киң территориядә яшәсә, ул шулкадәр төрле этник процессларга, шул җөмләдә дифференциациягә дә ачык була; тик аның үсүенә киртәләр чикләр генә кормаска кирәк.

Татарларның, шул җөмләдә керәшеннәрнең дә, тарихи һәм этномәдәни үсешләре катлаулы була. Казан ханлыгын басып алганнан соң, татарларны көчләп чукындыру нәтиҗәсендә барлыкка килгән бу төркем, христиан диненең басымы астында татарлардан ераклаша бара һәм этник үзаңын җуя (дөресрәге, аларның этник үзаңы дини үзаң - «керәшен» белән алыштырыла). Ләкин алар татарларга хас халык мәдәниятен: теле, йолаларын, бәйрәмнәрен (христиан дине аша кергән бәйрәмнәрне әйтмим), хәтта киемнәрендә дә, борынгы чорларда татарларга хас архаик формаларның күбесен саклаганнар. XVI йөзнең урталарыннан соң аларның этномәдәни үсеше мөселман татарлары белән бер юнәлештә бара алмый. Татар милләте һәм аның үзаңы формалашу процессы керәшеннәрне читләтеп уза

(гомумән, озак еллар алар татар милләте белән бер юнәлештә үсмиләр). Шуңа күрә аларда мөселман татар төркемнәренең барсына да хас нормалашкан милли үзенчәлекләр (милли кием, шул вакытка хас җырлар, көйләр, гадәтләр, йолалар) җитенкерәми.

Совет елларында, дини идеология көнкүрештән кысрыклап чыгарылу нәтиҗәсендә, әлеге конфессиональ төркем, яңадан татар милләтенең үсү процессына кушылды һәм бу юнәлештә үзеннән шактый өлеш кертте һәм кертә дә. Татар мәдәнияте, сәнгате һәм башка өлкәләрдә эшләүче югары квалификацияле татар вәкилләре арасында керәшеннәр дә байтак. Мин керәшен төркеменең киләчәге татар милләте структурасында булырга тиеш дип уйлыйм. Чөнки безнең уртак этномәдәни нигезебез бар. Ә дини үзаң гына ассимиляция (Россия шартларында урыслашу) процессын тизләтә торган фактор.

Башкортстанда бер миллионнан артык (1989 елгы сан алу буенча 1120702) татар бар. Аларның күбесе Башкортстанның төньяк-көнбатыш районнарында яши. Бу җирләрдә, әле борынгы чорларда ук, татар халкының, бигрәк тә Казан татарларының формалашуында катнашкан, уртак кабиләләренең яшәгәнлекләре билгеле. XVI йөзнең урталарыннан, Казан ханлыгы җиңелгәннән соң, татарларның Урал алды буйларына күчеп утырулары активлаша. Башкортстанда аларны, җиргә булган хокукларына карап, сан алу кенәгәләрендә төрлечә атаганнар, мәсәлән, иртәрәк килгән казан татарларын дәфтәргә теркәгәннәр (дәфтәр сүзеннән «типтәр» барлыкка килгән). «Мишәр» һәм «төмән» дигәннәре дә булган. Аларның күбесе, бигрәк тә «төмәннәре» әвәлге Рязань губерниясе Темников өязеннән (татарлар Темниковны Төмән дип атыйлар), хөкүмәт тарафыннан «служилый» (йомышлы) хезмәтен үтәүчеләр буларак китерелгәннәр. «Мишәр» дип аталганнар арасында кайдан килгәннәрен белмәүчеләре («җирле мишәрләр») һәм, соңрак дәверләрдә, төрле социаль сәбәпләр аркасында, Пенза, Сембер губерниясеннән күчеп килгәннәре дә бар. Гомумән башкорт җирләрендә әвәлгедән бирле яшәүче халыкларның, бигрәк тә татарларның, социаль төркемнәре шактый катлаулы һәм аларның җиргә булган хокукларына карап тагылган исемнәре дә күп. «Мишәр» терминына карата шуны әйтергә кирәк: бу термин этник үзаң буларак (1926 елгы сан алу вакытында), Башкортстанда яшәүче мишәрләр, бигрәк тә аларның «җирле» төркемнәре тарафыннан гына кабул ителгән. Ә менә әвәлге Рязань, Пенза, Түбән Новгород, Сембер губернияләрендә яшәүчеләр ул терминны мыскыл итү өчен тагылган ләкаб дип кабул итәләр. Чөнки аларның этник үзаңы инде күптән, бәлки Казан татарларыннан алдарак та, «татар» булган.

Соңгы дәвердә Башкортстанда татарларны киметү хисабына башкортларның санын арттыру тенденциясе күзәтелә. Мәсәлән, 1970 һәм 1979 елгы сан алу материаллары буенча шушы 10 ел эчендә республикада татарлар 4 меңнән артык кешегә кимегән. 2002 елгы сан алу нәтиҗәләре әлегә билгесез. Бу юлы да фальсификациянең булуы бик ихтимал.

Башкортстанның төньяк-көнбатыш районнарында яшәүче татарларга соңгы вакытларда «яңа башкортлар» дигән исем тага башладылар. Бу нормаль күренеш түгел, билгеле. Биредә бит кычкырып торган ике зур халык яши. Аларның берсе – татарлар (аларның мәдәнияте, игенчелек һәм утрак көнкүрешкә нигезләнгән), ә икенчесе – башкортлар (аларның үзенчәлекле мәдәнияте мал асраучылык, күчмә тормышка барып тоташа).

Һичшиксез, озак еллар барышында бу ике халыкның этнокультура бәйләнешләре ныгыды. Ләкин бу әле Башкортстанда яшәүче татарларның этник

(милли) үзаңы инде үзгәрде һәм анда «яңа башкорт»лар барлыкка килде дигән сүз түгел. Этносны алай гына яңартып булмый. Этник процессларының юнәлеше турында фикер йөртү зур һәм объектив фәнни өйрәнүләр нәтиҗәсендә генә мөмкин. Бу юнәлештә ялгышлыклар, саксызлыклар, республикадагы этнодемографик вәзгыятне бозып күрсәтүгә китерә.

Себер һәм Әстерхан татарларын сан алу анкеталарында аерып күрсәтү, минемчә, милләткә әллә ни куркыныч түгел. Бәлки бу, киресенчә, аларның этник үзаңнары («Себер яки Әстерхан татары» формасында булса да) ныгуга этәргеч бирер. Аларның нигезендә барыбер «татар» этносы ята бит. Хәер бүген татарларны административ-территориаль чикләргә (Татарстан, Башкортстан, Себер, Әстерхан һ.б.) генә сыйдырып булмый, чөнки аларның этнос (милләт) булып формалашкан территориясен бөтен Россия җирләре тәшкил итә. Милләтләрнең үсүе объектив күренеш. Ләкин бу объектив күренешкә, еш кына, субъектив шартлар (сәясәт, дәүләт тарафыннан эшләнгән җирле административ чикләр, дини бысым һ.б.) комачаулый. Объектив шартларда барган этник (милли) процессларда татар милләте югалмас, чөнки аның этномәдәни җегәре ифрат зур әле.

## *II бүлек*

*И.Г.Закирова,*
филология фәннәре кандидаты,
ТӘҺСИнең фәнни хезмәткәре

### *Кукмара районында яшәүче татарларның уен һәм йола фольклоры*

Йола һәм уен фольклоры халыкның этник тарихын, дөньяга карашын, тормыш-көнкүрешен өйрәнү өчен кыйммәтле чыганак булып тора. Йола поэзиясе — ул күптөрле йола, гореф-гадәтләр, бәйрәмнәргә бәйләнешле шигъри әсәрләр. Йола фольклорын гадәттә ике өлешкә бүлеп өйрәнү кабул ителгән: календарь йола поэзиясе һәм гаилә-көнкүреш йола поэзиясе. Шулай ук уеннар да, йола фольклоры белән тыгыз бәйләнештә булып, халыкның поэтик иҗаты белән үрелеп бара.

Татарстанның Кукмара районында оештырылган фольклор экспедициясендә тупланган материалның күбесе фольклорның шушы ике жанрына карый. Экспедиция вакытында фольклорчыларга мәгълүм йола-уеннар белән беррәттән яңа, әлегә кадәр билгеле булмаганнары да язып алынды. Язып алынган материал Кукмара төбәгендә яшәүче татарларның да, керәшеннәрнең дә йолаларын шактый тулы күзалларга мөмкинлек бирә, тулы картина тудыра.

Әмма йолалар турында сүз барганда, шуны да әйтергә кирәк: аларның күбесе өлкән буын вәкилләренең генә хәтерендә сакланып, актив яшәештән төшеп калган. Өлкәннәр еш кына йолаларны бутап та җибәрәләр яки йола-уеннарның аерым фрагментларын гына хәтерлиләр. Ә уеннарны яшьләр, Сабантуйларда өлкәннәр дә хәзер дә уйныйлар, алар шуңа күрә яхшырак сакланган.

Кукмара районында татар һәм керәшен татарлары, удмуртлар һәм марилар үзара аралашып яши. Бу бәйләнеш фольклорга да үтеп кергән. Бер халыкның фольклор мотивлары, уен-йолалары икенчеләренә күчкән яки уртак иҗатка әверелгән.

Язып алынган материалларның зур күпчелеген календарь — йола поэзиясенә караган материаллар тәшкил итә. Календарь — йола поэзиясе дигәндә, елның төрле фасылларына караучы аграр-практик ихтыяҗлар белән бәйле йола-бәйрәмнәрне күз алдында тоталар. Хәзергә шуларга кыскача тукталып китик.

Йола-бәйрәмнәрнең беренчесе — Нардуган, ягъни Юлиан календаре нигезендә Яңа елны каршы алу. Нардуган кичәләрендә Яңа елга багышлап теләкләр әйтелгән. Алар Нәүрүз теләкләренә якын торалар. Илгә-көнгә иминлек, тынычлык, байлык телиләр. Нардуган көннәрендә карт-карчык булып киенеп, битләрен корымга буяп, туннарын, бүрекләрен әйләндереп киеп йөрүчеләр булган. Бу киенгән кешеләрне исәкәйләр яки шамакайлар д.а. Алар өйдән өйгә кереп биеп күрсәткәннәр, таба, мич капкачы кагып көй чыгарганнар. Исәкәй өчен махсус сый да әзерләп куйганнар. Нардуган бәйрәме турында материал Югары Чура авылында яшәүче информант Егорова Зоядан язып алынды. Егорова Зоя аның 7–18 гыйнварда уздырылуын әйтте. Нардуган көннәрендә халык утырмага йөргән. Төрләнеп, ягъни төрлечә киенеп тә йөргәннәр. 13 гыйнварда кызлар төшлек салганнар, фал ачканнар, кемгә кияүгә

чыгасын юраганнар. Нардуган вакытында башкарыла торган “читән кочу”, “кое бурасы ясап юрау”, төшлек салу һ.б. фаллар язып алынды.

Исәкәй булып киенеп йөрү керәшеннәрдән татарларга күчеп, аулак өйләргә дә кергән. Теркәш авылында яшәүче информант Гайфуллина Фәизә Динмөхәммәт кызыннан “Исакай”, ягъни аулак өйләрдә күңел ачу уены турында мәгълүмат язып алынды. “Исакай” иске тун яки тунын әйләндереп киеп керә, таяк тоткан, капчыгы була, һәр кешедән берәр әйбер ала. Яшьләр “Исакай килгән, бабай килгән, күчтәнәч алып килгән”, — дип каршы алалар. Ул “күчтәнәчен” тарата. Керәшен татарларының “Нардуган” “исәкәйләре” аулак өйләргә килеп җитеп импровизацияле уен-тамашага әйләнгән. Ул аулак өйдәге яшьләрнең күңелен күтәрергә юнәлдерелгән уен.

Кукмара төбәгендә язып алынган икенче йола — “Тукмак сугу”. Төркәш авылында яшәүче информантлар Гайфуллина Фәизә Динмөхәммәт кызы, Сәләхиева Халисә Зәкиҗан кызы, Асриева Мөэминә Габделгазиз кызыннан шушы йола турында материал язып алынды. Тукмак сугу — язгы беренче уен-йола. Кар эреп бетүгә башланган, бер атнага сузылган. “Кар бетүгә, казык сугып, шуңа тукмак сугалар иде. Бакча башында, яки ындыр амбарында, бакча киртәләренә дә сугалар иде. Кызларның бар эше шул була иде”, — дип сөйли Гайфуллина Фәизә әби. Тукмак сукканда, барлык кызлар билгеле бер ритм белән, тезелешеп басып, көй чыгарып икешәр тукмак белән сукканнар, бик матур тавыш чыккан, үзләре шул көйгә биеп тә торганнар. Тукмак тавышын ишетеп егетләр җыелган. Бу йола бик борынгы йола дип уйлыйбыз. Информантлар аның иген уңышы мул булсын өчен башкарылуын әйтәләр. Бу җир-ананы, табигатьне кышкы йокыдан уятуга корылган йола да булырга мөмкин. Березняк авылында яшәүче информант Абдуллина Әминә Хәкимҗан кызыннан Симек турында мәгълүмат алынды. Бу көнне яшьләр урманда бер каен агачын сайлап, аңа төрле тасмалар, яулыклар бәйләп, агачны бизәп кайтканнар. Аннан халык зиратка килгән, әби-бабайларны искә алып каберләргә ризык куйганнар. Аннары зират янындагы болында бәйрәм узган. Бәйрәмдә керәшен татарлары, удмуртлар гына түгел, татарлар да катнашкан, информант әйтүенчә, болыннан кайтышлый бөтен кеше чәчәкләр җыеп кайткан. Симек Троицадан бер атна алда узган. Ә Троицаны керәшеннәр яфрак яки каен бәйрәме дип атаганнар. Фольклорчы галим Р.Ягъфәров аның җир-су ияләрен, табигатьне олылау йоласы буларак үткәрелүен әйтә. Безгә Троица турында материал очрамады. Әмма Югары Чура авылында яшәүче информант Анастасия Михайлова “Майлы ботка” дигән йола-бәйрәм турында сөйләде. Информант әйтүенчә, ул Симектән соң бер атнадан уздырыла. Авыл халкы һәрбер йорттан берәр стакан ярма җыя, чиркәү янындагы берәр йортта җыелган ярмадан ботка пешерәләр. Олылар өйдә ашый, табак белән урамда уйнаучы балаларга чыгаралар, “Еллар имин булсын, халык таза булсын, икмәкләр уңсын, Ходай дәүләтне күп итеп бирсен”, — дип иман укыйлар. Шуннан соң чәчүгә чыгалар. Поплар тубал белән чыккан ашлыкны арулапдыралар. Җиргә йомырка сибәләр, балалар йомырка җыялар. Бу чәчүгә чыгу алдыннан үткәрелә торган, орлыкны изгеләндерү белән бәйле йола. Күрәсең, ул “Шыйлык” йоласының үзенчәлекле вариантыдыр. “Шыйлык”та да “Майлы ботка”да да йоланың төп максаты келәү әйтүгә, орлыкны изгеләндерүгә кайтып кала.

Борынгы мәҗүси йолалардан булып, тора-бара үзенең беренчел мәгънәсен югалтып балаларның күңел ачу йоласы булып калган йоланың берсе — “Зәрә боткасы”. “Зәрә” яки “Зәрә боткасы” язгы чәчүгә төшәр алдыннан, Сабантуйга берничә көн кала уздырылган. “Зәрә боткасы” турында материал Березняк авылында

яшәүче информант Абдуллина Әминә Хәкимҗан кызыннан язып алынды. Балалар зәрә буласы тауга менеп кычкырып җырлап зәрә буласын белдергәннәр.

Зәр-зәр-зәрәки
Иске-москы кәзәки.
Кәзәкиең булмаса,
Кешенекен ал да ки.

Халык бу чакыруны ишеткәч, төш пешергән, конфет әзерләгән, йомырка буяганнар. Бала-чага таңнан кызыл башлы сөлгедән тегелгән капчык асып йомырка, төш, ярма, май җыйган.

Алар:

Ай-ай-ай, диләр,
Шәяхмәтне бай диләр,
Бирәр кашык май диләр, — дип җырлаганнар. Шуннан су буенда казан утыртып барлык ярма, майларын салып ботка пешергәннәр. Авыз итәргә өйгә дә алып кайтканнар, төрле уеннар уйнаганнар.

Зәрә боткасыннан соң Сөрәнгә чыкканнар. Ат менгән егетләрнең йомырка җыюы һәм аны пешереп ашаулары — сөрәнгә чыгу д.а. Төркәш авылында яшәүче Сәләхиева Халисә Зәкиҗан кызыннан Сөрәннең нәкъ шушы борынгы варианты язып алынды. Хәзер Сөрәнгә чыгуны Сабантуена бүләк җыю итеп күзаллау бар. Бу алай түгел.

Сөрәнгә чыккан егетләр барсы да бик матур итеп шул заман модасы белән киенгән. Алар атларын матур итеп бизәп, ат койрыкларын бизәп бәйләп атка атланып сөрән әйтеп барганнар.

Сөрәнгә, Сөрәнгә,
Сөрән бирегез,
Абыстайлар, абыстайлар —
Түтәйләр!
Бирегез күкәйләр
Сөрәнгә, Сөрәнгә, — дип кычкырып барганнар.

Җыелган күкәйләрне ялгыз кешегә кереп буяганнар, пешергәннәр. Атка атланган егетләргә авылның бөтен бала-чагасы ияргән. Аларны да матур итеп киендергәннәр. Егетләр җыелган күкәйдән бала-чагага да өлеш чыгарган. Балаларның күкәй бүлешеп сугышып алуы да тамаша булган.

Сөрәннән соң Сабан туе уздырылган. Ул хәзерге кебек чәчү беткәч түгел, ә чәчүгә чыгар алдыннан уздырылган. Бу йола-бәйрәмнәр барысы да салкын кыштан соң табигатьнең уянуына, үзләренең исән-сау булуына шөкерана итүгә, илгә-көнгә муллык теләүгә, җир-ананы зурлауга кайтып калган.

Төркәш авылы информантлары әлеге йола-бәйрәмнәрне дүртәү дип, санап күрсәттеләр. Иң беренчесе “Тукмак сугу”, икенчесе “Сөрән”, өченчесе — “Сабантуй”, соңгысы “Җыен”. Төркәш авылында арыш урагына төшкәч “Төенчек җыены” уздырылган. Халык иртә белән арыш урагы урап кайткан. Төштән соң җыен башланган. Ул 3 көн дәвам иткән. Аның базары да булган. Һәр авылның үз җыены булган. Ул бер авылның иртәрәк, икенчесенеке соңрак уздырылган. Җыеннарны Җанбай авылы башлап җибәргән, ул Җанбай җыены д.а. Пыкрау вакытында Ишки авылы җыены уздырылган. Төркәш авылы Пенәгәр авылы белән бергә төенчек җыены уздырган.

Экспедиция вакытында йолалар белән бергә татар халкының бик күп уеннары да язып алынды. “Түгәрәк уены”, уенда җырлана торган җырлар, “бормалы” яки

“борылдырыш” уены, “Бармаклы”, “Вак бәлеш” уеннары, аларның җыр текстлары язып алынды.

“Вак бәлеш” уены “Каравай” уенын хәтерләтә. Балалар түгәрәкләшеп, җитәкләшеп басалар. Берәү уртада була. Аңа карап җырлап әйләнәләр:

Сафа Мәръям туена
Пешергәннәр вак бәлеш,
Вак бәлеш, вак бәлеш.

Бөтенесе бергә уртадагы кешене кысалар:

Без дә булдык ул туйда,
Без дә булдык ул туйда.

Уен җырларына һәр чорның проблемасы, шул чорга хас бизәкләр, үзенчәлекләр килеп кергән. “Бармаклы”, “Биеп алышлы” уеннары аулак өйләрдә уйналган. Бу уеннарның җырлары шактый үзенчәлекле. Аларда колхозларга беренче тракторлар кайту, хатын-кызларның тракторга утыруы, читкә эшкә китүләр — шул заман сулышы сеңгән. Мәсәлән, “Бармаклы” уенында болай дип җырлаганнар:

Тракторист — майлы крис,
Туктат тракторыңны.
Гомерлеккә сөяр идем,
Белсәм характерыңны.
Тракторист — майлы крис,
Майлый да карап тора.
Пока күңел юатырга
Ятлар да ярап тора.

Яки “Биеп алышлы” уенындагы җырлана торган җыр-кушымта:

Ага радиатор,
Эшләми карбюратор,
Сосать итә магнита,
Магнита, магнита,
Магнита илләрендә,
Сакланасың йөрәгемнең
Иң тирән җирләрендә.

Бу җырда авыл халкының читкә — Магнитогорск якларына төзелешкә китүе, шул якларда яшәве дә чагылып китә.

Безгә бик күп җырлы-биюле уеннарны Югары Чура авылында Галина Павловна Азина җитәкләгән “Тәңкәләр” балалар фольклор ансамбле күрсәтте. Ансамбль балалары башкаруында “Өчле”, “Бормалы”, “Түгәрәк” уеннары карадык.

“Өчле” биюендәге беренче карашка шаян җырның сүзләрендә дә трагедия ята. Сугыш вакытындагы яки сугыштан соңгы еллар фаҗигасе: ир-атның гарипләнеп кайтуы, сугышларда һәлак булуы, бөтен эшнең хатын-кыз җилкәсенә төшүе чагыла:

Ай-һилләү-һилләү-һилләү,
30 кызга бер кияү.
Анысы да аяксыз,
Йөри алмый таяксыз.

Яшьләр җәй көне болында түгәрәк уены уйнаган. Уртада гармунчы уйнаган, яшьләр түгәрәктә озын көйгә җырлап әйләнгәннәр. Гадәттә мәхәббәт турындагы җырлар җырлаганнар. Этнограф галим Флера Баязитова: “Түгәрәк уеннарына кызлар күп булып җыелып чыкканнар һәм кырда иген дулкынланган кебек

хәрәкәтләр ясаганнар, уңыш та шулкадәр яхшырак була дип ышанганнар", — дип, бу уенның асылын ача.

Югары Чура авылында туй-мәҗлес җырлары да язып алынды. Керәшеннәрдә туй-мәҗлесләр җырсыз узмый. Кунак сыйлау үзенчәлекле җырлар белән үрелеп барган. Туй йолалары буенча материал булмаса да, җырларга тукталып китәбез. Җырларны кара-каршы кодагыйлар да, киленгә атап та, килгән кунакларга рәхмәт әйтеп тә җырлаганнар. Кыз анасы:

Безнең урман куе урман
Боланнар асрагыз,
Кызыбызны сезгә бирдек,
Какмый-сукмый асрагыз, -

дип җырласа, егет анасы уены-чынын бергә кушып:

Пешереп бирәм белен,
Өйдәгеләр тышка чыкса,
Кисеп алырбыз телен, -

дип җырлаган. Хуҗалар мәҗлес буена кунакларын мактап җырласа, кунаклар киткән вакытта рәхмәт әйтеп җыр башкарган. Сәрдекбаш, Югары Чура авылларында солдатка озату йоласы, солдат җырлары да язып алдык.

Гомумән әлеге экспедиция вакытында фәнгә мәгълүм йола-уеннар гына түгел, яңалары да язып алынды. Аларны киләчәктә фәнни нигездә өйрәнү, тулыландыру таләп ителә.

*Р.Ә.Исхакова-Вамба,*
сәнгать фәннәре кандидаты,
ТФДҮнең әйдәп баручы фәнни хезмәткәре

# ***Кукмара районында халык җыр иҗаты* (2002 елда бирегә ясалган фольклор экспедициясе материалларына нигезләнеп)**

Кукмара районы, билгеле булганча, Татарстан Республикасының төньяк төбәгендә урнашкан. Монда татарлар (арада керәшен татарлары да бар) белән удмуртлар, марилар, руслар һәм башка милләт вәкилләре элек-электән бергә яшәп килә. Шуңа күрә бу район хаклы рәвештә этник төркемнәргә бай, күпмилләтле һәм гаять үзенчәлекле як булып санала.

2002 елның язында Татарстан мәдәният министрлыгының Татар Дәүләт фольклор үзәге әлеге районның төрле авылларына комплекслы фольклор экспедиясе оештырды.

Сәрдекбаш, Яңа Сәрдек, Зур Сәрдек, Чура, Березняк, Кече Чура, Бужи, Төркәш, Уразай кебек авылларны без җентекләп өйрәнеп-белеп, аркылыдан буйга иңләп чыктык.

Бу чыгыш-информациядә мин фольклор үзәгенең фәнни хезмәткәре Дания Арслsecurityованың музыкаль фольклор буенча җыеп, язып алган һәм эшкәрткән халык музыкасы, нигездә халык көй-җырларын күзәтеп узмакчы булам.

Экспедиция барышында барлап, табып, язып алган материалларны башлыча ике төркемгә бүлеп карарга кирәктер, чөнки саф татар халык җырларыннан тыш, биредә төрле чорда композиторларыбыз иҗат иткән җырлар да очраштыргалый. Әлбәттә, безнең төп игътибарны иң элек халык мирасы – җыр-көйләр җәлеп итте.

Куанычлы һәм характерлы факторларның берсе – бу якта киң тарлган һөнәр – итек басу, тула басуга бәйле такмаклар – хезмәт җырларының күп һәм еш очравы.

Күмәкләшеп, бергә-бергә эшләгәндә, һөнәрчеләр еш кына үзара аралашкан, алай гына да түгел, бер-берсеннән көлеп, шаян такмаклар уйлап чыгара торган булганнар. Язып алынган материалның нигезендә дә шул мәзәкчән шаян эчтәлекле җырлар ята. Көйлелек ягыннан бу куплетлар шактый җыйнак, аз ноталардан оешкан, ә форма ягыннан бу мәзәк такмакларның күбесе ике өлештән тора, ә бу үзе табигый рәвештә квадрат структура барлыкка китерә.

Шунысы кызык: әлеге төркемгә игенчелек темасына багышланган җырлар да бик якын һәм аваздаш. Мәсәлән, июль – Питрау бәйрәме көнендә башкарыла торган «Питрәү җыры» - шундый табылдыкларның берсе. Әйтергә кирәк, «Питрәү җыры», бигрәк тә керәшен татарларында киң таралып, еш башкарылган, башлыча туган-тумача, кунак-төшем, дус-ишне олылый, хөрмәтли торган, нигездә, сый хөрмәтле торган нигездә, сый – хөрмәтле өстәл артында җырлана торган иң популяр җырларның берсе саналып килә.

Ә менә «Суда-суда», «Бас әле», «Бормалы» кебек уен җырлары башлыча Татарстанның Апас, Буа якларында киң таралыш тапкан, инде күптән һәм төрле вариантларда язып алдырылган җырларны кабатлыйлар. Ә менә үзенең поэтик эчтәлеге, оригинальлеге ягыннан биредә язып алынган «Гөлбидән» исемле җыр

алардан шактый аерылып тора. Хәер, эчтәлеге белән ул да әлеге дә баягы яшь, чая кызларның бер-берсенә төртмәле, шаян-наян сүз әйтүгә кайтып кала сыман.

Гөлбидән

Кара-каршы Гөлбидән,
Зәңгәр күзле Бибидән.
Алсу йөзле Гәйнидән,
Чәчәк өсте Сәрвидән.

Сандугачым Зифадан,
Карлыгачым Бибидән.
Күгәрченем Гөлгенәм
Лачыным күл йөзеннән.
Авызы уймак Әсмәдән,
Кәкре армәк Гайшәдән,
Озын торнак Рәйсәдән.

Ялкау Сәлимәнеке,
Торкау Гадиләнеке,
Моңсу Кәримәнеке,
Тел бистәсе Бәдьядән.

Бу типтагы җырлар арасында «Ай, икегез, икегез» кебек шаян-тапкыр хәзерге заман туй җыры да киң таралыш тапкан.

Экспедиция йомгак-нәтиҗәсенең тагын бер ягы бар: Кукмара ягында күп санлы борынгы дини-дөньяви мөнәҗәтләр әле дә яшәп килә икән! Арада «Муса мөнәҗәте», «Күңел җәүһәрләре» кебек бик матур, сирәк эчтәлекле һәм яңгырашлылары да байтак жанрга хас булганча, мөнәҗәтләрнең күбесендә Аллаһы тәгалә, пәйгамбәр үзе, ахырзаман, тәмугъ һәм җәннәт, сабырлык һәм юмартлык кебек популяр дини төшенчәләр еш кабатлана. Ә менә көенең матурлыгы, колакка ятышлыгы, оригинальлеге ягыннан мин биредә язып алынган «Салават» көен билгеләп үтәр идем.

Җыелган мирас арасында лирик җырлар да байтак. Гаять киң таралыш тапкан «Авыл көйләре» («Ага сулар...» һ.б.) шулар рәтенә керә. Ә инде башка төбәкләрдә табылган җырлардан аермалык мәсьәләсенә килгәндә, шуны ассызыклап була: Кукмара ягы җырларының көйләренә керәшеннәрдән үтеп кергән квартага сикертү үзенчәлеге хас. Әмма биредә шуны билгеләп һәм атап китәргә кирәк: керәшен татарлары җырларының үзләренә дә татар көйләре йогынты-тәэсир ясамый калмаганнар. Мәсәлән, алда телгә алынган «Питрәү» җырында нәкъ татар җырына хас казенциядә авазның өч тапкыр кабатлану үзенчәлеге ярылып ята. Кыскасы, күпмилләтле, фольклорга бай Кукмара ягында татар һәм керәшен татарлары фольклорының бер-берсенә ясаган уңай йогынтысын бик күп мисалларда күрсәтергә булыр иде.

Йомгаклап шуны әйтергә мөмкин: әлеге экспедиция барышында гаять кыйммәтле һәм үзенчәлекле материал табылган. Шуларның кайберләрен генә санап китмәкче булам:

1. Данлы XX гасырны үтеп, яңа XXI гасырга аяк басканда, ягъни техника, кибернетика заманында да әле һаман күмәк көч-кул белән эшләгәндә туган хезмәт такмаклары җырлары яшәвен дәвам итә бирәләр!

2. Яңа гасыр башында да үткән гасырларда туган мөнәҗәтләр яшәп килә – арада «Салават» кебек гаять үзенчәлекләре дә очраштыргалый.

3. Хезмәткә, көнкүрешкә, гореф-гадәтләргә бәйле фольклор жанрлары да һаман исән. Керәшен татарларының «Питрәү җыры» - шундый куанычлы табылдыкларның берсе.

Сүземне йомгаклап, бер истәлек белән уртаклашмакчы булам. Сентябрь аенда, көтмәгәндә, Казан радиосыннан нәкъ менә Кукмара районында яңа табылган әлеге фольклор табылдыклары яңгырап алды. Гаҗәпләндергәне шул булды – кара син аны: гади генә, гаять киң таралыш тапкан «Авыл көенә» дә гаять лирик-мөләем эчтәлек, мәхәббәт-сөю аһәңе өстәп була икән, ләбаса! Әгәр элеккеге, традицион авыл көйләрендә сүз нигезендә Ватан, туган як, табигать бизәкләре турында барса, Кукмара районында без өр-яңа, заманга хас күренешкә юлыгабыз ич! Типик «Авыл көе» поэтикасы, акырынлап традицион шәһәр лирик җыр поэтикасы белән аралашып, яңа аһәң, яңа яңгыраш, яңа тәэсир тудыра ала икән бит! Ә бу инде үзе Кукмара ягы авыл көйләренең татар халык шигърияте һәм музыкасына яңа, бәрәкәтле табылдык-нюанслар өстәве хакында сөйли.

Кыскасы, халык авыз иҗаты өр-яңа XXI гасырда да, нәкъ элеккечә, тормыш-көнкүрешебездә булып торган үзгәрешләрнең гаять сиземле барометры булып тора ала әле.

*Л.Х.Ибраһимова,*
филология фәннәре кандидаты,
ТӘҺСИнең өлкән фәнни хезмәткәре

# *Кукмараның күңел бизәкләре*
# (Татарстанның Кукмара районына оештырылган фольклор экспедициясе нәтиҗәләре турында)

2002 елның 20 маеннан алып 29 майга кадәр без Татарстанның Кукмара районы авылларында булдык. Без дигәнем — Татарстан Мәдәният министрлыгының татар фольклорын җыйнау, саклау, өйрәнү һәм пропагандалау үзәгеннән — 6, Тел, әдәбият һәм сәнгать институтыннан — 2, барлыгы 8 кешедән торган экспедиция төркеме: җитәкчебез — әлеге үзәкнең директоры, филология фәннәре кандидаты Ф.Җәүһәрова, музыка белгече Дания Арсланова, рәссам-фотограф Рафаэль Сиражетдинов, этнограф Рәмзия Мөхәммәдова, фольклорчылар — филология фәннәре кандидатлары — Илсөяр Закирова һәм мин, оператор Рамил Җиһаншин, шофер егетебез Раил Сафиуллин. Экспедиция Фольклор үзәге тарафыннан оештырылган иде. Максатыбыз — халык иҗатын барлау, Кукмара халкы белән якыннан аралашып, кирәкле фольклор әсәрләрен һәм этнографик мәгълүматларны җыйнау.

Без 10 көн буе барлыгы 12 авылда һәм Кукмараның үзендә фольклорга, этнографиягә кагылышлы материаллар туплап йөрдек, аерым алганда, Сәрдекбаш, Уразай, Югары Чура, Кече Чура, Яңа Сәрдек, Зур Сәрдек, Аш Бужи, Кара Елга, Төркәш, Тырыш, Березняк (Бучирмә), Яңа Кукмара авылларында булдык.

Дөресен әйтим, күпне өмет итмәдем, ни дә булса таба алырбыз микән соң, дигән икеле-микелерәк уй белән килгән идем бирегә. Компьютер заманында бүгенге татар авылында әкият сөйләүчеләрне, дастан көйләүчеләрне, алар иҗатын буыннан-буынга тапшыручыларны очратуы кыен булачагы болай да аңлашыла бит. Ни дисәң дә, заман таләбе башкачарак, ихтыяҗ да бүтәнрәк бүген. Әмма Кукмара авылларында йөргәндә мондый уйлар тарала төште, халык иҗатының бүгенге көндә дә мул сулы саф чишмә булуына янә бер кат инандым. Саекмый да, саегырга җыенмый да әле ул. Тарихыбыз битләрен, халык тәҗрибәсен, акылын, тел җәүһәрләрен һ.б. хисапсыз хәзинәләрне ияртеп, ага да ага.

Әйе, халык белән аралашу күп нәрсә бирә, әллә ниләр белә безнең халык, белгәннәрен бер җепкә тезеп тә бирә — сөйләндер генә.

Без фольклор материалларын җыюны өйдән-өйгә кереп, әби-бабайлар белән әңгәмә кору рәвешендә башкардык. Иң олы яшьтәге информантка 88 яшь булса (Югары Чурадан Михаилова Анастасия Федотовна, 1914 елгы һәм Төркәштән Гайфуллина Фаизә Динмөхәммәд кызы, 1914), иң яшьләре — мәктәп яшендәге балалар (Югары Чурада “Тәңкәләр” керәшен фольклор ансамблендә катнашучылар). Алтмышынчы-җитмешенче елгы информантлар да очрап куя.

Бәетләр чыгаручы Фәүзия апа Баһавиева (1928 елгы, Сәрдекбаш авылы), көйләп мөнәҗәт әйтүче, риваятьләр белүче Саҗидә апа Мифтахова (1920, Уразай), “Назалы” уены турында тәфсилләп сөйләгән, ул уенның такмакларын әйтеп яздырган Фидалия Миннемуллина (1965, Сәрдекбаш), яшь күңелле, янып торган күзле, кирәк икән — җилкенеп “Чабата” биюен биюче, кирәк икән — җиренә

җиткереп авыл көйләренә җыр башкаручы Фирдәүсә Хөсәенова (1940, Уразай), Югары Чурадан җырга-моңга бай Зоя Егорова (1941), Клавдия Никитина (1917), Анастасия Михайлова (1914), кайсы уенны уйнап, нинди җырыбызны җырлап күрсәтик, дип ашкынып торган “Тәңкәләр” керәшен фольклор ансамбле (җитәкчесе — Галина Азина), җиңел сөякле биюче, көйләп мөнәҗәт әйтүче Рәйсә Хәлиуллина (1938, Тырыш), авыл тарихы белән кызыксынучы, бәетләр чыгаручы Вәкил абый Әхмәтҗанов (1939, Кара Елга), яшь булса да, туган як тарихына битараф булмаган Зөлфия Ибәтуллина (тумышы белән Күкшелдән, 1978 елгы), Төркәштән гаҗәеп кызыклы әңгәмәдәш, борынгы йолаларны энәсеннән-җебенә кадәр сөйләүче Фаизә Гайфуллина (1914), әллә никадәр файдалы мәгълүмат биргән Мөэминә апа Әсриева (1922), Бучирмәдән Әминә апа Абдуллина (1921) һ.б. — менә кемнәре белән истә калды Кукмара.

Кайбер материаллар белән сезне дә таныштырып китәргә мөмкин. Алар түбәндәгеләр.

## ТУКМАК СУГУ (йола уены)[1]

Иген уңсын өчен тукмак сугу була торган иде. Яз көне кар эрү белән сугалар иде тукмакны. Чирәм чыккан җиргә озын колга куя торганнар иде. Тукмакны кызлар суга иде. Һәр кызда икешәр тукмак ике кулга. Бөтенесе дә шул тукмаклары белән колгага бәрә торганнар иде. Бик матур чыга иде тавышы, авыл яңгырап торыр иде.

## КАЧКЫН ЧИШМӘ РИВАЯТЕ[2]

Иске зиратта чишмә булган диләр иде. Хәзер ул чишмә урынында зур таш тора. Ташка колакны куеп тыңласаң, чишмә тавышы ишетелә. Бер әкәй (мари милләтеннән булган хатын-кыз. — Л.И.) баласының пычрак чүпрәген шул чишмәдә чайкаган, шуннан соң чишмә җир астына качкан. Иске зират чишмәсен хәзер Качкын чишмә дип атыйлар.

## КАРА ЕЛГА ИСЕМЕНЕҢ КИЛЕП ЧЫГЫШЫ ТУРЫНДА[3]

Безнең авылдан ерак түгел элек кара урман булган. Ул кара урманда кара елга булган. Шул урманнан бер кеше, шушы үзән буйлап төшеп, безнең бакча башындагы елга буена килеп чыга. Монда су бар икән, дип карап торганда, су белән йомычка агып килгәнен күрә. Елга буйлап өскә менеп караса, Уразай авылына барып чыга. Аннары кабат төшеп, шушында төпләнә. Кара елга буеннан килгәнгә күрә, авылны Кара Елга дип атаганнар.

## АДАЙ АВЫЛЫНЫҢ ИСЕМЕ КАЯН КИЛЕП ЧЫККАН?[4]

---

[1] Татарстанның Кукмара районы Тљркәш авылында пенсионер Гайфуллина Фаизә Димљхәммәд кызыннан (1914 елгы) язып алынды. Язып алучы — Л.Ибраһимова.

[2] Татарстанның Кукмара районы Уразай авылында пенсионер Мифтахова Саҗидә Гыйнуан кызыннан (1920 елгы) язып алынды. Язып алучы — Л.Ибраһимова.

[3] Татарстанның Кукмара районы Кара Елга авылында пенсионер Әхмәтҗанов Вәкил Шакирҗан улыннан (1939) язып алынды. Язып алучы — Л.Ибраһимова.

[4] Татарстанның Кукмара районы Аш Бужи авылында Ибатуллина Зљлфия Миннехан кызыннан (1978 елгы, тумышы белән Күкшелдән, Зур Сәрдектә “Туган якны љйрәнү” түгәрәге җитәкчесе) язып алынды. Язып алучы — Л.Ибраһимова.

Көннәрдән бер көнне зур кеше — Алып бабай бер авылда җир сукалап йөргән кешене күтәреп өенә алып кайта да әтисенә күрсәтә. Әтисе әйтә: “Улым, син ходай кешесен тоткансың, җибәр аны. Алар — бездән соң яшәячәк кешеләр”, — ди. Бу сүзләрне ишетеп торган җир сукалаучы, Алып бабай аны авылына кайтарып җибәргәннән соң, иптәшләренә бар ишеткәнен сөйләп бирә. Ул “ходай кешесе” дигәнне Адай дип аңлап, без Адай кешеләре икән, дип сөйли. Шуннан авылны Адай авылы дип йөртә башлыйлар. Бу Адай авылы хәзерге урынында булмый, тау башында була. Хәзерге Адай авылы — элек марилар яшәгән җир. Адайлар аларны куып, бу урынга үзләре төшеп утырганнар. Марилар киткәндә:

— Киттек, киттек, — дип җырлап киткәннәр, Бөрнең аргы ягына чыгып урнашканнар да шунда яши башлаганнар. Шуннан ул мари авылын Китәк дип атый башлаганнар.

## ИСТӘЛЕК[1]

Безнең Уразай мәчете — борынгы мәчет. Колхозда Галимулла дигән кеше рәислек иткән заманда мәчет манарасын кисәргә маташтылар. Уразай — бик дини авыл. Аның исеме дә Ураза ае дигәннән алынган бит. Шуңа күрә авылда мәчет манарасын кисәргә ризалашучы табылмады. Шуннан Галимулла манараны кистерергә дип чирмешләрне чакырып караган. Кисүче табылмагандырмы, Галимулланың үзен дә “өстән” бик кысмаганнардырмы — мәчет манарасы киселми калды.

## “БОРМАЛЫ” уены[2]

Бормалы уенында яшьләр парлашып, кара-каршы тотынышып тезеләләр. Берәү так кала. Так калган кеше үзе сайлаган егетнең яисә кызның артына әкрен генә килеп баса да, аны салмак кына алга таба этә. Этелгәне аңа каршы борылып баса, алар парлашалар. Этеп чыгарылганы янә пар эзләп китә. Уен шулай дәвам итә. “Бормалы” уены тоташ җыр җырлап башкарыла. Дүртьюллык җырлар җырлана. Көе салмак.

Алмагачның алмасын
Ал булмый ашамыйлар.

Яратмагач башламыйлар,
Яраткач ташламыйлар.

Аклы ситса күлмәгемне
Кимәгән булыр идем.
Болай икәнеңне белсәм,
Сөймәгән булыр идем.

Кашың кара, кашың кара,
Кашың кара кыйгачтыр.

---

1 Татарстанның Кукмара районы Уразай авылында пенсионеры Мифтахова Сажидә Гыйнуан кызы (1920елгы) сөйләгәннәрдән. Язып алучы – Л.Ибраһимова.

2 Татарстанның Кукмара районы Уразай авылы шәл бәйләүчесе Хльсәенова Фирдәусә Габдрәшит кызыннан (1940 елгы) язып алынды. Язып алучы — Л.Ибраһимова.

Синең сөйгән ярларың да -
Үзең күк карлыгачтыр.

Кукмара авылларында фольклор экспедициясендә йөреп, шактый гына бәет, мөнәҗәтләр, топонимик риваятьләр, мифологик хикәятләр, халыкның җырлы-биюле уеннары, авыл көйләре, им-том, йолалары һ.б. материаллар туплый алдык. Кукмаралылар вакытын да кызганмый, озаклап сөйләшеп утыра, белгәнен сөйли, дөбердәтеп “Чабата” көенә биеп тә күрсәтә, искитәрлек кул эшләрен — чиккән сөлгеләрен, мендәр тышын, тәрәзә өлгеләрен, шәлләрен җәеп сала. Күрә бел, ишет, соклан гына һәм арасында энҗе бөртегедәйләрен сайлап, хәтереңә биклә, язып ал.

Шулай итеп, ап-ак чәчәктә утырган бакчалары, матур, зәвыклы, төзек йортлары, тырыш, һөнәрле кешеләре белән зур канәгатьләнү хисе уяткан Кукмара районы биредә яшәүче кешеләрнең халык иҗатына булган уңай мөнәсәбәте белән тагын бер кат сокландырды.

Экспедиция нәтиҗәләре турында һәм тупланган материаллар арасында аеруча игътибарга лаеклыларын республикабызда чыга торган “Мәдәни җомга” гәзитендә “Кукмарада җыйган ак чәчәкләр” дигән мәкаләдә чагылдырдык.

# *III бүлек*

*Р.Г.Мөхәммәдова,*
тарих фәннәре кандидаты,
ТФДҮнең әйдәп баручы фәнни хезмәткәре

## *Иван Николаевич Юркин тарафыннан XIX йөз ахырында җыелган татар халык сюжетлы җырлары*

Иван Николаевич Юркин, Сембер губерния архивы комиссиясенең әгъзасы, XIX йөзенең ахыры – XX йөз башында эшләгән фольклорчы–этнограф. Ул Сембер губерниясенең Буа өязендә чуаш гаиләсендә туа (туган елы билгесез). Аның, Ульян өлкә архивында, 269нче номер астында, сакланган кульъязма фондында (Ф.269, Оп.1, ед.хр.12) татар халкының ***мишәр*** төркеме этнографиясенә караган материаллары да байтак. Без түбәндә шулар арасында сакланган сюжетлы җыр һәм бәет үрнәкләрен китерәбез (кызганычка каршы, аларның ноталары бирелми).

Кульъязма җыентыгында китерелгән искәрмәсендә Иван Николаевич түбәндәге белешмәләрне бирә. Бу җырлар аның тарафыннан 1895 елның көзендә Сембер губерниясе Корсунь өязе Оборит авылындагы аракы заводына вакытлы эшкә килгән татарлардан язып алынган (ул үзе анда надсмотрщик хезмәтен үтәгән). Заводка күбрәк Корсунь өязенә караган Стрельниково (Сезюки), Голышевка (Аксу), Дракино, Горинка, Ногаево (Нугай) авылларыннан килә торган булалар. Бу авыллар, безнең этнографик өйрәнүләргә караганда, шактый үзенчәлекле булган Ләмбрә төркеменә карыйлар[1]. Аларның материаль культурасында, мәсәлән, хатыннарның гадәти киемнәрендә, XX йөз башларына кадәр ***сылавыч***, ***тастар***, ***кашбау*** кебек борынгы башкиемнәре яшәп килә. Рухи мәдәниятләрендә дә, татар халкының башка төркемнәрендә сирәк очраган, яки бу вакытларда бөтенләй дә, очрамаган йола–гадәтләр: үсмер малайны җиткән кызга өйләндерү (гаиләдә эшче куллар җитмәгән очракта), кызны кияве йортына озатканда ***елату*** (кыз елату) һәм алар белән бәйле йола җырларының булуы. И.Н.Юркин җыйган сюжетлы җырлар арасында укучы аларны да очратыр. Шулай да җырларның күбесе сөю–мәхәббәт белән бәйле; читкә, вакытлы эшкә, солдат хезмәтенә китүчеләргә карата чыгарылганнары да бар. Бәетләр, мәсәлән, Әбделмән Кунич «Аючылар» бәетләренең өзекләре (җирле вариантлары) бирелгән, ләкин җырларның исемнәре күрсәтелмәгән, һәм алар тематика буенча да бүленмәгән. Без дә И.Н.Юркин кульъязмасындагы тәртипне сакларга булдык, чөнки максат - бу җырларга фәнни анализ ясау түгел, ә аларны халыкка, галимнәргә җиткерү.

Күрсәтелгән (фондта китерелгән 25 җырның беренче егермебере Стрельникова (Сезюки) авылы кешесе Вәлиулла Рәхмәтуллиннан, ә калган дүртесе Горинка авылыннан килгән Якуп Ягудиннан, 1895 елның 8 сентяберендә язып алынган.

1

[1] Мухамедова Р.Г. Татары-мишары (историко-этнографическое исследование)/ Р.Г. Мухамедова. – М.: «Наука», 1972. – 247 с.

Биек тау башында күренә,
Дуслар, күп илләр.
Нафкасыни, малын эзләп,
Зая була, дуслар, күп ирләр.
    Ары барма, җаным, кайт кире,
    Бар да бер Ходайның тәкъдире.
Сары сандугач балалары
Камыштан оя, әй, ташыйдыр,
Сораек Алладан тәүфикны,
Тәүфиксызлык башны ашыйдыр.
    Ашаганда–эчкәндә дуслар күп,
    Башка эшләр төшсә, кем дә юк.
Кечерәк атым күк ала,
Тезгененнән тотты ир бала.
Ир балакай ни бәхетсез,
Суга баткан кебек югала.

2

Диңгез өсләрендә кораб йөри,
Һавадагы йолдызга багып.
Йөрмәдек тегел, күп йөредек,
Яныкаем, инде кайтырга вакыт.
Ишек төбем күк кәгазь,
Ут кабыныр диеп куркабыз.
Безнең яныкайлар икенче илдә,
Ятлар алыр диеп куркабыз.
Киек–үрдәк баласын кайда асрый,
Дангал стебында күлләрдә.
Ике–өч яштем син яшмәдең,
Синең күңелең әллә кайларда.
Минем беләзегем ике пар,
Берсе иңле булса да, берсе - тар.
Ялындырма егет ярың белән,
Яшьтән сөйгән ярым тагы бар.

3

Ай–хай, Сембердәге түрәләр,
Ука катыш камчы үрәләр.
Безнең генә азиз башларыбыз,
Бигрәк яшьли нужа күрәләр.
Сикереп кенә мендем,
Сикереп төштем.
Җелпердәп торган боз өчен,
Ай да йөрмәдем, ел йөредем.

Яшел шәл бәйләгән кыз өчен.
Кара урманнарда җил уйныйдыр,
Бал белән тулгандыр муртасы.
Ике сүз әйтә алмыйм – калтырыйсың,
Әллә ник яникам, куркасың.
Кара урманнарның уртасында,
Кортлар бал ташыйдыр муртага.
Яныем, илегезгә баралмыймын,
Дошманнар алалар уртага.

4

Безнең илнең такыры.
Йөз комганның бакыры.
Яз да бетте, көз дә җитте,
Без китәрбез ахыры.
Ике туры ат, берсе - зурырак,
Тотып булмый, дулыйлар.
Егет матур, кызы чибәр,
Йөзек салыш уйныйлар.
Әйдә, яныкай, су буена,
Кашың кара, юарсың.
Кил уйныек, кил сөешик,
Яшь күңелебез юансын.

5

Балдыз куш гүренчә  салдырадыр,
Хрустальдан куйдыра бусага.
Балдыз куенында куш алма,
Бирче кулкаема кысарга.
Ни биектер мәчет манарасы,
Менә алмадым азан әйтергә.
Балдыз, ике күзем, сиңа әйтәмен,
Вакыт инде үгә китәргә.
    Ак тасма балдызның башында
    Боргаланма йизнәң каршында.

6

Тәрәз карнизына кунып сайрый,
Койрык – карлыгач.
Ак куяннар кебек әрнешербез,
Туган–үскән илдән аерылгач.

Бармадым муллага сабакка,
Үләнә алмый киттем солдатка.
Кара–каршы ике думыгыз,
Уртасында яткан гуртыгыз.
Каршы чыксаң да, танымассың
Дүрт мең биш йөз солдат полкыбыз.
Елама, анай, ялан да,
Түгелгән нәфкабыз бар анда.

7

Имам мәчетнең алгысына,
Нинди хәзрәтнең таягы?
Без дә сорашмыйбыз, сез әйтмисез,
Сезнең бу кунак кыз кай ягы?
Карт-кош кунган кызыл какыга,
Без ярлыйбыз Сез дуслар хакында.

8

Мәскәү белән Питер арасында,
Телеграф йөри туктамый.
Солдат хәсрәтләрен хәсерәтләп,
Күп төнләр узды йокламый.
Елама, анай кәбәм, һәр даем,
Садака бир йома көн саен.

9

Кызарып кояш чыга,
Шәүләсе бәрелә марларга.
Кич караңгы диеп килми калма,
Уятып җибәрермен таңнарда.
Крымка бүркеңне киеп кил,
Кич караңгы булса да танырмын,
Кич караңгы диеп килми калма,
Үзем каршы чыгып алырмын.
Нанкадан казаки син тектердең,
Аклы да күлмәгең ник кидең?
Кояш та ятмаган, ай да калыкмаган,
Тәрәзәм төбенә ник килдең?

10

Биек тау башында мәдрәсә,
Мәдрәсәдә сиксән тәрәзә.
Үз матурың белән кауша алмассыз,
Бер Ходай үзе бирмәсә.
Балавыз шәме кайда яна,
Уникеле күзле фонарда.
Безнең сөвешүләр җитәрме икән,
Өфе указы белән Казанга?
Егетләр атлар йиктеләр,
Йибәрделәр юлның үренә.
Матур кыз асраган әнкәләрне,
Утыртсыннар йәннәт түренә.

11

Биек тау башындагы мунчагыз,
Тау асларында булса иде.
Хәбибәкәй суга бара,
Ат эчергәндә булса иде.
Караңгы кичләрдә ялтырый,
Хәбиб буенда тәнкәсе.
Асыл кошмы икән, былбылмы икән,
Хәбибне асраган әнкәсе?
Кечерәк атым, күк-ала,
Вак атлап юлларны күп ала.
Ерласам, йөзем ояла,
Ерламасам, хәтерең кала.
Өстәл читендә нигъмәтем,
Алып авзыңа капсана.
Бездәй яшь балалар ни белә,
Кочагыңа алып ятсана.
Иртәрәк торып көтү сөрдем
Ындыр артындагы табунга.
Сүмимен түгел, бик севәмен,
Белгертмимен үзем сабырга.

12

Капкыннан куянны мин коткардым,
Арт саннары кара, буе ала.
Яшьтәй йөрәккәем котырып ала,
Күрсәм яшьрәк кыз бала.
Атларны бәйлиләр капкага
Ялан аяк белән басмага.
Һич бер хәйлә белән чыга алмасаң,

Чык яныкай, артка – бакчага.
Урамыгыз үтә мин узамын,
Яшел дугамны дугалап.
Бер генә кич ятып йоклар идем,
Яшьтәй йөрәккәем ут яна.
Тәрәзәң төбеннән мин узаем,
Тал таягы таянып.
Без йөрибез сезне күрер өчен,
Сез торасыз бездән оялып.

13

Олы юлкайларда телеграф,
Россиягә хәбәр йөретә.
Күз алдында йөри, кулыма төшми,
Шунсы йөрәгемне әрнетә.
Агиделне кичкәндә,
Веслам[1] сынды ишкәндә.
Бер дә ерларбыз, биш ерларбыз,
Исемә төшкән кичләрдә.
    Агыла болыт, агыламы икән,
    Югалган хәтер табыламы икән?

14

Олы юлкайлардан түрәләр килә,
Кемгә тияр аларның олавы.
Соратып, килешеп бирмәсәләр,
Әнкәсенә аның елавы.
Биек тау башында бөрлегән,
Тау аскайларында карлыган.
Карлыганнан кара күзгенәң,
Бөрлегәннән нурлы йөзгенәң.
    Нурлы йөзгенәңә гашыйк булдым,
    Ни әйтерсең ике күзгенәм?
Ай һай, урамы тар,
Урамында крыльчалар бар.
Ул да крыльчаның өсләрендә,
Ак калпаклар кигән кызлар бар.
    Алма битең нурлы йөзгенәм,
    Ашыйк булдым ике күзгенәм.

15

[1] Веслам – ишкәгем.

Биек тау башында мәдрәсә,
Мәдрәсәдә сигез тәрәзә.
Севәркәңне сүмисең сүүвен,
Ник күңел аздырдың алайса.
Ак та гүренчәдә яшел дә кич,
Ялтырый, яныкай, якты кич.
Безнең яныкайлар туган икән,
Пигәмбәрләр корбан чалган кич.
Биек тау башында салкын күзләү,
Эчтем, яныкаем, яным күгәндә.
Ерак та юлны якын итеп,
Килдем, яныкаем, сине сүгәнгә.

16

Агиделкәйнең камышы,
Шавылдыйдыр җилдә, давылда.
Безнең үлемнәрне сорасагыз,
Верхний Шерхан дигән авылда.
Миннән калган окончаның[1]
Башкынасы тамар, кем ябар?
Яшь хәләлем кала, ул ир табар
Анай ятим кала, кем багар.
Яшь хәләлем киҗе тукыйдыр,
Ахыры миңа дигән күлмәккә
Аюым акыра, мине чакыра,
Ахыры әҗәлемә - үлмәккә.

17

Безнең ындырыбыз бик еракта,
Кырык кына тегел чакырым.
Минем яныкаем бик еракта,
Нинди хәйлә белән чакырыйм.
Кечерәк кенә кыз бала,
Итәккәен сызгана.
Кыз балага сүз әйтмәгез,
Аның яры кызгана.

18

[1] Оконча – русча “оконница” сүзеннән

Киек үрдәк төшкән йимешкә,
Исәпләсәм искенәм китә.
Башкынама төшкән шул эшкә,
Бадьян сиптем, гөл сиптем,
Гөлчәчкәмне җил түкте.
Теләгән теләгем бушка китте,
Теләмәгән ярга төш итте.
Аллы-гөлле яулыгың,
Һич тә ишетелми саулыгың.
Үз алмагачым булса иде,
Таянмас идем талларга.
Үз яныкаем булса иде,
Ялынмас идем ятларга.
Агиделкәйләрнең яры крута,
Ярыладыр кояш жарына.
Бик матур булсаң да, боегырсың,
Ярамагач сәүгән ярыңа.
Агиделнең тирәненә
Бәйләче егет салыңны,
Җәлләмичә егет бир малыңны,
Алырсың үз дигән ярыңны.
Олы алпутларның кучерләре,
Тауны менә атыннан төшмичә.
Кемне генә күрсәң, шул әйтәдер,
Ник йибәрдең сывырып үпмичә.

19

Сандугачлар сайрый сазларда,
Тавышлары безнең абзарда.
Саргайдым, бигерәк беттем,
Быелгысы, узган язларда.
Яңа ызбада шкафта,
Кулъяулыгым калды – ал яныем.
Мине генә ташлап ятны алсаң,
Оҗмахлардан мәхрүм кал яныем.
Алпутлар килер, узып китәр,
Алтын белән көмеш сатуы.
Гүр газабыннан катырак икән,
Ярың булып та, ялгыз ятуы.
Аргамаклар ялсыз, егет малсыз,
Малсыз егет була кадерсез.
Безгә Ходай сорап бирми,
Кешеләргә бирә бер сансыз.

20

Кызыл гына кызыл тубылгы,
Тирән коеларның бурасы.
Хурламагыз кызлар егетләрне,
Шул егетләр кызлар мулласы.
Егетләр баралар Самарга,
Самарларда печән чабарга.
    Үтәр-үтмәс чалгысы,
    Эчендә ян сүвәр кайгысы.
Кара урманнарда карама,
Кармадан кортлар бал ала.
Елама, канатым, алмас диеп,
Үземнең эчтә дә ут яна.
Кечерәк атымны мин йибәрдем,
Таяк астындыйн пар бара.
Минем сүвгәнемне сорасагыз,
Күзе сөрмәле, кашы кап-кара.

21

Алынлы-артлы куш кабак[1]
Калиткаларны, атам, такмадың.
Рәнҗүем, зур, әтеки, сиңа,
Сабыйдан[2] башка кияү тапмадың.
Тыкырык буе озын сельнича[3],
Кан'игәчләрем епләр ашлыйдыр.
Унике яшәр Айнуш киявем,
Кочакласам да, елый башлыйдыр.
    Кызлар бәйлиләр айлы шәл генә,
    Сабый балага буй кыз җәл генә.
Кан' анам куйган кияү ашларын,
Чыгып китмичә ашый алмадым.
Унике яшәр Айнуш киявем,
Ике-өч ел үтми башлый алмады.

22

Яңадан ук баскыч мин ясаттым,
Биек крилечтән менгәнчә.
Мин, канатым, сине онытa алмам,
Үлеп гүргенәмә кергәнчә.
Урамыгыз аша узган чакта,
Ялтыраб ук кала йиз йозак.

---

[1] Кабак - әдәби телдә "кабка".
[2] Сабый – егет булып җитмәгән малай мәгънәсендә әйтелгән.
[3] Сельнича – русча "сельница", сельник (өй алды белән тоташ салкын чолан, келәт) сүзеннән.

Китеп баручыга берни тегел,
Көтеп алучыга бик озак.
Тәрәз аша бодай сиптем,
Очып барган асыл кошларга.
Оҗмахларда урын бик күп диләр,
Егет сүгән матур кызларга.

23

Иртә белән тышка чыктым,
Кучатлар кычкыра торырга.
Бу дыр әти-әни язу[1] гынам
Кочаклап илттеләр карарга.
Әйдәгезче, дуслар, уйнарга,
Иртәгә килерләр кыварга,
Киттем яшь үмеремне еларга.
    Ашар ашкынабыз алмадыр,
    Ышанычкынабыз Алладыр.
Губерня урамы киң генә,
Алтмыш биш меӊ солдат арасында
Мөселман солдаты мин генә.
    Ашар ашкынабыз алмадыр,
    Ышанычкынабыз Алладыр.
Алпут садларын ни күрекләтә,
Галанский казның мамыгы.
Өч тә братымның арасында,
Күрдем бу дөньяның тамугын.
    Ашар ашкынабыз алмадыр,
    Ышанычкынабыз Алладыр.

24

Әбделмән купичның азбары,
Азбары гына тулы казлары.
Әбделмән купичны сорасагыз, дуслар,
Аструкта[2] узадыр язлары.
Әбделмән купичның атлары,
Тау буенда калган[3] кимерә.
Әбделмән купичны сорасагыз, дуслар,
Аструктан багып тилмерә.
Әбделмән купичның азбары гына,
Судлар йөри-йөрит саз булды.
Тугыз пот тартадыр кәгазь акча гынам,

---

[1] Язу - әдәби телдә “язмыш”.
[2] Аструк – рус телендәге “острог” ягъни “төрмә” сүзеннән.
[3] Калган – үсемлек.

Башымны йоларга аз булды.
Әбделмән купичның расшивалары
Аның флюгерләре сары ука.
Купич арасында олы купич иде,
Бер купич та алмыйдыр парукка.

25

Базарларга барып шыплар алдым,
Шыпларым коелды куеныма.
Чыгарга диеп талпынамын,
Дилбегәм тагылган буеныема.
Иртә белән торып тышка чыктым,
Сивай атым килә, үзем юк.
Гәүдәгенәмне судан чыгардылар,
Уң колагым белән күзем юк.
Базарларга барып плис алдым,
Яхия балама бүрке өчен.
Укыт, этеки Яхияне,
Ике дөньялыкның күрке өчен.
Урысча, мәләвен кычкыргачтан,
Минем сивай атым йикмәгән.
Әти йибәрәсең Канаутка,
Әллә байлыгыңмы йитмәгән.

*Л.П.Сотникова,*
ТФДҮнең фән эшләре буенча
директор урынбасары

## *Зәйнәп Максудова архивында мәкаль һәм әйтемнәр*

Татарстан республикасы Милли музеенда татар мәдәниятен чын шәрыкъчә комплекслы өйрәнгән мәгърифәтче галимә Зәйнәп Максудова архивы саклана. Архив шактый зур. Анда 188 кульъязма, 60 басма китап һәм 28 папкада гомер буе җыелган гыйлми тикшеренү материаллары саклана.

З.Максудова 1897 елда Алабуга өязе, Атбасар авылында туа. 7 яшеннән Иж-буби мәдрәсәсендә укып укытучы дәрәҗәсен ала. Ул балалар бакчасында, Алабуга мәктәбендә татар һәм рус теле укытучысы булып, 1920 елдан Ташкентта хатын-кызлар мәгариф институтында төрки телләр укыта. Шунда ук Ташкент университетының өченче курсын тәмамлый, 1922 елда Казанга кайтып балалар йортында, үзәк архивта, сәүдә техникумында дәресләр бирә, 50, 35, 80 казан татар мәктәпләрендә рус телен укыта һәм рус телен укыту методикасын булдыру өстендә эшли.1957 елдан педагогия институтында гарәп телен укыта. Дәүләт университеты һәм ИЯЛИ галимнәре белән борынгы кульъязмалар өстендә эшли. Бу эшнең

нәтиҗәсе буларак татар телендә аңлатма-белешмәләр белән С.Сараиның «Гөлестан Бит-төрки» (Х.Госман белән бергә) әсәре дөнья күрде.

З.Максудова гомеренең соңгы елларын онытылып бетә язган борынгы тарихыбыз, әдәбиятыбыз һәм гомумән югала язган, өзелә язган татар мәдәниятен ялгау, аякка бастыруга багышлады.

Бу олы хезмәт нәтиҗәләрен бастыру, халыкка җиткерүне без үзебезгә бурыч итеп куйдык һәм иң элек З. Максудова туплаган халык мәкальләрен һәм әйтемнәрен бастырырга булдык. Бу мәкаль һәм әйтемнәр арасында әле бер җирдә дә бастырылмаганнары шактый күп. Һәм монда әле архивта булган барлык мәкаль һәм әйтемнәр бирелмәгән. Аларны якын арада бастыру күздә тотыла.

## Халык әдәбиятында тел байлыклары

1. Туры (тугъры) әйткән туганына ярамаган
2. Кыңгыр эш кырык елдан соң да беленер
3. Димче диңгез кичерер
4. Ялкау бер эшлисен биш эшләр
5. Иренчәк ике эшләр
6. Биргән бигә яраган, бирмәгән нигә яраган
7. Биргәнгә биш тә күп, алганга алты да аз
8. Ачу агу, йотсаң дару
9. Даруның азы дару, күбе агу
10. Керүеңнән элек чыгуыңны бел
11. Йөргән таш шомара, яткан таш мүкләнә
12. Күп яшәгән ни белгән, күпне күргән ул белгән
13. Алты яшәр юлдан кайтса, алтмыш яшәр күрешә килсен
14. Ашаган белмәс, тураган белер
15. Өлешчегә өч үрдәк, өләшә белмәсә бере дә юк
16. Ат күрмәгән ат күрсә, кыйный-кыйный үтерер, тун күрмәгән тун күрсә, кага-кага бетерер
17. Сыерлар су эчкәндә, бозаулар боз ялый
18. Язгы бозның ястык калынлыгы, көзге бозның көзге калынлыгы
19. Урман — колак, кыр— күз
20. Йокы ястык теләмәс, мәхәббәт (сөю) җәмал (чибәрлек) теләмәс
21. Ярлының улы булганчы, байның колы бул
22. Иске байның бөлгәне — яңа байның байганы
23. Бай бөлгәнче илле ел, Ярлы байганчы илле ел туры кирәк
24. Байның авызы кыек булса да, сүзе төзек
25. Кул кулны җуа, икесе битне җуа
26. Аш ашка, урыны башка
27. Үрдәк бирсәң, каз алырсың
28. Майламыйча таба да шумый
29. Иртәгәсе өчен ишәк тә кайгыра
30. Каләм юынсаң, озын юынгыл ботыны; хатын алсаң, элек алгыл кутыны (кут - азык)
31. Алма агачыннан ерак төшми
32. Оясында ни булса, очканында шул була

34. Алма пеш, авызыма төш
35. Ни чәчсәң, шуны урырсың
36. Таш белән атканга, аш белән ат
37. Ит изгелек, кош явызлык
38. Яхшыга ияргә ярпайган, ямьлегә ияргән картайган
39. Яхшы сүз җан азыгы, яман сүз баш казыгы
40. Яхшы әйтер “мин юл куйдым”, яман әйтер “мин җиңдем”
41. Яхшылык җирдә ятмас
42. Вакыт акчадыр, гафил булма качадыр
43. Бер алдың, биш артыңа кара
44. Тапкан сөенгән, таныган алган
45. Сөйләшүең көмеш булса, тик торуың алтын булыр
46. Сабыр төбе - саф алтын
47. Бурның бүреге яна
48. Шикле чикмәнен ябына
49. Әйткән сүз — аткан ук
50. Ак булмаса пакъ булыр
51. Агармаса, бузарыр
52. Ашлык сукмак — кул чапмак, әйрән язмак — җан чыкмак
53. Ашыккан җитмәс, боерган җитәр
54. Ашыккан — ашка пешкән
55. Сайлаган базга, очраган тазга
56. Җиде тапкыр үлчә, бер тапкыр кис
57. Суккан җиргә ит бетмәс (үсмәс)
58. Кура ( ) белән сукканның хуры китмәс
59. Кул ярасы төзәлер, тел ярасы төзәлмәс
60. Батыр ярасыз йөрмәс
61. Эше юкның ашы юк
62. Эшләмәгән ашамас
63. Аягың лапылтамаса, авызың да чапылтамас
64. Корал эшләр, ир мактаныр
65. Өй салуның нисе бар: мүклисе (конопатить) дә чутласы (обтесать)
66. Киндер сугуның нисе бар: җиңги атты, мин кактым
67. Җитез идем, җил идем, давыл идем — җиде көнгә бер ыштан тегә идем
68. Байлык бер айлык, ярлылык гомерлек
69. Су чокырга җыела
70. Ил төкерсә, күл булыр
71. Аерылганны бүре ашар, бүленгәнне бүре ашар
72. Түшәгеңә күрә аягыңны суз
73. Юрганыңа күрә аягыңны суз
74. Күлеңә күрә чум
75. Югарыга карап фикер ит, түбәнгә карап шөкер ит
76. Яхшыга карап үрнәк ал, яманга карап гыйбрәт ал
77. Яхшыга ияргән ярпайган, яманга ияргән картайган
78. Иптәшең нинди, үзең шундый
79. Май чүлмәге тышыннан билгеле

80. Бар булса — тимер, юк булганы — алтын
81. Бар сөештерә, юк талаштыра
82. Утның башы бер очкын
83. Утны башында сүндерү кирәк
84. Алганда үзем генә алган идем; сатканда эти белән дә сата алмыйм
85. Файдасы файда, кара сыерның тиресе кайда
86. Итек алсаң, кунычы кала, сату итсәң, бурычы кала
87. Алтыга ал да, бишкә сат, атың булсын сәүдәгәр
88. Сатучыны алу өйрәтми, сату өйрәтә
89. Сабанда сайрашмасаң, ындырда ыңгырашырсың
90. Сабыр төбе - саф алтын
91. Ана — казна, ата — җизнә
92. Ятим бозау асрасаң, авызың-борының май булыр, ятим бала асрасаң, авызың-борының кан булыр
93. Тели белсәк — теләк, тели белмәсәң - имгәк
94. Карга теләве белән кар яумый
95. Ала каргада аласың булсын
96. Арбаның алды каян тәкәрләсә, арты шуннан тәкәрли
97. Кем чанасына утырсаң, шуның җырын җырларсың
98. Атасызны кияү итмә, анасызны килен итмә
99. Кызым, сиңа әйтәм, киленем, син тыңла
100. Иртә уңмаган кич уңмас, кич уңмаган һич уңмас
101. Коры кашык авыз ерта
102. Бишектәге бишкә төрләнер
103. Барлык ялтыраган алтын булмас
104. Алтынны букка (пычракка) буяган белән кадере китмәс
105. Дөнья куласа, бер әйләнә, бер баса
106. Уңган хатын арыш онын кәбаб итәр, уңмаганнар бодай онын харап итәр
107. Көлке көлә килер, артыңнан куа килер
108. Кеше көлкесе кешедән көләр
109. Кешенеке кештәктә, үзеңнеке үзәктә
110. Башың ярылса — бүрек эчендә, кулың сынса - җиң эчендә булсын
111. Утыз улың булганчы, усрак ирең булсачы
112. Ирдән калган хатынга Бохарадагы эт тычар
113. Кыек булса да юл яхшы, сукыр булса да, кыз яхшы
114. Аксак күп йөрер, сукыр күп күрер
115. Йокы язып, май чыкмас
116. Йокының коты да бар, батманы да бар
117. Хатын алмак ник кирәк, көн дә мал ит кирәк
118. Ит иткә, шурпа биткә
119. Бер тарыдан ботка пешми
120. Сукыр тавыкка бары да бодай
121. Тавык төшенә тары кергән
122. Безне төшле итеп булмас
123. Без капчыкта ятмас

124. Бер казанга ике тәкә башы сыймый
125. Җыруның җыртыгы юк
126. Әргәнчегә ни булса, биючегә шул булыр
127. Каш төзәтәм дип, күз чыгармыйлар
128. Аттан ала да туа, кола да туа
129. Аю баласын аппагым, керпе йомшагым дип сөяр
130. Бүре баласын бишеккә салсаң, иш булмас
131. Өеңа кереп ашыңны ашар, чыккач башыңны ашар
132. Үз үтермәс, чит ярлыкамас
133. Кашык—аяк шалтырамый тормый
134. Иләгенә күрә чиләге
135. Чиләгенә күрә капкачы
136. Ирсез хатын — җөгәнсез ат
137. Иргә ышанма, иделгә таянма
138. Ирнең үгәе юк, айсыз атны мактама, елсыз хатынны мактама
139. Ашамыйм дигән бер килен, алтмыш белен ашаган
140. Кыз баланың анасы кырык, кырык беренчесе чыбык
141. Көзге катык, көмеш кашык — кияү белән кызыма, язгы катык, ярык кашык — улым белән киленемә
142. Улың акырса түргә мен, кияу кикерсә ишек тоткасын тот
143. Кызлы йорт — гөлле йорт
144. Каен сеңле — каен шырпы
145. Олының кадерен белмәгән — олай изгелек күрмәс
146. Ачның кадерен тук белмәс
147. Ачтан казан астырма, туңганда ут яктырма
148. Кошсызның үзе туйса да, күзе туймый
149. Үзе юкның, күзе юк
150. Карама беләккә, кара йөрәккә
151. Юаштан җан чыгар
152. Үтмәс балта таш (бук) чапканда кирәк
153. Төкермә күлгә, барып суын эчәрсең
154. Якты чырай, такта чәй
155. Бала булса - шук булсын, шук булмаса - юк булсын
156. Бала — бавыр ите
157. Ана күңеле — балада, бала күңеле — далада
158. Тырманың сирәге яхшы
159. Өе биек, үрәсе сыек
160. Җылыга елан да ияләнә
161. Беткә ачу итеп, тунны утка якмыйлар
162. Туган туганының көтү көтүенә рад
163. Тимерне кызуында сук
164. Сатучы да товар бир, алмасаң да, карап кал
165. Барын-югын белмидер, бал телидер күңелем
166. Өенә күрә тәрәзәсе, үзенә хакына күрә дәрәҗәсе
167. Тамак мур, өст нур
168. Карга күзен карга чукымас
169. Алдан кычкырган күкенең башы авыртыр
170. Кешегә чокыр казыма, үзең барып төшәрсең

171. Карга теләге белән кар яумас
172. Белмәгәннең беләге авыртмый
173. Ак иделнең ар ягында инә саен бер сыер, барып карасаң — бер дә юк
174. Бүре баласын бүреккә салсаң да, иш булмас
175. Сентябрьда син дә бер, мин дә бер
176. Тауга карап тау була алмассың
177. Асылынсаң, агачның асылына асылын
178. Үзе егылган еламас
179. Үз кешеңне мичкә керсә, күтеннән танырсың
180. Еламаган балага имчәк бирмиләр
181. Егылганны түбәләмиләр
182. Чынлап торып еласаң, сукыр күздән яшь чыгар
183. Алла ташламаса, бүре ашамас
184. Үги ананың яхшысы — тәмугъ утының яктысы
185. Ашама бутка, барырсың судка
186. Алтын күргәч, ахун азган
187. Көндә кигәннең тәне (күте) ачык, атна кигәннең йөзе ачык
188. Урынсыз ужо дигәне утыз көл
189. Уйламыйча сөйләсәң, авырмыйча үләрсең
190. Чирен яшергән үлгән, бурычын яшергән бөлгән
191. Агачны чыбык чагында бөгү ансат
192. Мактанчыкның арты (күте) ачык
193. Җүләр үзен мактар
194. Оста барында кулыңны тый, мулла барында телеңне тый
195. Ак эт бәласы — кара эткә
196. Эт чаба дип бет чаба
197. Судан сылу булмассың
198. Җегет кешегә җитмеш төрле һөнәр аз
199. Этне төлке итә алмассың
200. Курыкканга куш күренә
201. Килен чиккән бер нагыш (нәкыш), ул да булса гел ялгыш
202. Елыйсы килгән бала атасының сакалы белән уйнар
203. Чибәрлекне табакка салып йөртмиләр
204. Чибәрлек туйда кирәк, кешелек көндә кирәк
205. Үзе кунак чакырган, үзе баланга киткән
206. Аяз көнне алма җый, болыт көнне балан җый
207. Бай кисә — котлы булсын, ярлы кисә — кайдан алдың
208. Ярлының көне ялыныч
209. Көрәге булса бугы табылыр
210. Эштән син курыкма, эш синнән курыксын
211. Кызлар бүрәнә ярыгыннан да көлә
212. Кыз чагында — кызыл чук, хатын булгач — кипкән бук
213. Табардан түрә булса, чабатасын түргә эләр
214. Татар телennән табар
215. Татар ашар да качар
216. Әләк әдәм үтерер
217. Бер сынаганны ике сынасаң, адәм көләр

218. Өметсез шайтан булыр
219. Сабыр иткән — морадына җиткән
220. Уен бер булыр, усрак ике булыр
221. Беренче ир — ил йоласы, икенчесе — йөз карасы
222. Гамәлгә күрә җазасы
223. Урыс мыекны кисмәс, кисмәсә дә бик үсмәс
224. Киндер көе — кубыз көе
225. Дигәндә — диңгездәй, димәгәндә — дуңгыздай
226. Урамыма чыкма, улымның чөкәенә басма
227. Бия колын бик типмәс, бик типсә дә, нык типмәс
228. Үзең бел, кешедән сора
229. Бер куй аркасында мең куй туйган
230. Маңка мәхәббәткә зарар итми
231. Татар барда, хәтәр бар
232. Ир чәкәшми сынашмый
233. Еланның телен белмәссең
234. Илгә чыккан иллене кунган
235. Кысыр аш кашык куйдырмас, тамак туйдырмас
236. Ишек төбеннән тапкан әйберне түрдән эзләмә
237. Бер курыккан эт өч көн өрер
238. Бер тиенлек эчкән, биш тиенлек исергән
239. Былтыр усырган быел сасысы чыккан
240. Ир бирмәк — җан бирмәк
241. Ир көннәмәгән — ишәк, катын көннәмәгән — калтак
242. Иртә өйләнгән улына- кызына куанган
243. Кунак ризкы белән килә
244. Кунак — иясенең ишәге
245. Кунак килсә, кот килер
246. Көйгән икмәк көңелдән китмәс
247. Биләнкене — биленнән, юбалгыны аягыннан белеп була
248. Бүрәнә аркылы бүре үтермиләр
249. Акырын барган куян артыннан җитәр
250. Киленне килгәч күрәләр
251. Атка менгәч, атасын оныткан
252. Ир какканны мир кагар
253. Ир кеше өйдә туар, кырда үләр
254. Исемә төште, исем китте
255. Әти мине кыйнаган, мин аны да тоймаган
256. Ике бармак арасында ит бетмәс (үсмәс)
257. Алдырыр көн, яздырыр
258. Дуңгызның ите симез булса да, ашарга ярамый
259. Ир кардәше — ишек янында, хатын кардәше — кашан янында
260. Үпкән, кочкан, җилгә очкан
261. Кызлар кысса, кырык көн чыдый
262. Куян тиресе әтәч кычкырган саен ертыла
263. Җитез үзен бетерер, акырын эшен бетерер
264. Бай баймасын, кояш байсын
265. Үзе йоклаганның бәхете дә йоклый

266. Кайда коймак, шунда кунак
267. Җөйсез йомырка гына була
268. Шодра йөрәк яндыра, шома хәтер калдыра
269. Сипкелле — сөяргә сөйкемле
270. Ятып калганчы атып кал
271. Балта чапканчы түмгәк ял итәр
272. Озын-озын чәнеч, үтүк белән җәнеч
273. Ертык тишектән күлә
274. Балта бирдем шөшле алдым — алдаладым татарны
275. Эт euкә, эт койрыкка сылтый (салына)
276. Көлдә аунасын, көнен күрсен
277. Күрәчәкне күрми гүргә кереп булмый
278. Татар байса хатын алыр, урыс байса чиркәү салыр
279. Килен кеше — ким кеше, алабай белән тиң кеше
280. Көяз туңмас — калтырар
281. Тыштан ялтырар, эчтән калтырар
282. Агайлар алганчы, җиңгиләр җыйганчы
283. Эрләмәгән - сукмаган шагай сиңа ыштанлык
284. Бәндә сөйли, тәкъдир көлә
285. Чырым тимәс, чыр итәр, чыбык төшсә тик торыр
286. Чыбык тисә чыр итәр, таяк тисә тик торыр
287. Бака сисә — күлгә файда
288. Байның эше фәрман белән, ярлыныкы — дәрман белән
289. Бәндә рәхәткә чыдамас, михнәткә чыдый
290. Биргәннең битенә карамыйлар
291. Җаны барның тыны бар
292. Кәҗәнең сакалы озын, акылы кыска
293. Ашау — байдан, үлем — ходайдан
294. Утынга барган, балтасын өйдә калдырган
295. Ашын ашаган, яшен яшәгән
296. Гомер ике килми
297. Буласы булган, буявы сеңгән
298. Бу көнге эшне иртәгәгә калдырмыйлар
299. Аз ашасаң - күп ашарсың, күп ашасаң - аз ашарсың
300. Татарга толмач кирәк түгел
301. Үлем ике килми
302. Йортка кергән — букка кергән
303. Дөньяны су басса, үрдәккә ни кайгы
304. Тәмле нәрсә күп булмас
305. Авызың кыек булса, көзгегә үпкәләмә
306. Авызың ни әйтсә, колагың шуны ишетер
307. Көтүче хатыны кич киенә
308. Үлгән сыер сөтле була
309. Күпне көткән аздан коры калган
310. Һавадагы кошка ышанып кулыңдагын җибәрмә
311. Ашаганда колагың селкенеп торсын, эшләгәндә йөрәгең җилкенеп торсын
312. Ат яхшысы аркада, ир яхшысы тарханда (иркенлектә)

313. Акчаның йозагы — саран, ашлыкның йозагы — салам
314. Айгыр кешнәмәсә, бия кешнәмәс
315. Туйган җирдән туган ил яхшы
316. Ирнең сүзе бер булыр
317. Ир кеше ике сөйләмәс
318. Ялганчы иясен тапмас
319. Матурлык туйда кирәк — мәхәббәт көн дә кирәк
320. Сүз сүзне чыгара, күбесе күзне чыгара
321. Әйтсәң — сүз, төртсәң — күз
322. Ни эзләсәң шуны табарсың
323. Адәм ята атлатмас
324. Биисе килмәгән аюга мәйдан тар
325. Мактаулы кыз туенда усыра
326. Үтә кызыл тиз уңа
327. Җете кызыл тиз уңа
328. Бар чагында — бүредәй, юк чагында — шүредәй
329. Кызганганны кызыл эт ашый
330. Кешене кызганган үзе кызганычка калыр
331. Капкан саен калҗа булмас
332. Эт авызына таяк тыкмыйлар
333. Сукырга таяк тондырмыйлар
334. Сукырга суд юк
335. Сөзә торган сыерга ходай мөгез бирми
336. Мүкләк сыердан мөгез сорамый
337. Сыйларга сыең булмаса, сөйләргә телең булсын
338. Ир сәфәрдә, ат тәртәдә беленер
339. Суфи суганны сөймәс, күрсә - берсен дә калдырмас
340. Кешегә калган көнең — таң атмаган төнең
341. Белмәү — гаеп түгел, өйрәнмәү — гаеп
342. Иске — гаеп түгел, ертык — гаеп
343. Байлык аера, ярлылык куша
344. Дөньяны җил бозар, адәмне сүз бозар
345. Эше юкның ашы да юк
346. Агач ботаксыз булмас
347. Качып китсәң, дә чәчеп кит
348. Акча санны ярата
349. Мулла булдың түр булдың, бер тиенгә көл булдың
350. Мулла булдың түр булдың, байгурага көл булдың
351. Без өйләнгәч төн кыска булды
352. Карт булса да, йөрәге шат
353. Ирдән иргә йөргәнче, түрдән түргә йөр
354. Һәр кешенең бармагы үзенә таба кәкре
355. Асыл сөяк зур булмас
356. Белмәгәнгә — нәкыш, белгәнгә — ялгыш
357. Сөйдергән дә — тел, биздергән дә — тел
358. Җәяүлегә янчык авыр
359. Ялкауга көн дә бәйрәм
360. Күңеллегә — куаныч, күңелсезгә — юаныч

361. Акчаны юлда тапсаң да, санап ал
362. Агач башы җилсез селкенми
363. Өеңдәге хәлне кешедән сора
364. Ата булмый ата кадере беленмәс, ана булмый ана кадере беленмәс
365. Укымый мулла булмый, чукымый карга булмый
366. Чакырмый килгән кунакка рөхсәтсез китү дә ярый
367. Кибән астында тычкан үлми
368. Күк төймәм кемдә, күңелем анда
369. Акылсыз дусттан акыллы дошман артык
370. Аерылмас иптәшкә онытылмас сүз әйтмә
371. Сугыш беткәч, батыр күп була
372. Туй үткәч, дөмбергә килмиләр
373. Усал белән тапма да, өләшмә дә
374. Җилсез кура селкенми
375. Ил авызына яулык бәйләмәссең
376. Туганның азары булса да, бизәре булмый
377. Сыйлап биргәннең суын эч
378. Ут белән уйнама, янарсың
379. Җыен эшнең арасында бер бүренең койрыгы бот арасында
380. Ак матур— чак матур, кара матур — бик матур
381. Каз ашы — кара-каршы
382. Бәйрәм ашы — кара-каршы
383. Урыс улын кыстырганда марҗа кызын кыстыра
384. Кысылмас җиргә кысылган Биктауга Биктимер
385. Балалы казка җим тимәс
386. Ашап туймаган ялап туймас
387. Эт кулыннан кош туймас
388. Чыккан җирендә алтынның кадере юк
389. Кичке эштән иртәнге эш көләр
390. Балык бирсәң бәйләп бир, башын-күзен чәйнәп бир
391. Юл газабы — гүр газабы
392. Аңлыларга әйттем — белде, аңсызлар шаркылдап көлде
393. Чебине көз көне саныйлар
394. Ерактагы чап була, якын килгәч чак була
395. Киткәнгә юл яхшы, калганга йорт яхшы
396. Адәм дисәң - юне юк, хайван дисәң - җаны юк
397. Кәсеп итми насыйп булмый
398. Изге ният — ярты рыскал
399. Китәсе малның киртәсе юк
400. Эт корсагына сары май килешми
401. Патшаныкын урламаган солдат булмас, атаныкын урламаган угыл булмас
402. Бүген үлгәннән таңда үлгән артык
403. Какма кеше капкасын, үз капкаңны кагарлар
404. Төя дә бүләк, төймә дә бүләк
405. Каланың стенасы да ала
406. Син дә мулла, мин дә мулла, атка печән кем сала

407. Укыган — мулла түгел, тоткан — мулла
408. Үткән эшкә салават
409. Идел суы — илле батман
410. Тизнең эше — тизәк
411. Шыр да суан, эч тә куан
412. Бер елга куян тиресе дә чыдый
413. Оятсыз хатын - тозсыз аш
414. Әрлеләр әрләнгәнче, әрсезләр ашап туйганнар
415. Ятимнең корсагы җиде булыр
416. Күп сүз бозау имезә, күткә таяк тигезә
417. Килен каенана туфрагыннан яратылыр
418. Усал булсаң асарлар, юаш булсаң басарлар, урта булсаң, ил агасы ясарлар
419. Эттән сөяк артмас
420. Мал иясенә охшар
421. Акыллы ирнең башында иярле, җөгәнле атятыр
422. Уңган килен ул табар, изге килен кыз табар
423. Күз — дәрья, күңел — марҗа
424. Эт ашы — кара боламык
425. Күршенең үрдәге күршегә каз булып, хатыны кыз булып күренә
426. Татарның акылы тау төшкәч, арбасы уалгач искә төшәр
427. Үксез үз кендеген үзе кисәдер
428. Ямле җәйнең мазасын черки-чебен китәрер, удал җегетнең йөрәген яман хатын кимерер
429. Үләр идем гамәл юк, өйләнергә сәман юк
430. Күп сүз башны авырттыра
431. Күздән ерак күңелдән дә ерак була
432. Юкәне майлау белән каен булмас

Татар халык иҗаты. Фәнни эзләнүләр һәм фольклор үрнәкләре.
Татарское народное творчество. Научные исследования и фольклорные образцы.

Фәнни конференцияләр материаллары җыентыгы.
Сборник материалов научных конференций.

Беренче китап.
Первая книга.

Составитель:
Редакторы: Р.Харисова, Р.Хисамиева, Л.Давлетшина

Набор нотных текстов: Д.Н. Арсланова

Дизайн обложки: Л.Леронова